PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2021 АПРЕЛЬ № 4

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398



мәхәббәт
ЯРАТТЫРА ДА,
яраштыра да

АЛСУ
АБУЛЬХАНОВА
мин –
хатын-кыз

төрек
ПӘХЛӘВӘСЕ
пешерү серләре

Кадрия ИДРИСОВА:

«Сүзеңнең һәрберсе кайтаваз булып кайта».

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!



Алсинә СӘЛАХОВА

КЫЗЫМ – МИНЕМ ЯШЬ ЧАГЫМ

Көзгеләргә карыйсың да,
Чәчеңне төзәтәсең.
Серле карашларың белән
Үзеңне күзәтәсең.

Егетләр карый борылып,
Син урамнан үткәндә.
Ышанмыймын, нәни кызым
Зур кызлардай үскәнгә.

Мин дә синең кебек идем,
Биеп һич туймый идем.
Балачаклар, гүзәл яшьлек
Үтмәс дип уйлый идем.

Күзләремне алып булмый,
Сокланам сиңа тагын.
...Гомер үткәнгә кайгырмыйм,
Син – ул минем яшь чагым.

■ Безнең гаилә бик музыкаль. Дәү әнием гармунда уйнап җырлады. Дәү әтием дә гармунчы иде. Әниемнең энеләре гитара чирткәннәр. Әни 12 яшендә гармунда уйнарга өйрәнгән. Үзем дә музыка мәктәбен тәмамладым. Хәзер кызым Камилла гитарада уйный. Төрле бәйгеләрдә катнаша. Хорда җырлый, бии. Талант нәселдән бирелә, диләр. Хактыр...

Әлфия ГЫЙЛЬФАНОВА.
Казан.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021



Фото: Ксения Богданова

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Кадрия Идрисова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр
Ильмира Сөләйманова
Олег Сердюк

Формат: 225x290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 29.04.2021 ел.
Чыгу көне: 8.04.2021 ел.
Заказ Е-949
Тираж 10236

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Россиядә: ПО279 (берьеллык)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



«Тукай лирикасыннан». Р. Кильдебәков эше. Фото: Елена Сөнгатова — elena@art16.ru



ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ БӨЕК ШАГЫЙРЕ ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА – 135 ЕЛ

Габдулла ТУКАЙ

Мәхәббәт

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы.

Бер гүзәлдән кайсы шагыйрь, әйтеңез, рухланмаган?
Байроның, Лермонтовыңмы, Пушкиныңмы – кайсысы?

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, –
Парә-парә кисмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.

Тешләренең гәүһәреннән кабызып алдым менә
Мин бу шигъре, – әйтсәңез лә, энҗедән ким кай төше?

Бу татар шагыйрьләрен мөмкиндер артка калдыру,
Алга сөрсен гашыйкый анчак мәхәббәт камчысы.

Һич хуҗалыкны кабул итмәм бөтен дөньяга мин,
Булмага мөмкин икән гыйшык, мәхәббәт ялчысы.

Әмма ләззәтле дә соң яшьрен газап, яшьрен яну! –
Бар микән, белмим, моның миннән бүтән аңлаучысы?

Барча әхраре мәхәббәт миннән уңда, зан итәм, –
Кайда Фәрһад берлә Мәҗнүн! – мин аларның таңчысы!

Шигъре – шигырен.
Гашыйкый – гашыйкны.
Анчак – тик, бары.
Барча әхраре мәхәббәт – иң кайнар мәхәббәт ияләренең барысы.
Зан итәм – уйлыйм.

Безнең тышлыкта

«Эшне башлап җибәргәндә иң беренче таләп – милли киемнәргә кайту иде. Әгәр дә сөйләгән сүзләрең, әйткән фикерләрең күңел халәтеңә дә, кылган гамәлләреңә дә тәңгәл килми икән, эшеңне куәтләүче дә булмый дип уйлыйм мин.»



10 Кадриянең ак дөньясы
Эльмира Закирова

Заман һәм без

6 Алиһә хатын-кызлар: ярашып яшәү хурлыкмы?
Чулпан Галиәхмәтова

16 Тренинглар нәрсәгә өйрәтә?
Руфия Рәхмәтуллина

14 Дөньяны үзгәрткән балчык
Гөлнур Хәсәншина



20 Мин – хатын-кыз!
Чулпан Галиәхмәтова



Татар дөньясы

22 Бергә булганда
Гөлнур Сафиуллина



26 Төрмәләрдән саркып чыккан моң
Тәэминә Биктимерова



30 Монда диварлар да татарча «сөйләшә»
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш



36 Миләүшәләр һәм карга каргышы
Нәзифә Кәримова




42 Җаным монда кала...
Гөлзадә Бәйрәмова

Яшәеш



48 «Яшәргә көчем калмады...»
Камилә Әюпова



52 Тургаем, сагындым!..
Эльмира Шәрифуллина

Хуҗабикә

57 Җиңсез күлмәк киярга әзерләнәбез

58 Челтәр-челтәр ак пәрдә
Чулпан Галиәхмәтова



60 Төрек пәхләвәсе

»

PRESSA

Элек хатын-кыз гаилә учагын саклаучы, ире артында торучы дип саналса, хәзер ул образ бермә-бер үзгәрде. Тормыш дилбегәсе дә, нигездә, хатын-кызлар кулында. Яулап алынган тигез хокук нәрсәгә китерде? Асыл затлар асыл булудан туктамадымы? Хатын-кыз һәрвакыт хатын-кыз турында яза да, фикерен дә әйтә ул. Бу юлы ирләр фикерен тыңларга булдык әле. Редакциябезгә ир-атларны гына җыеп, әлеге темага багышланган «түгәрәк өстәл» үткәрдек. Анда аксакал – Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге премия лауреаты Рабит Батулла, шагыйрь, шулай ук Г. Тукай исемендәге премия иясе Газинур Морат, «Татарстан» телерадиокомпаниясенең милли тапшырулар хезмәте җитәкчесе Миңназыйм Сәфәров, радиотапшырулар алып баручы, шоумен Зөлфәт Зиннуров, «Ябалак» эко-бакчасы җитәкчесе Азат Миргаязов килгән иде. Әңгәмәдә шулай ук «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Лариса Маликова катнашты.


Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА


Лариса МАЛИКОВА


Газинур МОРАТ


Зөлфәт ЗИННУРОВ


Миңназыйм СӘФӘРОВ


Азат МИРГАЯЗОВ


Рабит БАТУЛЛА

АЛИҺӘ ХАТЫН-КЫЗЛАР: ЯРАШЫП ЯШӘҮ ХУРЛЫКМЫ?

ХАТЫН-КЫЗЛАР – ЯНГАН УТКА КЕРҮЧЕ ДӘ, ИЛҺАМЛАНДЫРУЧЫ ДА, ТЕЛ САГЫНДА ТОРУЧЫ ДА?!

ЛАРИСА МАЛИКОВА: Сүзне «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова сөйләгән вакыйгадан башлыйсым килә. «Татар кызы» Халыкара бәйгесенә әзерлек барышында ул анда катнашкан кызлардан «Сезне очрашуга чакырганда вакытында барасызмы, соңга каласызмы, соңга калсагыз, шалтыратып әйтәсезме?» – дип сораган. «Нигә без шалтыратырга тиеш?! Безне акланмагыз, үзегез өчен яшәгез дип үстерделәр», – дигән алар. Кызларның җавабы аптырашта калдырды, әйтергә кирәк, күзләрне ачты. Үзләре өчен генә яшәүче алиһәләр үстерәбез түгелме соң? Алар ничек гаилә корыр, ничек бала тәрбияләр, ирен санлап яшәр? Сезне мондый вазгыять сискәндерәме?

МИҢНАЗЫЙМ СӘФӘРОВ: Үзең өчен яшәү дигән фикер әйттегез. Үзең өчен яшәсәң була инде ул, кияүгә чыгарга да, өйләнергә дә кирәкми. Көндәлек матбугатта бер егет «Ни өчен өйләнмибез», дигән сорауга җавап эзләгән. Кызлар машинаң бармы, фатирың бармы, күпме акча аласың дип сорый башлыйлар да, гайрәтне чигерәләр, шуңа яннарына барасы да килми, дип язган. Менә шулар бөтенесе бер җепкә тезелә. Гаиләдә бит кеше күңелен күреп яшәргә кирәк. Бер-береңә юл бирмәсәң, ун ел түгел, бер көн дә яши алмыйсың.

РАБИТ БАТУЛЛА: Без сезгә тигезлек хокукы алып бирдек. Сез аны бик рәхәтләнеп кабул иттегез. Бөек Ватан сугышыннан соң ирләр сирәгәйде, хатыннар ат җигә башлады. Дилбегәне, чыбыркыны тоттырдык. Итәгегезне салып чалбар кидегез, машина руле артына утырдыгыз. Шулай итеп азатлыкны алдыгыз-алдыгыз да, хәзер иза чигәсез. Сез активлашканнан соң ирләр пассивлашты да, диванга сузылып ятты. Бөтенесен үзегез эшлисез. Билгеле, акча да хатын-кыз кулына күчте. Шуңа күрә ничек санлап торсын инде ул ирне?

ЧУЛПАН ГАЛИӘХМӘТОВА: Димәк, хәзерге ирләр булдыксызрак булып чыга.

РАБИТ БАТУЛЛА: Шулайдыр инде. Кинәт акча эшли башласа, хөрмәте дә артырга мөмкин. Ләкин андый хәлләр булмый. Безнең буын өчен мал турында сораштыра башлау хатын-кыз белән араны шунда ук бикләп куя. Беренчедән, машина алырлык акча юк. Икенчедән, акчам булса да, качам инде аннан, чөнки дәрт суына. Мәхәббәт бөреләнә башланмаган, дәрт суынган була.

ГАЗИНУР МОРАТ: Бүген бик кызыклы әверелеш күзәтелә: теләсә кайсы өлкәдә хатын-кызлар ирләр вазыйфасын үзенә кабул итеп бара, ирләр хатын-кыз урынынарак кала башлады. Мәгарифтә ул йөз процент шулай. Шуңа да хатынлашу процессы җәмгыятьтә бик табигый, чөнки тәрбияне хатын-кыз бирә. Күрәсең, бу матриархатка бер адымдыр. Нәзберек затлар булып тоелсалар да, җәмгыятьнең катаклизмлы чорында хатын-кызлар түземлерәк: җаваплылыкны нәфис иңнәренә алалар. Ирләр, киресенчә, түземсезгә әйләнде шикелле. Игътибар итсәгез, бүген бөтен иң бай, иң җитеш илләрдә хакимият хатын-кыз кулында һәм, әйтергә кирәк, алар бик шәп идарә итә. Тәхеттә ир кеше утырырга тиеш дигән постулат юкка чыкты.

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Чулпан, димәк, ирләр булдыксызрак дип нәтиҗә ясап куйды. Алай түгел ул. Ир – бер өлкә буенча бик яхшы белгеч һәм ул шәһәрдә бер генә урында, мәсәлән, заводта эшли ала, ди. Үз эшен җиренә җиткереп башкара, ләкин моның өчен аңа тау-тау акча түләнми. Ә гаиләдә акча җитмәүгә бәйле низаг чыга. Проблема ир-ат булдыксызлыгында түгел, хатын-кызның булганына шөкер итә белмәвендә. Бирелгән гомерне шөкер итеп яшәсәң, күпкә җиңеләер, ир-атларның да гомере озынаер иде. Бала тәрбияләгәндә дә хатын-кызның иң элек иренә хөрмәте булырга тиеш. Балалар шуны күреп үссен.



ЧУЛПАН ГАЛИӘХМӘТОВА: Мин килешеп бетмим. Син хәзер безне меркантильлектә гаепләдең. Ләкин шундый хатын-кызлар ирләрен күбрәк эшләргә, диванда сузылып ятмаска этәрми микән?

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Сез шулай дип уйлаганга күрә дә ирләр кыска гомерле дә инде...

АЗАТ МИРГАЯЗОВ: Безнең динебез бар. Аның кануннары буенча, беренче чиратта, ир үз гаиләсен туендыра. Бу – аның вазыйфасы. Ә хатын-кыз аны илһамландырсын. Дөньяга танылган Генри Форд та үз уңышын хатыны белән бәйли. Хатыны: «Эшлә, уйлап тап», – дип игәүләмәгән аны, ә илһамландырган, ярдәм иткән. Һәр уңышлы ир артында көчле хатын-кызны тоябыз.

ЧУЛПАН ГАЛИӘХМӘТОВА: Акча да сорамыйча, эшлә дип тә әйтмичә, хатын-кыз ир-атны ничек илһамландырырга тиеш?

РАБИТ БАТУЛЛА: Ирләрне үсендерергә! Булдыра алмаса да, мактарга кирәк. Аннан соң булдыра башлый ул.

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Иргә терәк булырга, артыннан этеп торырга кирәк. Хатын идея бирсен, әмма ир аны үзем уйлап таптым дип белсен.

ГАЗИНУР МОРАТ: Ир-ат бөтен нәрсәне булдыра алмый. Менә шул чакта хатын күрше иренә, дусларына төртеп күрсәтә. Бу коточкыч дәрәҗәдә ир-атның тез астына суга.

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Телевизордан күрсәткән кинолар да боза хатын-кызны. Матур тормыш, ясалма чибәрлек, «мәхәббәтем», «кадерлем», дип эндәшүләр... «Менә күрдеңме, ничек дип әйтә ул хатынына», – ди инде безнекеләр.

РАБИТ БАТУЛЛА: Әмма ул бит бик төче сүз, ышандырмый. Татарда андый төчеләнү булмаган, хәтта «яратам» да димәгәннәр. Яратканнар, ләкин тел белән әйтмәгәннәр.

ГАЗИНУР МОРАТ: Хәзерге хатын-кыз тагын бер нәрсәне онытып бетерә. Ул – милләт анасы. Татар аңлы балалар тәрбияләү аларның тагын бер бурычы. Әнә, Актанышта 2 нче гимназиядә хатын-кызлар татарча укытуга каршы чыкканнар. Башка сыймаслык хәл бит!

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Бу да шул шөкер итә белмәүдән. Баласының русча укып, Мәскәүгә, чит илгә китүен тели ул.

РАБИТ БАТУЛЛА: Рус мәктәбендә укучылар да татарча фикерләргә мөмкин. Аяз Гыйләҗев, Нурихан Фәттах балалары шундый, чөнки аларның өендә дәүләт теле – татар теле булды. Минем балалар да рус мәктәбендә укыды, әмма телен, милли үзаңын онытмады. Нурбәккә 8 яшьләр тирәсе булгандыр урамнан кайтып керде дә, ишек төбендә: «Мам, дай хлеба», – дип кычкыра. Әнисе үзенең офисында, кухняда ягъни, мин – эш бүлмәмдә. Берничә тапкыр кычкырды, әнисе ишетмәмешкә сабыша. Шуннан миңа: «Күрше Миша кергән бугай, нәрсә кирәк икән аңа?» – ди. Мин ишек төбенә килдем дә: «Үзебезнең Нурбәк икән бит!» – дим. И оялды. «Әни, ипи бир әле», – диде кире. Бетте. Кабат бусаганы атлап өйгә кергәч, рус телендә сөйләшмәде безнең балалар. Бу бер боҗра гына. Телне, мәктәбең булмаса, болай гына коткарып булмый. Хөкүмәт дәрәҗәсендә алып барылырга тиешле сәясәт ул. Әмма ана теле юкка гына ана теле дип әйтелмәгән, аны хатын-кыз сакларга тиеш.

ЯУЧЫЛЫК ИНСТИТУТЫ

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Бер хатын, кияүгә чыкканнан соң, башка түзә алмыйм, дип, әнисе янына кайткан. Әнисе: «Кызым, менә сиңа бер шырпы, ул бар нәрсәне дә тәртипкә салыр. Ирең сүз әйтә башлагач, авызыңа кабып куй», – дигән. Бераз вакыт үткәч, кызы белән кияве кунакка килгән. «Булыштымы, кызым?» – дип сораган әнисе. «Булышуын булышты, әмма чәйнәп бетердем. Тагын бер шырпы бир әле», – дигән хатын.

АЗАТ МИРГАЯЗОВ: Элек йөрешү-очрашулар булмаган, әти-әниләр таныштырган. Миңа калса, бу бик яхшы күренеш, чөнки өлкәннәр күбрәк белә.

РАБИТ БАТУЛЛА: Яучылар институты бетте шул. Революциягә кадәрле яучыларның үз дәфтәрләре булган, анда нәсел-нәсәп турында бөтен мәгълүмат язылган. Ә хәзерге яучыларны бер генә нәрсә кызыксындыра: фатиры бар, әти-әнисе урында эшли. Элек күрешмичә дә өйләнешеп бик бәхетле яшәгәннәр. Балалар булгач, тора-тора яратышасың аны. Ләкин хикмәт нәрсәдә? Бар яраклашып яшәү, бар ярашып яшәү. Яраклашып яшәү ул – кемгә димләсәләр, шуңа өйләнеп яшәү, әмма ярату булмый. Ярашып яшәү – мәхәббәт дигән сүз. Ул психологик яктан бер-береңә туры килүне аңлата. Бездә, мәсәлән, кулда ике тавык боты, хәзер минем күз эзли башлый, алга тоз килеп куна. Хатын! Тоз кирәклеген белеп тора ул. Югыйсә сорамадым да. Күз карашыннан тоя. Бу ярашып яшәү, сүзсез аңлашу! Шулай яшәргә язсын барыгызга да. Яраклашып яшәүне дә хөрмәт итәм, чөнки алар бала туганнан соң, аларны ятим итмәс өчен, яраклашып яшәргә мәҗбүрләр һәм бөек батырлык кылалар.

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Хәзер хатын-кызның күбесе алай яшәми. «Мин көчле» дигән марафоннарда катнашалар, интернеттан укыйлар. Ир-ат аның кадәр үк кирәк түгел дигән фикергә киләләр...

ГАЗИНУР МОРАТ: Нәрсә генә дисәгез дә, ир кешенең күзе иң беренче хатын-кызның йөзенә төшә. Матурлык ул – алдавыч. Дөресен генә әйткәндә, бик күп ир-атның гомере, алданып, бушка уза.

МИҢНАЗЫЙМ СӘФӘРОВ: Моннан качу юллары да бар, Газинур. Менә мин ике кыз үстердем. Безнең өйдә язылмаган канун бар иде: кем белән йөрсәң дә, аны өйгә алып кереп таныштырырга. Әти-әни белеп торырга тиеш. Егет безгә кергәч, телен тартып карыйсың, сөйләштерәсең, фикер сөрешеннән кем икәнен чамалый башлыйсың. Килгән саен күзәтәсең. Шулай хәйран гына егетләрне араларга туры килде. Бервакытта да: «Кызым, моның белән йөрмә, сиңа пар түгел», – дип әйтмәдем. Чөнки балага алай әйтсәң, үземнекен эшлим дигән фикере уянырга мөмкин. Җайлап кына: «Бу егет болайрак», – дип әйтә идем. Шуннан кайтып: «Әти, син хаклы булгансың», – диләр иде. Кияүгә чыктылар. Хәзер без кызлар ягында түгел, кияүләр ягында, чөнки үзебез дә сайлаштык. Әни дә миңа каршы Резеда белән коалициягә керә иде. Үзенә күрә дипломатия! Ә тормышта ул бик кирәк. Әгәр дә балаңны: «Синнән яхшысы, чибәре юк, тегене сора, моны эшлә», – дип «үсендереп» торсаң, барып чыкмый ул. Без әле баштарак кияүләр белән бергә яшәдек. Ул да кияүләр өчен үзенә күрә бер үрнәк булды. Алар да, гаиләгә кергәч, боларда нинди тәртип икән дип күз салмый калмый. Мәсәлән, кияүләр ашарга пешергәләштергәнемне күрде. Безнең гаиләнең тәртибе шулай. Баштарак пешерергә уңайсызланалар иде, хәзер ике кияү дә, башларына төшсә, пешерә ала.

АЗАТ МИРГАЯЗОВ: Тимергали хәзрәтнең кияү белән кәләшкә биргән бер киңәше истә калды: «Бер-берегезнең әти-әнисенә зарланмагыз. Синең әниең синең яклы, аның әнисе – аның яклы. Дөреслекне табып булмаячак». Бу гаилә тормышында беренче кагыйдә булырга тиеш. Мин дә хатыныма әйтеп куйдым: «Нәрсә булса да, әйтмибез!»

ГАДЖЕТЛАР ТӘРБИЯСЕМЕ, МӘХӘББӘТМЕ?

ГАЗИНУР МОРАТ: Безнең заманда романтика бар иде. Хәзер бит аңа урын калмады. XXI гасырда, нигездә, меркантиль мөнәсәбәтләр хөкем сөрә. Бүгенге көндә тәрбияче – әти-әни дә, мәктәп тә түгел, ә гаджетлар.

ЛАРИСА МАЛИКОВА: Капма-каршы фикер яңгырады. Зөлфәт тә, Миңназыйм абый да кызлар гаиләдә тәрбияләнергә тиеш, ди. Газинур абый гаджетлар җиңә диде. Ничек уйлыйсыз, кем җиңәр? Азат, балалар бакчасында нинди тенденция күренә.

АЗАТ МИРГАЯЗОВ: Әлбәттә, гаиләгә карый. Шуңа да хатын-кыз белемле, акыллы, зиһенле булырга тиеш, чөнки аның бала тәрбиялисе бар. Без хатыным белән, мәсәлән, әкиятләр аша тәрбияләү яклы, чөнки балалар кечкенә чакта аларга бик тиз ышана, тәэсирләнә. «Шүрәле», «Су анасы», «Сак-Сок» китаплары һәр татар гаиләсендә бардыр. «Сак-Сок» китабының тышлыгы истә калган. Беренче битеннән үк тәэсирләндерә торган китап бит ул! Ә хәзер гаиләдә гаджетлар хакимлек итә. Алиһә кызлар шулар корбаны инде. Моның белән ничек көрәшергә соң? Беренчедән, гаилә, икенчедән, массакүләм мәгълүмат чаралары. Бүгенге көндә кешегә иң көчле тәэсир итә торган инструмент – социаль челтәрләр. Тәрбияне шунда алып барырга кирәк дип уйлыйм. Татар блогерлары аша эшләргә кирәк. Аларның да беренче бурычлары халыкны тәрбияләү булсын иде. Дөрес, татар милләте глобаль тенденциягә тәэсир итә алмый. Анысы да бар.

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВ: Яраклашмыйча булмый. Гаиләдә алган тәрбия, аның үз кыйммәтләрен истә тотып, замана белән атларга кирәк.

МИҢНАЗЫЙМ СӘФӘРОВ: Бу мавыгулар үтәчәк. Бу кадәр табыну, моның кадәр мавыгу була алмый. Телевидение чыккач, телевидение белән шулай булды. Социаль челтәрләрдә дә төрлесе бар, ул буш булырга тиеш түгел. Чикләвекне ватканнан соң эчендә чикләвек булырга тиеш. Блогерлар гына тәрбияләп бетерә алыр микән?! Кайберләренең үзләрен тәрбияләргә кирәк әле аларның.

ЛАРИСА МАЛИКОВА: Газинур абый, сезгә шагыйрь буларак, бер сорау бирәсем килә. Минем олы кызым да 90 нчы елда туган бала. Ул да үзенә принц образы ясап куйган иде. Булачак киявебез танышырга килгәч, көлеп кенә: «Кызыгыз Ламборджини турында хыяллана, күз күрер», – дип куйды. Аллага шөкер, Ламборджинисыз да бик бәхетле яшиләр. Мәхәббәт үзгәртте дип саныйм кызымны. Сез шагыйрь буларак ничек уйлыйсыз, мәхәббәт җиңәргә тиешме?

ГАЗИНУР МОРАТ: Әлбәттә, тиеш. Мәхәббәтсез яшәп булмыйдыр да ул...

АЗАТ МИРГАЯЗОВ: Бер хикмәт иясе әйткән бит: мәхәббәт ул – фигыль. Мәхәббәт юктан бар булмый. Каяндыр килеп тә чыкмый. Аның өчен сәбәп кирәк. Хатын-кыз да, ир-ат та гамәле белән яраттыра, Рабит абый әйтмешли, яраштыра. Мәхәббәтне яулау өчен тырышырга кирәк. Егетләргә генә түгел, кызларга да...

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
әзерләде.

КАДРИЯНЕҢ АК ДӨНЬЯСЫ

Аны татарлар яшәгән һәр җирдә – үзебезнең шәһәр-авылларда, ерак төбәкләрдә, хәтта чит илләрдә беләләр, якын күрәләр, яраталар. «Кадрияне калфагыннан ук танып алабыз», – диләр. Милләт кызы, татар хатын-кызы образы идеалы итеп кабул итәләр. Затлы-зыялы да, чая-тәвәккәл дә, тынгысыз-тиктормас та, зирәк-сабыр да, ихлас-гади дә, һәм шул ук вакытта горур да... Аңлагансыздыр инде, сүзебез – Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе, РСФСРның халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган социаль хезмәткәре, «Россиянең атказанган педагогы» билгесе иясе Кадрия Рәес кызы ИДРИСОВА турында. Без бүген аның хозурында.



Фото: Анна Арахамия



Эльмира
ЗАКИРОВА

Энҗе-мәрҗәнле ак калфактан, сирень чәчәге төсендәге күтәртмә якалы күлмәге түшендә дә – шул ук энҗе-мәрҗәннәр. «Кайда гына барсам да, нинди генә чарада катнашсам да, миннән калмый инде калфак. Мине хәзер калфаксыз кабул да итмиләр. Беркөн сөткә чыккан идем. Сатучы рус хатыны: «А почему без этого», – ди. Калфак дип әйтә белми инде», – дип көлә.

Бөтендөнья татар конгрессы бинасында ул утырган бүлмәдә үзенә бер бәйрәм халәте, төсләр балкышы. Чигүле сөлгеләр эленеп тора, чиккән намазлыклар күзгә чалына, дисбеләрнең ниндие генә юк...

– Быел Бөтендөнья татар хатын-кызларының VI җыены көннәрендә күргәзмәдә чиккән сөлгеләр күзне иркәләячәк, – ди ул. – Нижневартовск, Соликамск, Мәскәү, Сочи, Кырым... Кайлардан гына юк! – Кадрия ханым, сокланып, сөлгеләрне барлый-барлый дәвам итә. – Яңа елдан соң намазлыклар чигә башладык. Карагыз әле, бер авылдан гына да унар кеше катнаша! Менә, Самараның Гали авылы кызлары шулай чигә. Инде дисбе ясый башладылар.

Мин шаккатып карап торган арада, монысы талдан эшләнгән, бусы – ногыт борчагыннан, хөрмә төшеннән, дип санап, төрледән-төрле дисбеләрне өстәлгә тезеп сала.

– Ничек ясарга дип, төне буе язышалар! Мәрьям ана гөле бар. Кызлар бер-берсеннән күреп, шуны үстерә хәзер. Аның орлыгы ялтырап тора. Тал белән хөрмә төшен аралаштырып тезгәннәре дә бар менә. Бервакыт Зәйнәп исемле кызыбыз яза: «Кызлар, 2 килолап җимешне туганнарга ашатып бетердем инде. Төшләрен дә җыйдым. Керми бит аңа энә!» – ди. Уйлагыз, дидем. Кайсыдыр кайнатырга кирәк аны дип өйрәткән. Кайнаткач, ялтырап

та китә, җеп узардай тишеге дә барлыкка килә – тезәсе генә кала.

Кайберәүләр моны вак эш ди инде. Мунча себеркесе бәйләргә өйрәтүне дә, кулъяулык чигүне дә... Ләкин болар берсе дә вак эш түгел! Тыныч кына күпме эш башкарабыз! Үз милләтеңнең гореф-гадәтләрен, милли ашларын, йолаларын, киемнәрен, уеннарын, кыскасы, ата-бабалардан калган ядкарьләрне саклап калып киләчәк буынга тапшыру өчен эшлисең. Мин шулай уйлыйм.

Әйе, шулай уйлап, шулай эшләмәсә, Кадрия буламыни ул! Мин аның Казан педагогика институтында укып йөргән елларын хәтерлим: якташлар бит... Мәктәптә үк спорт буенча уңышлары булган кыз институтта да волейбол җыелма командасына килеп эләгә, җиңел атлетика, теннис, чаңгы ярышларында да алдынгылардан була. Кадрия – «Горизонт» студентлар төзелеш отряды комиссары, бер елдан инде – командир. Группаның комсоргы. Мәскәү Олимпиадасы көннәрендә педагогика институты егет-кызлары белән бергәләп поездда проводник булып эшли. Шулай ук студент кыз фәнни конференцияләрдә дә чыгышлар ясый. Соңгы курста аны аспирантурага кыстыйлар, институтның комсомол эшендә күрергә телиләр. Ә ул үзсүзле кыз, мин авыл укытучысы булырга укыдым, дип, Актанышка кайтып китә. Сәфәр мәктәбендә бер ел эшләүгә, завуч итеп куялар. Җырчы егет Азатка кияүгә чыга... Тормышның яңа бер чоры башлана. Актанышлы, Агыйделле, Азат, Алмаз, Алсулы ак дөнья...

Мин Кадрия Рәес кызының район хакимияте башлыгы урынбасары чакларын искә төшерергә яратам. Хакимият башлыгының авыл советлары белән, социаль мәсьәләләр буенча урынбасары булып эшләү дәверендә (ул колачлаган өлкәләр арасында мәгариф, мәдәният, социаль яклау, спорт, медицина, санэпидстанция, военкоматы, почтасы да...) бик күп яңалыклар керде Актанышка. Район тарихын өйрәнергә килгән галимнәрдән башлап спортта, сәнгатьтә, иҗатта җиңгән балалар өчен «Сәләт» лагерен оештыру, әле генә уку бетереп кайткан белгечләр өчен яшьләр форумыннан башлап халкыбыз мирасын саклап калу максатыннан төрледән-төрле бәйгеләр булдыру, балалар бакчалары республика семинарының Актанышта узуы, мәдәният хезмәткәрләре республика слетының да районда үткәрелә башлавы һәм башкалар, һәм башкалар... Бүгенге Актаныш урамнарының чисталыгына, матурлыгына сокланабыз икән, анысында да Кадриянең өлеше зур. Ул оештырган чәчәк бәйрәмнәре, «Ишегалдым гөлбакча» конкурслары (һәр кеше үзе яшәгән йорт тирәсен чәчәккә күмәргә тиеш иде. Урамдагы сыерларны Идрисова үзе куып йөри, дип сөйләделәр хәтта! Ә хәзер Актаныш авыллары гөлбакчаны хәтерләтә!) кебек чараларны халык та үз итте. Сөйләшәбез, искә төшерәбез, сагынабыз... Кадрия ханым сөйләгәннәр уйдык-уйдык булып күңелгә кереп урнаша.

Мин әбиле йортта үстем

– Балачагым кечкенә генә Чынык авылында үтте. Һәр йортта бишәр, алтышар бала. Күп балалы кечкенә авылда бөтенебез дә туганнар кебек идек... Бер өйгә кунак кайтса, ул барыбызның да кунагына әйләнә... Бакча артында гына Шәбез суы. Фәлән тапкыр су кердек, фәлән тапкыр чумдык дип, ярыша-ярыша санаш иде. Без әбиле йортта үстек. Бер йортта өч буын бергә яшәдек. Әти, әни, әбекәй һәм без – алты бала: Илһамия апам, мин, Азат, Нияз, Зилә, Илһам – тугыз җан бер түбә астында. Әбекәйгә ихтирам зур иде. Ә Идрис бабакай Чишмә авылында председатель булып эшләгәндә сугышка киткән һәм кире әйләнеп кайтмаган. Безнең әле әни ягыннан ерак әбекәй, ерак бабкай да исән иде. Каникуллар башлануга ук ерак бабакай, ат җигеп килеп, безне яланнар аша үзләренә – Каентүбә авылына алып китә. Ерак әбекәем Хафаса 85 яшькә җиткәнче биек үкчәле читекләр киеп йөрде. Бервакытта да ишегалдында йөргән киемнән суга да чыкмады, капка төбендә дә утырмады. «Карга боткасы»на барыр алдыннан ике сәгать алдан әйтеп куярга кирәк иде. Чөнки бик озаклап киенә, ясана. Чәчләрен тарап үреп куя, чулпыларын тага, йөзекләрен алмаштырып бетерә, чигүле камзулларын кия... Чыннан да, затлы нәселдән иде шул әбиебез. Татарстанның халык рәссамы, скульптор Васил Маликов, Башкортстанның халык рәссамы, скульптор Зилфәт Басыйровларның апасы иде ул! Аның әйткән сүзләрен хәзер дә «ерак әбекәй әйтмешли», дип искә төшерәбез. Алар нәселе кул эшләренә оста иде. Әни, мәсәлән, бөтенесе йокларга яткач, лампа яктысында бәйләп утырыр иде. Без гел бәйләнгән әйберләр киеп үстек. Кормашка йөреп укый башлагач, мәктәп интернаты тәрбиячесе Көмеш апа гел әйтә иде «Әзһәрия кызлары» дип... Әнинең кул эшләреннән аның кызлары икәнебезне таныйлар иде. Ерак әбекәй дә бу дөньядан киткәнче, мана-мана, укалап-чуклап япмалар, оекбашлар бәйләде. Аның бөтен әйберсе тәртиптә иде. Хәтта чәч тараганын да кешегә күрсәтмәде, мич арасына кереп, алдына яулык җәеп тарый иде. Бөтен эшне бөртекләп эшли. Бәрәңгене дә хәтта җидегә аера иде...

Ак калфак» җитәкчесе булырга
ул бөтен барлыгы белән
әзер иде инде.

И ул балачак хатирәләре!.. «Карга боткасы»на барулар, кырмыска оясына аяк-кулларны куеп торулар, үләннәр, мәтрүшкәләр җыюлар, каз утыртулар, каен себеркесен бәйләүләр – барысы да әбиләрдән сеңгән безгә... Әбекәй янына күрше әбиләр еш керә иде. Бервакыт Шәмсенур әби ишектән күренүгә, апа, гадәттәгечә, самавырга ябышты. Ә мин урындык җәймәсен таба гына алмыйм бит! Шәмсенур әби мине күтәп торды-торды да, ак йон бияләйләрен урындык өстенә салып утырды, бергәләшеп дога кылдылар. Инде кунагыбыз киткәч, әбекәй: «Апаң доганы алып калды, ә синең доганы Шәмсенур үзе белән алып китте. Чөнки эшеңне үти алмадың», – диде. Әллә нинди гаеп эшләгән кебек хис иттем үземне!

Шулай ук тагын бер матур хатирә: әни мичтә алты ипи пешерер иде, шуның берсен кендек әбиебез Зөләйхаттәйгә без, балалар, илтеп бирергә тиеш идек.

Ә Сабантуйлар җитсә, әни җыенызбыга күлмәк тегәр, безгә өр-яңа сандалилар кидерерләр иде... Машина әрҗәсенә тезелеп олысы-кечесе җырлый-җырлый Иске Кормаш-

Төрле милләт халкы арасында яшәп тә, үзләрен күрсәтә белә безнен татар хатын-кызлары.



■ Татар кызлары искиткеч булдыклы, уңган... Күңел күтәренкелеге дә бар аларда, асылыбызга кайту да...



ка Сабантуйга барулар... Тиенләп җыйган акчаларга көнбагыш, тәмле сулар алулар... Ә эти – көрәшче. Аның көрәшкәнен ут йотып күзәтүләр... Мин дә Сабантуйларда йөгерә идем. Авылдашлар үз баласыдай якын итеп, көч биреп тора. Бүләккә яулык эләгә. Менә ул нинди авылның хикмәтле тәрбиясе!

Бөркет капка шакый!

– Июньдә туебыз булды, сентябрьдә Азатны Актанышка эшкә алдылар. Ул мәдәният йортында эшли, мин авырлы килеш аңа булышып, концерт-спектакльләр әзерләшеп йөрим. Алмаз тугач, кайнана белән кайната янына төп йортка кайттым. Баланың кырыгы тулганчы шунда яшәдек. Актаныштa Яңа ел кичәсен алып баруымны ошатып, миңа инде эш тә табып куйганнар. Балалар бакчасына мөдир итеп көтәләр! Баланың кечкенә булуын, шулай ук әлеге хезмәтнең минем өчен яңалык икәнен әйтеп, тәрбияче булырга гына риза булдым. Дүрт айлык Алмазны күтәреп эшкә йөри башладым. «Нинди кырмыска дүмгәгенә эләктем мин!» – дим Азатка. Гөж килә бит балалар.

Ияләштем. Шул балалар белән идәндә өелешеп уйныйбыз, биюләр куеп, аларны клубта биетәбез. Өч айдан мөдир итеп күчерделәр. Балалар бакчасына ремонт ясаулар үзе бер кыйсса! Штукатуркаларын куптарып, цемент, комнар кайтартып, тузанга батып... Бөтен ата-ана килеп булышты! Аннары инде бассейнлы бакча турында хыяллана башладык. Проектлар эзләп табып, ашкынып йөрим... Озакламый төркемнәрнең үз мәйданчыгы булдырылды: һәр баланың кечкенә көрәкләре, тырмалары. Алмагачлар утыртабыз, чәчәкләр үстерәбез, үрдәкләр, попугайлар, кенәриләр асрыйбыз. Соңрак кышкы бакчабыз да булдырылды! Азатның кышкы бакча өчен үсентеләр алып кайтуы һаман да истә. Салкын декабрьдә утырттык. Ул – миңа, мин аңа гел шулай эштә булышып тордык без. Бакчабызга «Каенкай» дип исем куштык.

Диварларына Коръән китабы тышындагы сурәтләр төшерелгән музее гына да ни тора! Энеләрем Азат белән Илһам ясады. Хәтердә уелып калган тагын бер истәлек – бервакыт бакчага ятим калган бөркет баласын китерделәр. Аңа кышкы бакчада читлек ясадык. Әллә беренче көннән үк үзем ашаткангамы, белмим, бөркетебез башка берәүне дә янына китермәде. Балалар бакчасыннан киткәч тә, бөркетне ирекккә чыгарып җибәргәннәр. Әгәр дә каяндыр укыган, кемнәндер ишеткән булсам, ышанмас идем. Кечкенәдән үк читлектә утырып очарга да өйрәнә алмаган бөркет, мине эзләп өйгә килгән иде...

Хакимияткә эшкә килгәч тә, бакчаны, балаларны сагындым. Аның энергетикасы, кешеләре яхшы иде. Балалар йоклаганда коллектив белән бер-беребезне чигәргә, тегәргә, кәфенлекләр кисәргә, корама ясарга өйрәтәбез. Минемчә, бакчада эшләгән кеше – җыештыручымы ул, тәрбиячеме, мөдирме – бөтенесен эшли белергә тиеш.

Кадрия Рәес кызы кайда гына эшләсә дә – мәктәпме ул, бакчамы, район хакимиятеме, мәдәният министрлыгымы – һәр үткән юлы аны бүгенге эшенә – «Ак калфак» татар хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе булырга әзерләгән. «Алар барысы да бүген кирәк, мин бөтен тәҗрибәмне кулланам», – ди ул үзе дә. Аның асыл сыйфатлары, кешеләрне тыңлый, халык белән эшли белү сәләте, моңарчы беркайда кабатланмаган, беркемнең башына килмәгән яңа кызыклы юнәлешләр уйлап табуга маһирлыгы, һәрчак булышырга әзер торуы, һәркем белән уртак тел таба алуы күпләрне магнит кебек үзенә тарта. Кешене урыны түгел, эше бизи шул.

Региональ «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының кабул ителгән эш юнәлешләре стратегиясе белән танышам. Дүрт юнәлештә эш алып бара алар: йола, гореф-гадәтләрне кире кайтару һәм аның үтәлеше; татар гаиләсе; татар халык ашлары; сәламәт милләт. Татарстан белән генә чикләнмичә, Россия төбәкләрендә, чит илләрдә «Шә-

җәрә – киләчәккә тәрәзә» фестивале үткәрү, дөнья буйлап уздырыла торган «Татар кызчыгы», «Татар малае», «Нәүрүз гүзәле», «Сөмбелә», «Яшь киленнәр», «Килен-кайнана», «Күркәм гаилә», «Әбекәй-матуркай», укучы кызларның «Ак калфак», «Татар кызы» халыкара бәйгеләре... «Тарихи хәтер» клубы эшчәнлеге, югалган авыл тарихларын өйрәнеп китаплар чыгарулар... «Тәрбия баскычы» дискы 40 көнгә хәтле сабыйны тәрбияләү, аннары 40 көннән 3 яшькәчә, 3 яшьтән 7 яшькәчә балаларны тәрбияләү турында. Болар һәммәсе «Ак калфак» тарихына язылып калырлык, горурланырлык эш-гамәлләр.

«Иң элек, кызлар, үзебез калфак киябез!»

– Иң беренче эш итеп өйрәтү дәресләре үткәрә башладык. Калфак тегәргә һәм изү чигәргә өйрәнү өчен регионнардан 111 хатын-кыз Казанда җыйналды. Дизайнер Ләйсән Хаҗиева белән Самарадан килгән Гөлнара Насыйрова аларның остазлары булды. Аларны озаткannнан соң, аш-су осталарын җыйдык. Өч ресторанда уникe төрле татар халык ашлары пешерергә өйрәтелде. Бу дәресләрдә дә 100 дән артык хатын-кыз катнашты. Җирлекләренә кайткач, башкаларга да өйрәтү максат итеп куелды. Сурәтләргә төшереп, язма материаллар белән безгә юллау өй эше итеп бирелде. Әлеге чараларның уңышы турында бер фикер әйтеп китү дә җитәдер: регионнардагы, районнардагы хатын-кызларыбыз үз җирлекләрендә элек-электән үк килгән һөнәрләрне тергезеп, башкаларны да таныштырдылар. Свердловскилар, мәсәлән, үзләренчә итеп, ыргак белән тамбурлы чигү серләренә төшендерсәләр, самаралылар изү, алъяпкычлар каю буенча осталыкларын җиткерәләр. Гомумән, күпме хатын-кыз милли киемгә кайта башлады! Аңлату гына кирәк кешегә. Шулай ук иң беренче юнәлешләребезнең берсе шәҗәрәләребезне барлау булды. 2015 елдан башлап һәр елны бер регионда «Шәҗәрә – киләчәккә тәрәзә» исеме астында күчмә утырышлар уза. Кешеләрнең шәҗәрәсе турында гына сүз бармый, ә милләтемнең көнкүрешендә, яшәешендә бик тә кирәкле булган ядкарьләр – калфак, түбәтәй, беләзек, самавыр, сөлге, сандык, комган, мәктәп, балалар бакчаларының тарихлары да өйрәнелергә тиеш.

Өйдә сине аңлап торучылар кирәк

– Ирем Азат Нургалиев – җырчы. Шуңадыр, Алмаз да, Алсу да сәхнәләрдә җырлап, республика бәйгеләрендә катнашып үстеләр. Минем як туганнар рәсемгә, бизәү, матурлау эшләренә хирыслар. Балалар бу яктан да сәләтле булдылар. Улыбыз Алмаз мәктәп елларында ук җырлады да, рәсемнәр дә ясады. Рәсемнәре «Ялкын», «Салават күпере» журналларында басылды. Җыр буенча төрле бәйгеләрдә җиңеп, консерватория тәмамласа да, икенче юнәлеш – кино дөньясын үз итте. «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы оештырган чараларның, шулай ук «Тәрбия баскычлары» өйрәтү фильмының режиссеры һәм сценаристы да Алмаз.

Кызыбыз Алсу... Сәнгать юнәлешендә сәләте зур булса да, Алсу төгәл фәннәрне үз итте. Төп белем йорты итеп финанс-икътисад институтын сайлаган хәлдә, җырчы Клара Хәйретдиновада дәресләр алды. Ул елларда Алсуга татар халкының иң авыр җырларыннан саналган «Гөлҗамал», «Зөлхиҗҗә» кебек әсәрләрне Мәскәү сәхнәләрендә башкарырга насыйп булды. «Әнкәм» дип дәшә иде ул миңа гел!.. Соңгы тапкыр җәй көне мәңгелек сәфәренә чыгып китәр алдыннан иртәнге бишкә кадәр өй җыештырды, ишегалдына түшәлгән такталарга кадәр бик бөртекләп, кыра-кыра юды. Шелтәләп тә ташладым. Син үзең дә шундый бит, ди. «Әнкәм, 75 процент кына сиңа охшасам да, бик бәхетле булыр идем!» – дигән сүзләре һаман яңгырап тора кебек... Мин Алсу белән Алмазны бергә җырлатырга хыяллана идем. Тавышлары туры килә... «Алсу, Алмаз Нургалиевларның «Алнур» төркемен оештырыгыз», – дим. Азат белән яши башлавыбызга 25 ел тулуны Актаныш мәдәният сараенда халык каршында көмеш балдаклар алмашып уздырдык. Залда – халык, дуслар, туганнар. Алсу гына арабызда юк инде, ул сәхнә түрендәге экраннан гына елмая... Шул бәйрәмдә Алмаз: «Әни, мин Алсуга кушылып җырлыйм. «Алнур» төркеме барлыкка килгән дип уйла», – диде...

* * *

Тормыш дәвам итә. Киленнәре Алсу – Алмазның хатыны – дүртенче баласын бала табу йортыннан да калфак киеп алып кайткан. Укытканда да дәрескә калфактан керә икән. Азат белән Кадрия йортында ял көннәрендә Нургалиевлар гаиләсе сигез җанга әйләнә. Алмазның дүрт улы килсәме! Йосыф, Муса, Юныс, Салихның сорауларына җавап биреп кенә өлгер! Азат Газетдин улы – бабакай, Кадрия Рәес кызы алар өчен – әбекәй! Кадрия әбекәй иртән торуларына тәбикмәк, коймак та пешерә, кичерәкләргә әкиятләр укырга да өлгерә, бергәләп чаңгы, тимераяк шуарга да чыгып китәләр, шашка, шахмат уйныйлар. Чатнатып татарча сөйләшәләр. Чып-чын татар малайлары!

Кадрия Идрисованың бик мәгънәле мондый сүзләре бар: «Эшне эшлибез икән, авызыбыздан бер сүз чыга икән, ул бит үзебезгә кайтаваз булып кире кайта. Нәкъ урмандагы кебек! Ә минә шул кайтаваз, синнән чыккан һәр сүз эшеңә хисап булып кайтырга тиеш, минемчә. Кайтаваз булып кына түгел, хисап булып! Тормыштагы максатым шул минем».

Аның ак дөньясы шушы кайтавазлыр, мөгаен.



ДӨНЬЯНЫ ҮЗГӘРТКӘН

– Әйдә, башта балчык белән дуслашабыз! Дуслашмасак, аннан берни дә әвәли алмабыз... Учыңа сал да, җылыт аны. Ул бит бик озак еллар җирдә яткан, «кайчан миңа кеше куллары кагылыр икән» дип көткән... Нәрсә ясарга телисең? Керпеме? Ярый, алар миндә берничә төрле, хәзер берсен сайлыйбыз...

Мастер-класс узучы 6 яшьлек Варвара (ул да әти-әнисе белән Мәскәүдән килгән турист!) шул арада кулындагы балчык белән генә түгел, Гүзәл апасы белән дә дуслашырга өлгерә. И-и, балчык турында бу кадәр тәмле итеп сөйләп торсын да соң!

...Барысы да Апас районы Борнаш авылындагы төп нигезләрен саткач башлана. Әнисенең кинәт ямансулап, моңсуланып калуын күргән кызы, туган көненә көтелмәгән бүләк әзерли: керамикадан аның туган йортын ясый. Түшәмен ачып, хәтта йорт эченә күз салырга да була: стенада сәгать эленеп тора, кайчандыр алар түгәрәкләнеп утырган өстәл, карават... Гаҗәеп матур истәлек! «Ә моны ничек ясап була?» – дип сорый ул шунда ук. Алисә әнисен керамика белән шөгыльләнүче дус кызы янына алып бара. Утта янарга сәләтле балчык белән беренче очрашу була бу...

– Керамиканы яшьтән үк яраттым. Кемгәдер бүләк бирергә кирәк булганда, нигәдер, гел балчыктан эшләгән вазалар, чүлмәкләр алырга тырыша идем. Казанга күчеп килгәч, эштән кайтышлый «Майолика» кибетенә керә торган булдым. Күн саен! Нәкъ менә керамикадан ясалган әйберләрне карап йөрим. Боларны бит кеше кулы тудырган, дим... Озакламый үзем дә балчыктан сувенирлар эшли башлаячагымны күз алдыма да китермәдем...

Гүзәл ханым үзе әйткәндәй, тормышта бер нәрсә дә очраклы түгел. Гомер буе мәктәптә математика укытса да, кул эшләре белән шөгыльләнергә барыбер вакыт таба торган булган ул. Хәер, бу мавыгу аңа нәселдән үк килә. Дәү әнисенең Әнәледә оста тегүче дигән даны таралган. Дәү әтисе исә аяк киемнәренә кадәр теккән. Гүзәл дә әнисе теккән күлмәкләрне киеп үскән. Аннары инде, үзе дә балаларына хәтта пальто да сатып алмаган: кулың эш белгәндә! Әле Алабугада яшәгәндә бисер белән калфак, түбәтәй чигү белән дә мавыккан.

Лаеклы ялга чыгуга аңа мәктәптән китәргә туры килгән: урын өстендә яткан әнисен тәрбияләгән. Аны җирләгәч, нигезне дә саткач, дөнья бушап калган...

– Әле укытканда ук уйлый идем, пенсиягә чыккач нишләрмен, дия идем. Миңа актив тормыш кирәк иде. Ә монда гел кеше арасында кайныйм. Иң ошаганы – шул бугай. Туристлар башкалардан аерыла: алар дөньяга гел позитив күзлектән карый. Безнең шәһәрдән яхшы уйлар, яхшы фикерләр белән китсеннәр дип тырышам...

Кызының дусты Эльвира янында шактый остаргач, бирегә – «Туган авылым» милли комплексына, халык һөнәрчеләре остаханәсенә килеп эләгә ул. Алар бире дә татар халкының традицион һөнәрләрен торгызу, саклау, аны туристларга җиткерү белән шөгыльләнәләр. Гүзәл ханымның мастер-классларына бала-чагалар гына түгел (ә алар белән уртак телне һәрвакыт таба белә!), өлкәннәр дә килә. Хәтта ир-атлар да! «Кулларына балчык алгач, алар бөтенләй үзгәрә», – дип елмая ул. Шулай, балчык әллә нәрсәләргә сәләтле! Табигатьтәге дүрт стихияне – дүрт көчне балчык кына үзендә берләштерә. Җирдә барлыкка килә. Су белән туена. Һавада кибә. Утта ныгый. Гүзәл Хәбибуллинада мастер-класста булганнар бу хакта да ишетеп китә.

Балчыкны кулына тоткан һәркем аңардан нәрсәдер әвәли аламы? Оста: «Әйе!» – дип җавап бирә. Аннан бер очракны искә төшерә. Әле пандемиягә кадәр алар остаханәсе ике көн эчендә Санкт-Петербургтан килгән 600 туристны кабул итә. Аңа мастер-класска эләккән яшь кенә бер кыз өстәл янына утырудан баш тарта: «Кулымны да пычратып тормыйм, – ди. – Дүрт ел инде сәнгать мәктәбенә йөрим, бездә дә бу юнәлеш бар. Ошамый да ул миңа, килеп тә чыкмый». «Ә сез тотынып эшләп карагыз әле, килеп чыкмаса ташларсыз», – ди Гүзәл апасы. Юлдашлары каршында бәхәсләшеп торасы килмичә генә, кыз кулына балчык ала. Ә аннан кәефе үзгәрә, күзләре очкынланып яна башлый... Рәхмәт әйтеп китә: «Кайчан да булса нәрсәдер эшли алырмын дип уйламаган идем!» – ди.

Әйе, килгән һәркемнең күңеленә сукмак та сала белергә кирәк әле. Быел 8 Март алдыннан бер егет белән кыз керәләр. «Әвәлисебез килә, тик ни икәнен белмибез», – ди алар. Күзләре өчпочмакка төшә. «Өчпочмак артык җиңел, аннан гына канәгатьлек алмассыз», – ди оста. Шулай килешәләр: егет милли бизәкле тәлинкә ясый, кызы татар милли ашлары «пешерә». Гадәттә туристлар үзләре ясаган сувенирларны алып китә, ә болар әлегә калдырган: Гүзәл ханымнан мичтә яндырып та бирүен сораганнар. «Аннан буйыйбыз һәм гомер буе саклаячакбыз», – дигәннәр. Бу да балчыкның бер үзенчәлеге. Һәр мастер-класс алдыннан Гүзәл ханым һәркемне илһамландыручы: «Сезнең куллар хәзер гомер буе сакланачак сувенир иҗат итәчәк», – дигән сүзләрне юкка гына әйтми бит.

Кылган игелекнең дә гомере озын. Авыр хәлдә калган яшь әниләргә ярдәм итү өчен оештырылган «Умиление» үзәгендә Гүзәл ханым инде бер генә мастер-класс уздырмаган. Кем белә, бәлки, аларның кайсыдыр бу эш белән чын-чынлап мавыгып китәр, ул аның өчен тормышны алып барырлык шөгыльгә әйләнер? Элеккеге «Гаврош» балалар һәм яшүсмерләр социаль приютында да еш була ул. Бүген анда өлкәннәр һәм инвалидлар өчен көндезге бүлек эшли. Балчыктан нидер әвәләү һәркайсының кулыннан, көченнән килмәсә дә, Гүзәл ханым үткәргән дәресләрне бәйрәм кебек көтәләр. Хәйриячелек – аның күңел таләбе.

– Туристлар миннән еш кына: «Сез бик бәхетледер, әйеме?» – дип сорыйлар. «Картлыгым болай бәхетле булыр дип уйламаган идем», – дим. «Сез балкыйсыз!» – ди алар. Бер көнем икенчесенә охшамаган! Бер сувенир икенчесен кабатламый! Җаным ял итә торган шөгыль...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА


БАЛЧЫК

– Күптән түгел бер ханым ике баласын ияртеп остаханәбезгә керде дә, башка беркая да карамыйча, туп-туры яныма килде. Улы белән кызын каршыма утыртып, аларга: «Менә балчык, әвәләгез!» – диде... Сөйләшеп киттек. Мәскәүләр икән. Балалардан узып, нигә нәкъ менә миңа килүенең сәбәбен беләсе килә бит... «Олысының теле начар ачылды, – дип сөйләде ул. – Дус кызым гаиләсендә дә шундый ук проблема бар иде. Мин баламны җитәкләп психологка бардым, ул логопедка язылырга киңәш итте. Ә дус кызым каяндыр: «Балчык белән шөгыльләнү булыша икән», – дигән сүзне ишеткән һәм улын шундый түгәрәккә яздырткан. Аларның телләре дә шундук ачылды, үсеш дәрәҗәсе дә алга китте. Мин хәзер кайда балчык күрәм, балаларны тизрәк шунда утыртам...



Фото: Анна Аракамия

Күптән аралаша торган танышым белән очраштык. Күреп торам: борчуы бар.
– Нәрсә булды? – дим.
– Беләсеңме, кичә миңа кызым шаккатарлык сүз әйтте. «Алга киткән илләрдә өлкән яшьтәге ата-аналар үзләре теләп Картлар йортына китә. Ә бездә балаларына йөк булып яшиләр...» – диде. Өстемә кайнар су койган кебек булды. Шундый нечкә күңелле бала бит ул! Ничек мондый фикер башына килгән, аңлый алмыйм... Бактың исә, танышымның кызы «дөрес яшәргә» өйрәтүче тренингларга йөри башлаган. Бу шуның нәтиҗәсе икән...





Руфия РӘХМӘТУЛЛИНА

Эзләнү...

Чынлап та, Талия (исемен шулай дип куям) – тәрбияле кыз. Әллә кайдан сүз башлап исәнләшә, көләч йөзле. Тик менә соңгы вакытта шәхси тормышында күңелсезлекләр килеп чыккан – озак очрашып йөргән егете белән аерылышкан, сәламәтлеге белән дә проблемалар бар икән. Әлбәттә, ана кеше (минем теге танышым) кызы өчен бик борчылган. Табибларга да барганнар, өшкерүче әбиләр дә калмаган. Эзләнә торгач, Талия интернетта бер психологның битенә юлыккан һәм шул ханымга онлайн консультациягә язылган.

– Кызым психолог белән аралашуны бик ошатты, – дип сөйләде танышым. – «Әни, мин яңадан туган кебек булдым», – диде. Дөресен генә әйткәндә, ул психологның сөйләмен колак очым белән генә ишетеп алдым. Бөтенләй ят нәрсәләр сөйли. «Иң беренче үзеңне уйла. Шулай булганда гына сиңа хөрмәт белән караячаклар», – ди. Мин инде кызым белән бәхәсләшеп тормадым, депрессиягә кереп китмәсен дип борчылдым. Шуңа күрә психолог яки бүтән кеше белән аралашамы, булышсын гына дип уйладым...

ТРЕНИНГЛАР НӘРСӘГӘ ӨЙРӘТӘ?


Фото: www.pixabay.com

Талиягә психолог белән аралашу шуның кадәр «ярдәм» иткән ки, хәтта әнисен Картлар йортына җибәрүне фаҗигагә санамый башлаган. Иң аянычы – бүген өлкәннәрнең Картлар йортында яшәвен норма, начар урын түгел дип санаучы яшьләр күп икән. Бигрәк тә кыз балалар арасында! (Егерме–утыз яшькәчә балалары булган ата-аналар белән дә сөйләштем. Тренингларга еш йөрүче яшьләр моны үзләре дә яшерми.)

Тренинг, коучинг, марафон, курслар... аларның исемнәре төрле. Ә нигезе – нәрсәгә булса да өйрәтүгә корылган. Анысы да монысы, бүген һәр теләгән кеше шулай үзен «акыл өйрәтүче» дип атый ала. Ә нәрсә, шундый ук түләүле курсларда «бик тирән» белем алып чыгасың да, тренер, коучер, остаз буласың. Әлбәттә, башта үзеңә социаль челтәрләр аша шәп реклама ясарга кирәк. Затлы машинаңны, өч катлы йортыңны, Мальдив утрауларында ял иткән фотоларыңны куясың. (Аларның күбесе фотошоп була, ләкин кем аны тикшереп торсын ди.)

Тренингларның нинди генә төре юк – җитәкчеләргә, хатын-кызларга, яшүсмерләргә, яшь туташларга (уңышлы кияүгә чыгарга өйрәтәләр)... Элек алардан башка ничек яшәгәннәр дә, ничек эшләгәннәр диген? Гаҗәп инде менә!

«Өйрәнәм!»

Әлбәттә, бөтен кеше минем кебек уйламый. Дистә еллар буена тренингларга йөргән кешеләр бар. Һәм, чынлап та, аларга ул тормышта ярдәм дә итә. Үзләренә яңа шөгыль табучыларны да беләм. «Төрле комплексларым юкка чыкты»,- диючеләр дә бар. Кемдер үсәргә, яңа белемнәр тупларга дип йөри. Мисал өчен, Казанда яшәүче Ландыш Гәрәева әнә шундыйлардан. Бу юнәлештә күпме акча түккәнен, никадәр лекцияләр тыңлаганын ул үзе дә белми, әмма ул канәгать.

– Тагын бер түләүле онлайн курсларга язылдым әле, – диде.

Ландыш – югары белемле ханым, кияүдә. Беренче сөйләшүдә бик акыллы диган тәэсир калдыра. Туры Тукайлыгымны эшкә җигеп сорап куйдым:

– Фикерсез кешегә охшамагансың. Ул түләүле тренинг, курслар нәрсәгә кирәк? – дидем.

– Бу белемнәрне мин бер көндә генә алмадым. 18 яшемдә Мирзакерим Норбековның семинарларын

PRESSA



Рөстәм хәзрәт ХӘЙРУЛЛИН, «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы

– Тренингларга йөрүгә тискәре карыйм дип әйтә алмыйм. Әмма... үсеш өчен. Әйтик, син яңа һөнәр үзләштерергә, үсәргә телисең. Мондый вакытта аның начарлыгын күрмим. Әйе, бүген тренинглар бихисап. Кызганыч, аларның күбесе эгоизм тәрбияли. Ә Ислам динендә эгоизм гөнаһ санала. Уйлап карасаң, үзе өчен генә яшәгән кешенең картлыгы матур булмый. Янәшәңдә тормыш иптәшең, балаларың, оныкларың йөгереп йөрмәсә, ни кызыгы бар?

Ата-ананы йөк дип карауга килгәндә... «Җәннәт ишекләре әти-әниләрнең аяк астында» дигән сүзләрне һәркайсыбызның ишеткәне бар. Беркөнне Рәсүлебез (с.г.в.) урамга чыккач, елый торган бер шәкертне күрә. «Ни булды?» – дип сорый ул аннан. «Йә, Рәсүл (с.г.в.), җәннәт ишекләренең берсе ябылды, әнием вафат булды, – ди шәкерт. – Ул нәрсә теләсә, нәрсә сораса, мин барысын да эшләдем, барысын да таптым. Әниемә әманәтне бирә алдым-мы?» – дип сорый. Рәсүлебез (с.г.в.) аңа болай дип җавап бирә: «Син аны гомер буе кулыңда күтәреп йөртсәң дә, сине тапканда кичергән авыртуга бәрабәр бернәрсә дә, беркайчан да булмас».

Картайган көндә ата-анасын карау – баланың бурычы. Мөселман илләрендә, шул ук Чечняда да Картлар йорты юк. Чөнки анда ата-аналарны ташламыйлар. Балалары булмаса, өлкән кешене туганнары үз карамагына ала. Кызганыч, бездә хәл бүтәнчә...

Без гел әйтәбез – гаиләне туендыручы ир-ат булырга тиеш. Ә хатын-кыз гаилә учагын саклаучы. Ата-анасын карауны да ир-ат үз кулына алырга тиеш – хатынына матди, мораль яктан булышу турында сүз бара. «Тормыш авыр, икебезгә дә эшләргә кирәк. Өлкән яшьтәге әти-әнине карау авыр», – дип еш кына киләләр. Бу хәлдә калучыларга җавабым бер – Аллаһы Тәгалә андый чакта йортка бәрәкәт бирә ул, булганы җитә. Өлкән яшьтәге ата-ананы караудан һич тә баш тартырга ярамый!

тыңлый башлаган идем. Шуннан китте инде... Өч ай саен яңа курслар, китаплар сатып алам. Заман үзгәрә бит хәзер. Яшәү рәвешебез, тормыш фәлсәфәсе элеккеге кебек түгел. Тормыш үзе ниндидер проблемалар китереп чыгара. Аларны үзең генә чишә алмаган очраклар була. Менә шул вакытта тренерлар, остазлар көч бирә... Ул бик тирән белемнәр. Аны куллана да белергә кирәк. Әгәр ниндидер проблеманың төбенә төшәсең килсә, махсус китаплар укырга, шундый семинарлар, тренинглар тыңларга кирәк.

– Ландыш, – дим. – Яшерен-батырын түгел, үзләрен остаз дип әйтүче ул тренерлар барысы да диярлек түләүле хезмәт күрсәтә. Син моны халыктан акча җыюның бер төре дип карамыйсыңмы?

– Әйе, күбесе түләүле. Ләкин бүген бушка хезмәт күрсәтүче нинди кеше, оешма бар соң? Минем түләүсезен дә, ташламалы тренингларны да үткәнем бар. Тик бушка сыр капкында гына була. Башлангыч тренерлар, блогерлар миңа кызык түгел. Алар хәтле инде үзем дә беләм.

– Алайса үзеңнең дә шундый остаз буласың килмиме соң?

– Ул турыда уйлаганым бар. Тик әлегә алынырга кыюлык җитми, җаваплылыктан куркам. Клиентларга дөрес җавап бирмәсәм, аларны ялгыш юлдан җибәрермен дип борчылам.

– Акыл өйрәтүгә корылган курслар, тренинглар бик күп бит. Син аларны ничек сайлыйсың?

– Мин башта ул кешене бик җентекләп өйрәнәм. Интернет аша аны ярты, бер ел буена күзәтеп барам. Дөресен әйтим, фәкать акча эшләү максатыннан оештырылган курслар да күп. Шуңа күрә монда кат-кат уйларга кирәк. Тренерга чынлап торып ышангач кына курсларны сатып алам. Беренче карашка, бәлки, бу сәеррәк тоеладыр. Аларны тыңламыйча да рәхәтләнеп яшәп яталар бит. Ләкин бу миңа кызык, кешенең психологиясен ачасың, өйрәнәсең.

Ландыш тренингларда үзеңне яратырга өйрәткәннәрен яшерми. Әти-әниләргә мөнәсәбәткә килгәндә...

– Әйе, «Без әти-әниләргә бернәрсә дә тиеш түгел», – дигән фикерне алга сөрү бар, – диде Ландыш. – Янәсе, без җавап йөзеннән аларга гомер бүләк итә алмыйбыз. Ә ярдәм итүгә килгәндә, тормышлар авыр, яшьләргә бүген беркайдан да ярдәм юк. Ә әти-әниләргә дәүләт булышкан. Имеш, әле тагын балаларыннан өмет итеп яталар... Яшь кеше үзе өчен кайчан яшәргә тиеш? Аңа кем ярдәм итәр? Менә шундыйрак фикерләр. Бер яктан карасаң, алар хаклы да – яшьләргә бүген бик авыр. Ул әти-әнисенә ярдәм итәр хәлдә түгел. Икенче яктан... ата-бабалардан килгән тәрбия, әти-әнигә ихтирам дигән төшенчәләр бар. Әгәр яшь кешенең канына бу кыйммәтләр сеңгән икән, берниндди тренинглар да балада ата-анасына булган хөрмәтне, мәхәббәтне бетерә алмый. Ул сыйфатлар гаиләдә кечкенәдән тәрбияләнергә тиеш...

Ачы чынбарлык...

Инде ата-анага хөрмәт темасын дәвам итеп... Картлар йортына килик. Бу сүз безнең өчен бик шомлы яңгырый. Әйе, соңгы елларда аларны матурларга, өлкәннәр өчен уңайлы итәргә тырышалар. Шулай да биредәге тормышның асылын аңлау өчен Картлар йортына бер барып карау да җитә. Гаҗизлек... Күзләрдәге сагыш... Анда яшәүчеләрне ефәк юрганга төреп йоклатсаң да, алар үзләрен барыбер кимсетелгән, ташландык итеп хис итәчәк. (Узган ел Буа шәһәрендәге Картлар йортында булган идем. Тимер рәшәткәләр артыннан кул болгап калган әби әле

һаман күз алдымда.) Нишләтәсең, Картлар йортында яшәү безнең халыкка, безнең дингә хас түгел. «Артык кашык» булганнар гына бирегә килеп эләгә кебек.

Медальнең икенче ягы турында да әйтми булдыра алмыйм – Картлар йортында «дедовщина» да бар. Моңа гаҗәпләнәсе түгел – күп гомерен төрмәдә үткәргән кешеләр картлыгын йорт-җирсез, туганнарсыз каршы ала. Андыйларга бердәнбер юл – Картлар йорты. Ә алар бүреләр законы буенча яшәргә өйрәнгән, биредә дә шундыйрак тәртип урнаштырырга омтылалар. Гомере буе эчкән ир-атлар, хатын-кызлар... барысы да шушы урында очраша. Аяныч, әмма бу шулай. Ә хәзер шулар янында ак яулыклы әбине яки түбәтәйле бабайны күз алдына китерик... Ул анда нинди хисләр белән яшәячәк?! Күрәсең, теге танышымның кызы бездәге Картлар йортына барып караганы юк...

Ә менә әлеге тренинг, марафоннарның башлангычы саналган Америкада... Картлар йорты «артык кашыклар» урыны булып саналмый. (Мөгаен, теге акыл өйрәтүче тренер, остазлар чит илләрдәге әби-бабайларның ничек яшәүләрен күргән, ә безнекен юк.) Америкалы әби-бабай өчен, киресенчә, өйдә ялгызы утыру гайре хәл. Алар өчен биредә интернатлар, клублар эшли. Көнен яшьтәшләре янында уздырган әбибабай, кичкә өенә кайта. Инде сәламәтлеге начар икән, махсус шундый йортта яшәргә кала.

Бүгенге көндә Нью-Йоркның Брайтон-Бич районында яшәүче Казан кызы Наилә Бикчәнтәева өлкәннәр өчен бакчада эшли (үзләре шулай дип атыйлар).

– Брайтон-Бичны руслар яши торган район дип әйтергә була, – дип сөйләде Наилә. – Рус телле өлкәннәр өчен бакчада эшлим. Әйе, бу беренче карашка сәеррәк кебек. Россиядә бакчага балалар гына йөри, ә Америкада өлкәннәр өчен дә шундый урыннар бар. Ул тулысы белән дәүләт карамагында. Иртән махсус автобус өлкәннәрне өйләреннән җыеп йөри, кичен кайтарып куя. Әби-бабайлар биредә өч тапкыр ашый, күңел ачалар, йоклыйлар. Аерым көннәрдә чәч кистереп, маникюр ясатып була. Берәүләр шахмат, шашка уйный, икенчеләр спорт белән шөгыльләнә.

Әйткәнемчә, безнең бакча рус телле өлкәннәр өчен. Алар арасында элек Татарстанда, Казанда яшәгән кешеләр дә бар. Менә шулай картлык көннәрендә Америкага килеп эләккәннәр. (Кемдер балалары янына килгән, кайсындыр танышлары чакырган.) Әби-бабайлар җыелып, яшь чакларын искә төшерәләр, җырлыйлар, бииләр. Мин бу хәлгә башта бик аптырадым. Россиядә бит өлкәннәр өчен мондый урыннар юк. Безнең әби-бабайлар сигез мең сум пенсиясен ничек даруга, фатир өчен түләргә җиткерү турында уйлый. Ә Америкада картлык бүтәнчә уза.

...Кызык инде без: тотабыз да чит илләрдән бер яңалык кертәбез. Шул ук тренинглар аларда әллә кайчан бар иде. Бездә соңгы елларда гына популярлашты. Кертүен керттек тә, безнең халык, тәрбия, яшәү рәвеше, мөмкинлекләр бүтән икәнлеген оныттык... Картлар әйтмешли, Аллага тапшырдык инде. Барыбызның да әби-бабай буласы бар.



Чулпан НИГЪМӘТҖАНОВА, психология фәннәре магистры, психолог

– Бүген кешелек ныклап торып үзен өйрәнә башлады. Балачагын, үткәнен анализлый, бу хәтта ниндидер бер яшәү рәвешенә әйләнде...

Яңалык түгел – безнең әби-бабайлар ул турыда уйланмаган. Аларның максаты – тамак туйдыру, балаларын аякка бастыру булган. Әлбәттә, аларның да ирләре, балалары белән бәйле проблемалары чыгып торган. Тик тирәнгә кереп анализлап утырырга, үзендә казынырга аларның вакытлары булмаган. Ә бүген... Аллага шөкер, тамак проблемасы юк. Кешелек дөньясын икенче әйберләр кызыксындыра башлады. Җитмәсә, көн саен интернет челтәреннән безгә бу хакта тукып торалар. Ата-аналар белән балалар мөнәсәбәтенә килгәндә, соңгы елларда психология белән бәйле китаплар, курслар, марафоннар – барысы да бер фикерне алга сөрә: «Бөтен проблемалар да – балачактан». Янәсе, әти-әни безне үскәндә мактамаган, күңелне аңламаган... Әйдәгез, тирәнрәк уйлап карыйк: әти-әниләребез үзләре дә шулай үскән, аларны да күккә чөюче булмаган. Ягъни алар тәрбияне шулай булырга тиеш дип кабул иткән. Алар безне дөньяга тудырган, ашаткан, киендергән, укыткан. Әлбәттә, ялгышлыклары булгандыр, тик хәлләреннән килгәнчә, мөмкинлекләре булганча тәрбияләгәннәр бит! Менә шуны истән чыгармаска иде.

Кызганыч, бүген һәр кеше үзен акыл өйрәтә алам дип саный. Бернинди махсус белеме, тәҗрибәсе булмаган кешеләр төрле курслар үткәрә. Нәтиҗәдә, ул кешенең проблемасын ача, ләкин япмый. Ә бит ул проблемаларны «эшләп» бетермәсәң, кешедә җитди психологик авырулар башланырга мөмкин. Шуңа күрә мондый профессиональ булмаган тренерларны хәтта куркыныч, дияр идем. Соңгы бер елда мондый курслар, тренинглар берничә тапкырга артты. Һәм бу дөнья буйлап шулай. Моның сәбәбе бик гади – пандемия сәбәпле, кешеләр өйдә утырды. Һәм аларның буш вакытлары барлыкка килде. Нәкъ менә шул чорда күпләр үзләрендә казына башлады.

Йомгак ясап шуны әйтәсем килә: сезне еш борчый, тынгы бирми торган проблемагыз бар икән, белгечләргә барыгыз. Әллә нинди курслар сатып алганчы, уйлагыз: сезгә ул нәрсә бирер? Психолог буларак шуны әйтәм: эшсез тормагыз. Начар уйлардан, депрессиядән бары эш коткара. Буш вакытыгыз калмасын! Үзегездә артык казынмагыз, кичерә белегез. Урамда кояш, рәхәт. Һавада йөрегез, якыннарыгыз белән аралашыгыз... Дөнья матур!

МИН – ХАТЫН-КЫЗ!

Ул – татар эстрадасының иң зәвыклы һәм үзенчәлекле тавышлы җырчыларыннан берсе. Җырлау манерасы да, сәхнәдә үз-үзен тотышы да бөтенләй башка. Аны салкын дип уйлаучылар да бар. Әмма сөйләшә башлагач, аннан бөркелгән җылылыкка, якты бер энергетикага төренәсең. Һәрнәрсәдә матурлык һәм камиллек яраткан, үзе дә шуңа омтылган җырлар авторы, телевидение алып баручысы, киноактриса, продюсер, Татарстанның атказанган артисты Алсу АБУЛЬХАНОВА белән сөйләшәбез.



Алсу, Воркутада тугансың, Ульяновскида яшәгәнсең, хәзер син – Казанда. Воркутадан бу якларга нинди юллар алып килде?

– Әти-әнием тумышлары белән Чүпрәледән. Алар бәхет эзләп Воркутага чыгып китkән. Миңа 13 яшь чакта гаиләбез Ульяновскига күченеп кайтты. 90 нчы еллар – бик авыр чор иде ул. Әти белән әнигә барысын да өр-яңадан башларга туры килде. Казанда туганнарыбыз түгел, танышларыбыз да юк иде. Үсмер чагымда әни белән Казанга бер килдем – ошамады. Ульяновскидагы гаилә дустыбыз Әлфия Рамазанова татар җырларына мәхәббәт уятты миндә. Аңа кадәр бөтенләй татар эстрадасын белми идем. «Алсу, сиңа Казанга китәргә кирәк», – диде ул. 19 яшемдә Казан консерваториясенә укырга керергә килдем. Шәһәр үзгәргән иде инде. Яраттым. Монда калам дип, үземә сүз бирдем һәм сүземдә тордым. Казан – безнең горурлыгыбыз ул.

Рус мохитендә үсеп, татар телен ничек саклап кала алдың?

– Безне җәй башлануга әбигә кайтарып куялар иде. Кайтканда татарча ватаҗимерә сөйләшсәк, киткәндә инде рәхәтләнеп аралашабыз. Шуңа да тел өйрәнү өчен авыл, әби тәрбиясе кирәк ул. Безнең әби «Азат хатын» журналы алдыра иде. Шуларны актарырга ярата идем, тырыша-тырыша укыдым да. Тышлыклары бик ошый иде. Аннан соң өйдә дә әни белән әти гел татарча сөйләште. Кечкенәдән ул да кереп калган. Казанга килгәч, чынлап торып татарча өйрәнергә тотындым. Ана телен белмәгәнгә ояла идем. Татар мохитендә эшли башлагач, үзеннән-үзе сөйләшә башладым. Казанга килгәндә «Татар җыры»н алып барачаксың дип әйтсәләр, ышанмаган булыр идем.

Күпләр сине «Татарстан–Яңа гасыр» каналының алып баручысы буларак та белә. Бу өлкәгә кире кайтырга уйламыйсыңмы?

– Әйе, 20 ел шәһәр филармониясендә эшләү дәверендә мин дикторлык һөнәрен дә үзләштердем. Балачак хыялым иде ул. Кечкенә чакта уенчыклар белән уйнамадым, телевизор каршына утырып, программа белән «таныштыра» идем. Имеш, диктормын... Хыялымны тормышка ашырасым килде. Әмма һәрнәрсәдә профессиональлек яратам. Дилетантлык минеке түгел. Эшкә тотынасың икән, камил булырга кирәк. Ул бит үзеңә хөрмәт, җитмәсә, ышаныч та өсти. Шуның өчен Мәскәүдә «Останкино» телевидение мәктәбендә укып кайттым. Үзебездә «Доброе утро» тапшыруын алып бардым. Ике ел эшләгәннән соң киттем. Ябалак мин. Иртән эшләү биосәгатьләремә туры килмәде. Кызыклы проектка алынып идем. Әмма альтернатива кирәк, бер суга ике тапкыр кермиләр. Камера каршында эшләргә бик яратам. Курыкмыйм мин аннан. (*Көлә.*)

Кино артисты да бит әле син! Татарстан фильмнарында гына түгел, казакъ-татар киносында да төштең.

– Үземне бик озак актриса дип атарга кыймадым, чөнки махсус белемем юк. Дөрес, консерваториядә актерлык курслары үттем. Берничә фильмда катнашу минем өчен зур эксперимент булды. Тормышта бирелгән бөтен мөмкинлекләрне куллану ягындамын. Кинода төшәргә чакыралар икән, роль ошаса, рәхәтләнеп алыначакмын.

Син сәхнә өчен яратылган матурлык алиһәсе кебек. Тормышта – пәрдә артында Алсу нинди?

– Өйдә бөтенләй башка кеше мин. Көндез бизәнеп йөри алмыйм. Юынам, чәчемне җыям да чыгып китәм. Шулай уңайлы. Ә сәхнә ул башка! Анда зәвык, матурлык булырга тиеш. Сәхнәдә миңа шулай рәхәт. Аннан соң бу бит тамашачыга да хөрмәт. Дөрес, биек үкчәләр белән тормышта да йөрим.

Матурлык серең бармы?

– Бу хакта сөйләшергә яратмыйм. Үземне эталон дип тә санамыйм. Мин – хатын-кыз. Беренчедән, йөземне бик саклыйм. Һәрвакыт ян белән генә йоклыйм, минераль су белән генә юынам. Бу битне уята. Йөземне «тотам», ягъни һәрвакыт туры сын, бераз гына калку ияк, сызылып киткән каш... Андый хатын-кызларга каравы да рәхәт.

Хәзер социаль челтәрләр аша танылу популяр. Ә менә синең социаль челтәрләреңдә хайп та юк, гаиләңне дә артык күрсәтмисең...

– Беренчедән, ирем яратмый. «Син – артист, без артистлар түгел», – ди ул. Икенчедән, үзем дә шәхси тормышымны ачып салу ягында түгел. Чикләремне саклыйм, дип әйтимме соң?! Һәр адымнан хайп ясап, бөтен негативка түзгән кешеләргә һәйкәл куяр идем. Мин алай булдыра алмыйм.

Бүгенге иҗатыңда нинди планнар белән яшисең, Алсу? Яңа төркем дә төзедең бит әле...

– Бу идея белән күптән яна идем инде. Казанга килгәндә рус, инглиз җырлары җырлый идем, татарча җырлар өйрәндем, әмма бик күп тапкырлар безнеңчә җырламыйсың, дигән сүзләр ишеттем. Эзләндем. Үзгәрергә, яраклашырга туры килде. Европа манерасы белән җырлаудан киттем. Әмма ул минем хыял булып калды. Хәзер менә шуны тормышка ашырыр өчен яшь башкаручылар белән «Кара урман» төркеме төзедем. Алар төрле телдә җырлыйлар, әйбәт бииләр. Янып торалар, талантлылар.

Димәк, син хәзер продюсер да?

– Бу сүз бик яңгыравыклы, әлбәттә. Әмма уйлап карасаң, шулай булып чыгадыр ул! Төркемгә финанс кына түгел, җанымны да салам. Яшьләр – Тимур, Рамазан, Алина, Эльвина белән эшләү рәхәт. Алар мине рухландыра. Җырлар яздырдык, алар өчен махсус репертуар төзедек. Әле менә клип төшердек, тиздән тамашачыларга тәкъдим итәчәкбез. Без әле яңгырарбыз...

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Фәнис САДЫЙКОВ
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.





БЕРГӘ БУЛГАНДА



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Әбигә көн саен әйтәм: «Әле яшәсәк иде», – дим. Тормышыбыз бик рәхәт бит. Тәрбиядә, карауда, аягыбыз йөреп тора... Юк, китәсе килми әле... Бер-беребезгә иптәш без. Икәү шулай сөйләшеп утырабыз. Үткән гомерләрне искә төшерәбез, күргәннәрне, баштан кичкәннәрне...

Бу йортта Фәния һәм Галимҗан Зариповлар – Балтачның Ак әбисе белән Ак бабае яши. Тагын аларның төпчек уллары Азат һәм киленнәре Диләрә. Яраткан оныклары (янында үскән оныклар башкача якын була бит ул!) – Ирек, Динә, Азамат. Бу түбә астында Ярату яши! Әйе, бу язма Ярату турында. Хәер, аның турында гына да түгел...





// Диләрә: «Район үзәгендә яшәсәләр дә, Азатлар өйдә татарча гына сөйләшеп үскән. Без бүген дә өйдә татарча гына сөйләшәбез. Кызың яки улың кайтып сиңа русча әйткәнгә русча җавап бирә башласаң, аннары нәрсә була ул?! Балалар гимназиядә дә үзара татарча аралашалар. Балтачта ул яктан хәлләр шөкер әле...»

Өлкәннәр

КАВЫШУ ТАРИХЫ ТУРЫНДА. Балтачта «Стахановчы» әртиле бар иде. Шунда ат караучы булып кердем. Миңа бу вакытта 23 яшь. Кызларны урманга илтеп куям, алып кайтам. Юкә кабыгын төшерәләр дә, суга салалар, аннан мунчала ясыйлар... Арада Фәния дә бар. Күз гел аңарда... Сосна авылы кызы икәнен дә белдем. Бер көнне бу миңа: «Безгә менегез, Соснада вечерлар бик күңелле уза», – ди. Мендем шулай. Вечер бетте, чыгып сөйләшеп торабыз. Мөдәрис дигән егет белән икәү идек, ул берәүләрнең хуҗалыгына куеп калдырган атыбызны алырга китте. Ул килүгә янымдагы кызга: «Әйдә, Фәния, киттек безгә!» – дидем. «Юк, беркая да бармыйм», – ди. Күтәреп алып тарантаска утырттым да, төшеп киттек Балтачка. Инде: «Өйгә кермим!» – ди. Һаман әле ышанмый килен булып төшкәненә. Артыбыздан әнисе килеп җитте, аннан абыйсы. Килештек инде... Без ул төнне йокламадык, сөйләшеп кенә чыктык. Өйдә бер әти генә. Аңа инде 78 яшь. Кайтсам да, китсәм дә гел бер сүзне кабатлый иде: «Өйлән инде, улым!» Әни мин төрмәдә утырганда мәрхүм булган. Анысы үзе бер тарих... 1949 елны Балтачтан 8 чакрымдагы Көекбаш ягында колхозда ашлык ташып йөрим. Солы урган чак. Әни: «Тез белән генә сындырып бирә торган утын алып кайтып бир әле, улым», – дип сораган иде. Коры утын җыйдым, кайткач атка ашатырга дип, ярты капчык солы алдым һәм кичен юлга кузгалдым. Балтачны кергәндә колхоз рәисе белән авыл советы секретаре очрады. «Нигә ашлык урынына утын төяп кайтасың?» – дип бәйләнделәр. Арбамны аудардылар, ә анда атка дигән ярты капчык солы... Бер атна эчендә суд булды. Биш елга утырттылар. Өч ел да җиде айдан әйләнеп кайттым, тик әни бу хәсрәттән мәрхүм булган иде инде...

Иртәгәсен никах укыттык. 1953 елның 1 сентябре иде бу. Безнең уртак тормыш шул көнне башланды. Фәниягә бу вакытта 22 яшь. Бусаганы атлап керүгә җиң сызганып эшкә тотынды ул. Шактыйдан хатын-кыз кулы тимәгән йорт бит... Аш пешергәндер инде башта. Ул чакта көн саен өйдә аш пешә иде бит.

БАЛАЛАР ТУРЫНДА. 1954 елның июнендә беренче улыбыз Рөстәм туды. Аннан Сәрия кызыбыз. Фоат... «Сельхозхимия»дә өлкән агроном иде. Ул юк инде, авариягә очрап вафат булды. 31 яшьтә... Бер кызы калды... Фоаттан соң Фәргатьне алып кайттык. Төпчегебез Азат исә 1969 елны туды. Декрет еллары озын түгел иде бит – Фәния эштән калмады. Аның белән бергә эшләгән кызлар: «Без төшке ашка тамак ялгарга туктыйбыз, ә Фәния апа шул арада Соснага – әнисенең хәлен белергә йөгерә иде. Көн саен! Әнисе белән кара-каршы утырып чәй эчәргә дә өлгермәгәндер, әмма барыбер бара иде», – дип, соңыннан да озак сөйләделәр. Башкача вакыт юк бит – ял көннәре өйдән, балалардан бушамый. Малайларны әти карт карады безнең. Балалар бакчалары юк иде әле. Капканы ачып чыгуга Чепья юлы. Ул чактагы зур юлларның берсе. Бүгенге кебек булмаса да машиналар йөреп тора. Балалар өчен барыбер курка идек инде...

АКЧА ТУРЫНДА. Өйдә әти хуҗа иде, әлбәттә. Акчаны да аңа кайтарып бирәбез. 87 яшендә вафат булды ул. Урамнан: «Уф, арыдым», – дип кереп сандык өстенә утырды да, китеп тә барды... Аннан акча әбиегез кулында булды. Бик белеп тотты ул – юкка-барга әрәм итмәде. Миңа караганда, балаларга карата да кырысрак булды, каты тотты... Һәрберсен укыттык, башлыкүзле иттек... Пенсияләребез әйбәт, шөкер. Эшләмәсәк тә, китереп торалар. Балаларга булыша алу сөенеч хәзер безнең өчен.

ЙОРТ САЛУ ТУРЫНДА. 1939 елда, бәхет эзләп, гаилә белән Әстерхан якларына киткән идек. Әмма анда әтигә һава торышы килешмәде, шулай итеп, кире кайттык. Ә монда инде нигезне сатып киткән идек... Кайткач, ферма өендә торып тордык. Мин төрмәдә утырганда әти мунча бурасы сатып алып, шуны Балтачта өй итеп салып чыккан иде. Өчкә дүрт зурлыкта гына иде ул. Балалар тугач бигрәк тә кысрыкланды. Яңа өй кирәк иде... Балта эшенә үзем тотындым. Башта ял көннәрендә генә эшләдем. Киров якларына да чыгып китеп кешеләргә йортлар, мунчалар салып йөрдек. Эшләмәсәң, акча кайдан килсен. Кемгәдер ышанып торырга юк иде... Йортны 1958 елда гына салып чыктык. Үз көчебез белән.

ОНЫКЛАР ТУРЫНДА. Күп инде алар безнең... 11 онык, 19 оныкчык... Балалар барысы да үз тирәбездә – Балтачта төпләнделәр. Оныклар күз алдында үсте. Аллага шөкер, хөрмәт итәләр, әби, бабай, дип кенә торалар. Кайтсалар – әйтәләр, китсәләр: «Ярар, әби-бабай, киттек!» – дип саубуллашалар. Анысына да сөенәбез... Диләрә киленебез дә бик акыллы булды. Бер авыр сүз әйткәне юк. Азатның төпчеге Азамат белән дус инде без. Быел 1 нче класста укый ул.

ОЗЫН ГОМЕР ИТҮ ТУРЫНДА. Болай озак яшәрмен дип кем уйлаган?! Әти – 87, әни 56 яшендә үк мәрхүм булдылар. Миңа узган елның ноябрендә 90 тулды менә, әбигә – быел февральдә. Сере дип... Тыныч булырга кирәк, юк-барга борчылмаска. Без әби белән ачуланышып яшәмәдек, бигрәк тә балалар алдында. Үпкәләшеп торсаң, тормыш бармый бит ул. Бер-береңне тыңларга, юл куярга кирәк.

Яшьләр

КАВЫШУ ТАРИХЫ ТУРЫНДА. Минем Сбербанкта эшләгән чагым. Ә Азатның кредиты бар – ай саен шуны түләргә керә. Туксанынчы еллар ахырында Балтыйк буеннан машиналар алып кайтып сатты ул, шуңа алган булган. Айның соңгы көннәре җитсә, кемнең кредиты бар, шуларга шалтыратырга керешәбез: алар вакытында түлә-







мәсә, безнең дә премияләрне кисәләр. Ә Азат: «Иртәгә керәм», – ди дә югала – ай ахырында аңа гел эше буенча Казанга барырга кирәк иде. Үз акчамны түләп торам. Беркөнне кич җәяү генә кайтып барганда очрады. Өйгә кадәр озатып куйды. Шул көннән соң очраша башладык. Аңа – 30, миңа 25 яшь иде бу вакытта... Туебыз көнне яңгыр яуды. Кунакларга гараж эчендә генә биергә туры килде. Һәм шул вакыт алар Азатның машиналарга компьютер диагностикасы үткәрү белән шөгыльләнүен күрделәр. Район буйлап хәбәр таралды... Азат Балтачта бу эшкә беренче булып тотынды.

ЭШКӘ ӨЙРӘНЕП ҮСҮ ТУРЫНДА. Җиденче класста укыганда өйдә балалардан берүзем генә идем инде. Абыйлар кайсы укуда, кайсы инде гаиләле... Бездә эш беркайчан хатын-кызныкына, ир-атныкына бүленмәде. Мәктәптән кайтуга, колонкадан су ташыйм, мичкә ягам, мал асларын җыештырам. Тиресне көн саен аз-азлап чыгарам, шулай итсәң, атна ахырына буш вакыт күбрәк кала. Идәннәр буялмаган иде безнең – атнага бер тапкыр мунчалалап юып чыгарам. Чисталыкны кечкенәдән яраттым... Әти тирәсендә йөргәч, балта эшен барыбыз да өйрәнеп үстек. Армиягә киткәнче дә, кайткач та Карадуган мебель фабрикасында эшләдем. Иске өйдә торган стенканы шул вакыт үзем җыйган идем. Армиядә Мәскәү янында хезмәт иттем. Берсендә өйдән посылка килде. Нәрсәнедер район газетасы битенә төреп җибәргәннәр. Бер хәрефен калдырмыйча укып чыктым. Балтачта крахмал продуктлары әзерли торган завод төзи башлаулары турында да хәбәр бар иде анда. Шушы юнәлештә укырга кирәк дип уйлап куйдым. Мәскәүдә! Барысы да мин хыялланганча булды. Яңа заводка тәэминат бүлеге начальнигы итеп чакырдылар. Читтән торып Мәскәү азык-төлек институтын тәмамладым. Кызганыч, СССР таркалгач, завод та озак яшәмәде. Туксанынчы еллар ахырында инде үз эшемне ачтым... Төп нигездән китү уе ялгыш та башыма кергәне булмады. Кемдер калырга тиеш бит!

БАЛАЛАР ТУРЫНДА. Улыбыз да, кызыбыз да бар иде инде, аннан өченчегә тәвәккәлләдек. Азаматны 39 яшемдә алып кайттым. Бер дә үкенмим!

Азат ягы җыр-моңга бай. Җырчы Гөлзадә апа Сафиуллина белән кайнанам туганнан туганнар. Азат та баянда уйнаштыргалый. Күптәнге баян инде ул. Әниләр аны Рөстәм абыйга кечкенә чакта алып биргән булган. Юклык чагында да шундый мөмкинлек тапканнар... Музыкага тартылу безнең балаларда да бар. Дөрес, Ирек баян классында бер ел гына укыды да ташлады. Аңа видео төшерү күбрәк ошый. Ул Казан Энергетика университетында укый. Ә Динә музыка мәктәбен «бишле» билгеләренә генә тәмамлады. Фортепианода, гитарада һәм курайда уйный. Оештыру эшләрен ярата ул, классларында староста. «Орленок» лагерена путевка белән бүләкләнде. «Сәләт» форумнарын калдырмый. Гөлләр үстерү белән мавыга әнә.

ТЕЛ ТУРЫНДА. Район үзәгендә яшәсәләр дә, Азатлар өйдә татарча гына сөйләшеп үскән. Без бүген дә өйдә татарча гына сөйләшәбез. Кызың яки улың кайтып сиңа русча әйткәнгә русча җавап бирә башласаң, аннары нәрсә була ул?! Балалар гимназиядә дә үзара татарча аралашалар. Балтачта ул яктан хәлләр шөкер әле... Динә татар теле дәресләрен бик ярата, олимпиадаларга катнашып урыннар да алганы булды. «Тугызынчы класста татар теленнән дә имтихан бирәм», – дип торган иде. Кызганыч, бетерделәр... Ирек берсендә Илшат абыйсына телефоннан русча нидер язып җибәргән. Кинорежиссер Илшат Рәхимбай безнең Сәрия апаның улы бит. Аның белән барыбыз да горурланабыз!.. Илшаттан хәбәр булмаган... Соңыннан аңлашканнар – нәкъ менә русча язганга җавап бирмәгән икән. Энесенә яхшы сабак булды бу!

ЙОРТ САЛУ ТУРЫНДА. Бер ел элек кенә күченгән бу өч катлы йортыбызны ун елга якын төзедек. Төп нигез шундый зур, иркен булырга тиештер ул: бәйрәмнәрдә иллешәр кеше җыелабыз бит. Аны җиткереп керергә безгә бөтен туганнар булышты: минекеләр дә, Диләрәнекеләр дә. Төзи башлаганда әти белән әнигә сиксәнешәр генә яшь иде бит әле – бездән уздырып ком-таш, балчык ташып йөрделәр. Иң тынгысызы әни иде: ул безне кечкенәдән бүгенге эшне иртәгәгә калдырмаска өйрәтте.

Өйнең һәр сантиметрына кадәр үзем уйладым. Кайда, нәрсә буласын, нинди материал кулланасын... Бөтенесен булмаса да, күп нәрсәне үз кулларым белән эшләдем. Тәрәзәләрнең һәммәсен – ә алар егерме дүртәү – олы улым Ирек белән икәү куйдык. Йорт эчендәге һәммә нәрсә сәламәтлек өчен зыянсыз булсын дип тырыштым. Әле төзелешкә тотынганчы ук Канадада эшләнгән тузан суырткыч турында интернетта укып, аны үзебезгә дә алырга хыялланган идем. Кайтарттым! Аның үзәк өлеше аста, подвалда тора: йортның кайсы катында суыртсаң да,







зур чүпләр шушында – аста җыела, ә күзгә күренми торган вак тузан урамга ук чыгып китә.

МАВЫГУЛАР ТУРЫНДА. Шактый миндә мавыгулар. 2005 елдан умарта кортлары тота башладым. Үзебезнең балны гына ашыйбыз хәзер. Чәйне 7–8 төрле үлән кушып пешерәбез: бөтнек, мәтрүшкә, мелисса, юкә яфрагы, юкә чәчәге... Тагын мандарин, әфлисун кабыклары... Үләннәрне барыбыз бергә җыябыз. Какны да үзем ясыйм. Ә алманы, гадәттә, балалар турый. Узган ел алма бик күп булды, шактый киптердек тә. Пандемиянең дә бер файдасы булды – өйдә нишләргә белми ятканда сырлар ясый башладым. Интернеттан түләүле курслар сатып алдым. Бушлайлары да бар ул дәресләрнең, әмма анда бөтен серне дә ачмыйлар. Укыдым, өйрәндем һәм тәвәккәлләп тотынып карадым. Иң беренчесе үк килеп чыкты! Интернетта аралашабыз – өйдә сыр ясаучыларның күбесе ир-атлар. Шактый сабырлык кирәк: яныннан китмичә сәгатьләр буе болгатасың. Ул көнне иртәдән кичкә кадәр гел шуның белән генә маташасың. Җиренә җиткереп эшләмәсәм, эшкә тотынып та тормыйм... 10 литр сөттән 1200 грамм сыр чыга. Сөтен сатып алабыз. Каты сыр ясыйм – тешекләренә кадәр бар! «Сулугуни», «Адыгейский» сырларын ясарга өйрәндем инде, чиратта – «Моцарелла». Анысы ике сәгатьтә өлгерә, диләр. Ә каты сырны ким дигәндә суыткычта әле бер ай тотарга кирәк. Үзебезнең гаилә өчен җитеп бара – сырны барыбыз да бик яратабыз. Тагын катык оетырга да өйрәндем – кашык басып торырлык куе килеп чыга. Үз кулың белән әзерләгән булгач, ашавы да күңелле!

ӨЛКӘННӘР БЕЛӘН ЯШӘҮ ТУРЫНДА. Элек банкта эшләгәндә өлкән апаларның: «Кайната-кайнана белән 13, 15, 20 ел бергә торабыз», – дигәннәрен ишетеп шакката идем. «Ничек шулкадәр бергә яшәп була икән?» – дип уйлый идем. Була! Аның авырлыгы да, җиңеллеге дә бергә инде. Балаларны тәрбияләргә булыштылар – кая чыгып китсәк тә, өйдә кеше булды. Узган елга кадәр, егылып аягын авырттырганчы, төшке ашны безгә әти пешерде. Өчпочмакларга кадәр! «Аның нәрсәсе бар?!» – дип, камырны да үзе куя иде. Мех фабрикасында эшләүче әнигә караганда, әти һәрвакыт эштән иртәрәк кайта торган булган. Ашарга әзерләүне хатын җилкәсенә генә беркайчан салмаган ул. Алар икесе дә бәрәңге ярата – көн саен ашарга әзерләр. Тагын – шакмаклап киселгән токмач белән аш. Кияүгә чыкканчы әни гел: «Токмач та кисә белмисең бит, нишләрсең?» – дия иде. Килен булып төштем, ә Азатларда шакмаклы токмач ашыйлар! Аны кисәсе бик җайлы бит...

Иртән эшкә киткәнче, әнине уятып, юындырып, ашатып калдырам. Әти көн саен теләк тели-тели озата. Алар хәер-фатихасында яшибез... Беркайчан Азатка: «Әниең шундый, әтиең шундый», димәдем. Аларның да миннән зарланганын ишетмәдем. Мин эшкә чыгып киткәч сөйләшсәләр генә.

ЯРАТУ ТУРЫНДА. Килен булып төшкәнемә 21 ел. Әти белән әнинең бер тапкыр да сүзгә килгәннәрен хәтерләмим. Ни генә булса да, әти аны шундук уенкөлкегә, башка сүзгә бора. Аңардагы юмор хисе! Гомерендә сүгенгәне булмагандыр. Матур яшәмәсәләр, бу яшькә җитмәсләр дә иде, мөгаен.

Узган елга кадәр әти әле мәчеткә йөрде, мәетләр юды. Шушма буеннан кайтып кермәде – балык тотты. Ташбашлар тотып кайта, чистарта, кыздыра... Бик сабыр ул, юккабарга хафаланмый. Һәр иртәне әнигә бер үк сүзләрне кабатлый: «Шөкер, тордык. Инде исән-сау көнне дә үткәрсәк», – ди. Бер-берсен югалтудан бик курка алар. Узган ел әни авырып алды. Әти гел: «Әби, үлмисең. Әле яши генә башладык. Без бит монда санаторийдагы кебек», – дип әйтеп торды. Әни ашарга безнең янга чыга, ә әтигә хәзер бүлмәгә генә кертәбез. Әни өстәл янында озаграк торса, ул шундук: «Әби кайда әле ул?» – дип, аны эзли башлый... Әнинең күзләре тоникланды, ә әти күзлексез дә күрә әле: әнигә ул гел кычкырып укый. Аннан... җырлый! Күбрәк урам җырларын, ә кайчак үзе дә уйлап чыгара: «Минем сүзне тыңласаң, бергә булырбыз әле...» Әни тыңлый, җырлап бетергәч, кул чаба... Әти соңгы вакытта йөрми диярлек, әмма әнинең төнлә аз гына өсте ачылдымы, ул аны үзе торып яба...

МӨНӘСӘБӘТЛӘР ТУРЫНДА. Диләрә беренче көннән минекеләргә «әти», «әни» дип эндәшә башлады. Аны шулай тәрбияләгәннәр... Өлкәннәр белән яшәү, аларны карау җиңел түгел – мин хатыныма бик рәхмәтле... Без һәрвакыт бөтен нәрсәне киңәшләшеп эшлибез. Була, бер-беребез белән килешмәгән чаклар бездә дә була. Андый чакта кемдер юл куя белергә тиеш. Диләрәнең каршы эндәшкәне юк аның. Әйе, сабыр булсаң гына авырлыклар сизелмичә уза...

Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



ТӨРМӘЛӘРДӘН САРКЫП ЧЫККАН МОҢ

Казан, Мәскәү, Ярославль, Владимир төрмәләрен үтеп, 1941 елның 11 сентябрендә Орел төрмәсендә бер гаепсезгә атып үтерелгән татарның моңлы бер баласы Мәрьям Мозаффарова хакында язмамны шулай атарга булдым. Чөнки: «Мин гаепсез!» – дип тилмереп, карцерларның цемент идәннәрендә ятканда әнә шул моңы, күңеленә сеңеп калган, үзе яраткан Сәйдәш музыкасы, классик композиторларның аһәңнәре генә бердәнбер юанычы булмады микән дип уйланам.



Рәсеменә карап – чибәрлегенә, туганнарының һәм дусларының истәлекләрен укып – саф әхлагына, олы җанлылыгына, туры сүзлелегенә, һәркемгә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер булуына без сокланган Мәрьямнең гомере әнә шулай фаҗигале төстә вакытсыз өзелә. Моның сәбәбе – һичшиксез аның искиткеч талантлы шәхес булуында.

Мәрьям Хәсән кызы Мозаффарова 1906 елның 27 декабрендә элеккеге Сембер губернасының Иске Тимошкино авылында туа. Бик яшьли әтисе, 10 яшь тулганда әнисе дә үлеп киткәч, гаиләдәге өч кыз баланы өлкән абыйлары Йосыф Мозаффаров үз тәрбиясенә ала.

Оренбург өлкәсе Орск шәһәрендәге реальный училище тәмамлаган Йосыф үзе бу вакытта бер байда управляющий булып эшли. Бае аның хезмәтеннән дә, үзеннән дә канәгать булган, күрәсең: кызын да Йосыфка үзе димләп бирә. Матур гына гаилә төзелә. Киявен бик яраткан бай Йосыфның сеңелләре өчен өй дә сатып ала, аларны гимназиягә укырга кертергә дә булыша һәм хәтта өр-яңа пианино да бүләк итә. Сафия, Гөлсем, Мәрьямнәр өчен иң бәхетле еллар була бу. Орск кызлар гимназиясенең китапханәсенә йөрү, төрле фән, музыка укытучылары һәм иң мөһиме – татарның күтәрелеп килгән күренекле шәхесләре Салих

Сәйдәшев, Һади Такташлар белән очрашу кызларның фикер үсешенә, дөньяга карашына бик нык тәэсир ясый. Алар йогынтысында кызлар музыкаль һәм әдәби түгәрәкләргә йөриләр, татар җыр кичәләрендә катнашалар. Мәрьям сөекле шагыйре Габдулла Тукай шигырьләрен яттан сөйли, пианинода төрле музыкаль әсәрләр башкара. Салих Сәйдәшев аның җыр-моңга сәләтен күреп, үзе дәресләр бирә башлый, музыка белән җитдирәк шөгыльләнергә үгетли.

Озакламый татар тормышының тамырына балта чапкан Октябрь революциясе һәм аның нәтиҗәсе булган гражданнар сугышы башлана. Кызларның ир туганнары Йосыф белән Исмәгыйль дә кызыллар ягына сугышка алына. Йосыф фронтта С. Кировның иң ышанычлы ярдәмчесе булып китә, кызлар бәхетенә исән кала, тик Исмәгыйль генә Себердә сугышып йөргәндә тиф авыруы эләктереп үлеп китә. Әйтеп үтим, еллар тынгач, Йосыф Мозаффаров Урта Азиядә Совет властен урнаштыруда да булдыклылык күрсәтә, Турксибны салдыру эшендә дә үзен сәләтле җитәкче итеп таныта. Идел буендагы коточкыч ачлык вакытында ачларга ярдәм оештыруда башлап йөргән өчен Ленин үзе кул куйган Мактау грамотасы белән бүләкләнә. Тик сәясәт үзгәргәч, аны да, «солтангалиевче» дип, «халык дошманы» ясыйлар. Кулга алынудан Киров ярдәме белән котылып калса да, ул үлгәч, таяныр кешесе калмый инде: татарның булдыклы, зыялы шәхесе булып танылган Йосыфның гомере дә төрмәдә өзелә.

Кызлар хакында сүзне дәвам итик әле. 1918 елда абыйлары сугышка алынгач, алар апалары Сафия тәрбиясендә кала. Сафиягә бу вакытта – 18, Мәрьямгә 12 яшь була. Икесе дә татар авылларында укытучы булып эшли башлыйлар. Тик авылларда аклар белән кызыллар хакимияте еш алышынып торганлыктан, кызларның хәле бик җиңелдән булмаган. Еш кына укучыларның әти-әниләре төн уртасында ишек-тәрәзә кагып:

Дуслыкның да кадерен белгән, чын дуслыкка тугры булган Мәрьям. Шуңа дуслары да гомер буе оныта алмаган үзен.

«Абыстайлар, җыеныгыз, сезне качырырга кирәк!» – дип, аларны куркыныч хәлләрдән коткарып кала торган була.

Гражданнар сугышы тәмамлангач, Йосыф Мозаффаров сеңелләрен Мәскәүгә алып китә. Ул бу вакытта яңа гына оешкан Бохара Республикасының Мәскәүдәге тулы вәкаләте илчесе була.

Инде мәгълүм булганча, сугыштан соң, «халык хуҗалыгын торгызу еллары» дип тарихка кергән 20 нче елларда, СССРда төрле һөнәр ияләре, белгечләр җитешмәве бик нык сизелә башлый. Шуңа күрә яшьләр партия һәм профсоюз оешмалары юлламасы белән илнең төрле уку йортларына тартылалар, ә кайберләрен чит илләргә үк җибәрәләр. 1926 елда СССРдан китеп, Европа илләрендә укучы яшьләрнең Берлинда үткәрелгән конгрессында 1 мең ярым студент катнашуы – моның ачык дәлиле.

1922–1926 елларда Бохара Республикасының Германиядәге рәсми вәкиле булып Галимҗан Идриси эшли. Идриси әфәнденең нәкъ менә шул чорда татар-мөселман яшьләрен Германиягә укырга барырга өндәп йөрүен искәртеп үтим. Ни кызганыч, Германиядә укып белем алган татар яшьләренең күпме булуы турында төгәл мәгълүматым юк, ә менә 1928 елда Берлинның югары уку йортларын татарлардан барлыгы 22 кеше тәмамлавы һәм уналтысының СССРга кире әйләнеп кайтуы мәгълүм. Укучылар арасында Берлин консерваториясендә белем алган Мәрьям Мозаффарова да була. Мәрьям белән бергә барган Гөлсем апасы, укуын тәмамлагач, төрек инженерына кияүгә чыга һәм Төркиягә китә.

Мәрьям Германиядә 1923–1925 елларда укый. Чит илләрдә кешеләрнең үз милләттәшләренә тартылуы табигый хәл. Германиядә дә татар яшьләре бергә аралашып яшиләр, дуслашалар. Мәрьям Гаяз Исхакыйның кызы Сәгадәт белән дуслаша, аның белән бергә Идрисиләргә туй мәҗлесенә дә бара. Бу танышлыклар үз фаҗигасенең чишмә башы буласын кыз бала кайдан белсен?

Мәрьям Германиядән кайткач, Мәскәү педагогика институтына укырга керә. Укуын тәмамлаган яшь белгечне Казан педагогика институтына эшкә чакыралар. Немец телен бик яхшы үзләштергән Мәрьям Көнбатыш әдәбияты белән, фән белән ныклап шөгыльләнергә уйлый, Мәскәүгә барып аспирантурага кереп кайта. Томас Манн иҗатын өйрәнеп диссертация яза (тик диссертациясен якларга насыйп булмый). Мәскәү университетында эшләгән немец профессоры Шиллер аның фәнни җитәкчесе була.

Хезмәтеннән шатлык табып, канатланып эшли Мәрьям. Студентларга ул чит илләр әдәбияты буенча лекцияләр укый, әдәби-музыкаль кичәләр оештыра. Алар аны белемле, акыллы булганы, үз-үзен матур итеп тота белгәне өчен бик нык хөрмәт итәләр. «Кайда гына булса да, аз гына мөмкинлек чыкса, пианинода классик әсәрләрне, татар көйләрен әсәрләнеп уйный иде», – дип искә ала дуслары.

Татарның зыялы егетләре (алар арасында – Салих Сәйдәшев, Гыйлем Камай) аңа гашыйк була. Егетләрнең өйләнергә теләп ясаган тәкъдимнәрен ул никтер кире кагып килә. Аның өчен иң җылы, һаман үз итеп, тартып торган урын – апасы Сафиянең гаиләсе була. Сафия бу вакытта татарның күренекле галиме Хәмит Мөштәридә кияүдә, аларның бик чибәр ике кызчыгы – Гөлфия белән Нәркис үсеп килә.

Фотолар: автор архивыннан

Сталин палачлары кыз баланы юк итүгә сәбәп кенә әзерләп, көтеп торганнар диярсең.

1938 елның 27 августында татарның сөекле кызы кулга алына. Көтелмәгән бу хәлдән үзе дә, туганнары да өнсез кала. «Минем бер гаебем дә юк!» – дип тилмерә Мәрьям, һәм соңгы минутына кадәр төрмә палачлары аннан бары шул сүзләрне генә ишетә. Ул беркемнең дә өстенә нахак бәлаләр якмый, беркемнең дә исемен атамый.

Шушы урында Мәрьямнең нинди тарихи вазгыятьтә кулга алынуын искә төшереп китим әле.

1937 елның август ахырында Татарстан партия өлкә комитетының чираттан тыш Пленумында Үзәк Комитеттан килгән комиссия җитәкчесе Г. Маленков: «Сталин Казанда халык дошманнарын фаш итүнең барышы белән һич тә канәгать түгел», – дип күрсәтә. Нәтиҗәдә, 1937 ел азагына кулга алулар планы, 1936 ел белән чагыштырганда, биш тапкыр арттырып үтәлә. Билгеле инде, кулга алулар беренче нәүбәттә иң зыялы, иң талантлы кешеләр арасында үткәрелә. Мәрьям эшләгән педагогика институтында да көн саен диярлек кемне дә булса алып китәләр. Институтның ректоры – Гыйсмәтуллин Нәбиулла Нигъмәтулла улы, партоешма секретаре Исмаев Хәмзә Рәхмәтулла улы һәм күп кенә кафедра җитәкчеләре кулга алына.

Иң сәләтле укытучылар, шулар арасында Якуб Богданович, Илһамия Туктарова-Богданович, Рәхимҗан Яфаев, Габбас Вахитов, Фәйзи Уральский, Нури Йосыповлар бер үк вакытта диярлек кулга алына. План тутырырга кирәк булгач, чират студентларга җитә. Аларны инде сыпырып алган кебек, тулай тораклардан, аудиторияләрдән генә җыялар.

Педагогика институтында замана афәтләре – әләкчеләр дә җитәрлек булган икән. Хәтта укытучылар, кафедра мөдирләре бербёрсе өстеннән шикаятьләр язган. Мәрьям өстеннән дә шунда ук укыткан, үзен бик тә гадел санап йөргән укытучы ханым шикаять яза. Тик шикаять авторның үзен дә коткарып калмый, бераздан ул да кулга алына. Мәрьямнең талантыннан, студентлар һәм институт укытучылары арасында абруе, дәрәҗәсе зур булудан көнләшкәндер дип уйлыйм бу татар хатыны хакында. Чөнки шикаятендә ул «Мәрьямне бөтен кеше ярата», дип аерып, басым ясап күрсәткән.

Сәбәпләр дә бик җитди. Мәрьямнең абыйсы Йосыф бу вакытта «халык дошманы» дип атылган. Өстәвенә, үзе Германиядә белем алган. Әле тагын фәнни җитәкчесе, профессор Шиллер да «халык дошманы» дип кулга алынган булган икән.

Мәрьямнең Германиядә булуы, немец әдәбияты белән кызыксынуы һәм шул өлкәдә фәнни хезмәт язуы «немец разведкасы шпионы» дигән ярлык тагар өчен җитә кала. Болар өстенә, имеш, әле ул педагогика институтында контрреволюцион оешма барлыгын да белгән, әмма әйтмәгән.

Мәрьям Мозаффарованың җинаять эшендәге гаепләү актын СССР прокуроры, мәкерлеге, икейөзлелеге, кабахәтлеге белән аерылып торган Вышинский үз имзасы белән беркетә. Эшне СССР Югары судының Хәрби коллегиясе карый. Судтагы соңгы сүзендә дә Мәрьям: «Мин бернәрсәдә дә гаепле түгел...» – дип кабатлый.

Сафия апасының кызы, Мәскәүдә яшәүче Нәркис ханым җибәргән рөхсәт хаты белән килеп, архивтан Мәрьямнең шәхси эшен карадым. Аның битләрен тетрәнмичә, күз яшьләрсез укып була торган түгел. Мәрьямне еш кына карцерга утырталар, үлем күлмәге кидертеп җәзалыйлар, прогулкалардан мәхрүм итәләр һәм хәтта гади карцерда кычкырганы өчен резина карцерга да утырталар. Туберкулез белән авырый башлагач та ярдәмне вакытында күрсәтмиләр...

1941 елның 11 сентябрендә Орел төрмәсендә 161 тоткын атып үтерелә. Атылганнарның исемлегендә гөл чәчәге кебек матур, белеме белән фәнни ачышлар ясарлык талантлы татар кызы Мәрьям Хәсән кызы Мозаффарова, милләте буенча болгар, СССР гражданы, РСФСР сәламәтлек саклау комиссариатында бүлек җитәкчесе булып эшләгән 68 яшьлек Христиан Григорьевич Раковский, эсерлар партиясенең күренекле әгъзасы Мария Спиридонова, татар егете Рөстәм Туктамышев һәм башка милләт вәкилләренең исемнәре бар.

Гаепсезгә кулга алынган, үтерелгән кешеләрнең эшләрен архивларда сирәгрәк карарга тырышам. Чөнки ул язмаларның һәр юлында кулга алынучыларның үзәк өзгеч тилмерүләре, бер-ике тапкыр сорау алганнан соң, җәзалардан котылыр өчен, үз өсләренә теләсә нинди гаепне алырга риза булулары хакында уку тетрәндерә, йөрәк сызлана. «Ни өчен язмыш халыкның иң уңган, иң булган бөек шәхесләренә шундый сынаулар бирә?» – дип кычкырасы, үксеп елыйсы килә.

Бу җәһәттән, шушы авыр сынауларны кичеп, Мәрьям апасының исемен аклау өчен 1990 елга кадәр көрәшкән, рәсми органнарга йөзләрчә хат язган, замандашларының истәлекләрен җыйган һәм кадерләп саклаган Мәскәүдә яшәүче Нәркис ханым Романовага, Казанда яшәүче туганнары Нәркис һәм Ләлә ханым Мөштәриләргә олы рәхмәтемне җиткерәм. Зур рәхмәт аларга. Алдагы көннәрдә Мәрьямгә һәм халыкның иң олы шәхесләренә төшкән афәтләрне беркемгә дә күрергә язмасын.

Тәэминә БИКТИМЕРОВА,
тарих фәннәре кандидаты.

Фото: Мәрьям (унда) апасы Сафия белән.

УРАЗА



Илнар хәзрәт
ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым»
мәчете
имам-хатыйбы

Уразаны тулысынча тотып бетермәсәң, тоткан кадәресе дә кабул булмый, диләр. Бу дөресме?

– Юк, алар бер-берсенә берничек тә бәйле түгел. Рамазан ае ул – 30 көн. Әгәр син аның бер генә көнендә ураза тотсаң да, ул барыбер савап булып санала. Тагын 29 көне генә тотылмаган булып кала. Шуңа күрә бүлеп-бүлеп – башында, уртасында яки ахырында тоту да, һичьюгы бер генә көн тоту да, бөтенләй тотмаганга караганда, әйбәтрәк. Әлбәттә, күбрәк тота алган саен, савап та күбрәк языла. Тулысынча тотып чыга алсаң, аның савабы да зуррак була – бөтен гөнаһларың кичерелә, Рамазанның ун көне саен Пәйгамбәребез вәгъдә иткән нигъмәтләргә ирешәсең. (Уразаның беренче ункөнлеге – рәхмәт ункөнлеге, икенчесе – мәгъфирәт ункөнлеге һәм өченче ункөнлеге – Аллаһының газабыннан котылып, рәхмәтенә ирешү ункөнлеге санала.)

Тагын шунысын да онытмаска кирәк: тотмыйча калган уразаң синең өстә ахыргача җаваплылык булып торачак.

Бала имезүче хатыннар фидия түләргә тиешме, әллә юкмы?

– Бала имезүче хатыннар бала имезеп бетергәч, уразаларны каза кыла алалар. Ләкин каза кылу мөмкин булмаса (бала тапканнан соң яки бала күтәргәндә берәр нинди хроник авыру аркасында аларга ураза тоту бөтенләй ярамаса), ул вакытта фидия түлиләр. Шулай да каза кылу хәерлерәк. Башта баланы тугыз ай буе карында күтәреп йөреп, аннан берике ел имезсә, хатын-кыз уразаны ике-өч ел рәттән тота алмаска мөмкин. Әмма ул аны барыбер әкренәкрен генә каза кыла ала. Ураза каза кылына икән, аның өчен фидия түләнми. Әгәр аның каза кылырга вакыты калмаса – берәр сәбәп белән вафат булып китсә, бу очракта туганнары аның исеменнән фидия түлиләр. Сүз уңаеннан, быел фидиянең күләме бер көнгә – 200 сум.

Ураза тотмаучыларны ифтар мәҗлесләренә чакырырга ярыймы?

– Пәйгамбәребез үзе яшәгән заманда сәхәбәләргә Рамазан аенда ураза тотучыларны мәҗлескә чакырып, авыз ачтырырга кушкан. «Авыз ачтырган кеше муенын җәһәннәм газабыннан коткарыр, Аллаһы Тәгалә аның белеп һәм белми кылган гөнаһларын ярлыкар. Ураза тотучыга авыз ачарга бер хөрмә яисә баллы су биргән, аны ризыкландырган кешегә Аллаһы Тәгалә ураза тоту савапларын язып, сусаганга су эчерүчене гарасат мәйданына чакырмас», – дигән.

Ифтар мәҗлесенең иң беренче максаты – авыз ачтыру. Һәм шуңа күрә сәбәпсез ураза тотмаган кешеләрне мондый мәҗлескә чакырмау хәерлерәк. Ләкин әгәр инде синең якын-тирәңдә ураза тотучылар юк, ә мәҗлесне үткәрергә телисең икән, бу вакытта ул авыз ачу мәҗлесе түгел, ә гади мәҗлес кенә булып саналачак. Шуңа күрә ураза тоткан кешеләрне чакыру, һичшиксез, дөресрәк. Әмма бу мәҗлескә ураза тотмаган якын туганнарыңны, гарипгорабаларны, фәкыйрьләрне, ятимнәрне чакырсаң, алар ураза тотмаса да, син әзерләгән табынга килүләре, гыйбрәтләнеп, вәгазьләнеп китүләре зур савап булачак. Әмма, ничектер, бу мәҗлеснең мәгънәсе барыбер югала. Көне буе ашап-эчеп йөргән кешеләрнең әлеге мәҗлестә куанычлары ураза тотучыларныкы кебек булмаячак. Ә андыйларны гына кайдан табарга соң дисәгез, якындагы берәр мәчеткә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. «Фәлән кадәр кеше килеп, авыз ачып китегез әле», – дия аласыз. Күпләр, гадәттә, шулай эшли – ураза тотучыларны мәчеттән эзләү, табу җиңелрәк.

Рамазан аенда кемдер сине ифтар мәҗлесенә чакыра икән – барырга кирәк. Бик зур сәбәбең булганда гына баш тарта аласың. Пәйгамбәребез: «Кем чакырган җиргә сәбәпсез бармаса, ул миңа каршы килгән була», – ди. Чакырылган җиргә бару-бармау – мөселманлык хакы санала. Шуңа күрә мондый мәҗлескә барудан бер сәбәпсез баш тартасың икән, гөнаһлы буласың.

Халык арасында: «Ифтар мәҗлесенә тугыз кешедән дә кимне чакырырга ярамый. Кунакларың шуннан азрак булса, авыз ачтыруга саналмый», – дигән сүзләр дә ишетелә. Мондый таләп кую дөрес әйбер түгел. Бөтен кешенең дә хәле бертөсле түгел бит: һәркем шуның кадәр кунак чакыра да алмаска мөмкин. Берәүләрнең акчасы җитми, икенчеләре өенә аның кадәр кеше сыйдыра алмавы бар, өченчеләренең таныш-белешләре арасында шуның кадәр ураза тотучы булмавы ихтимал... Пәйгамбәребезнең дә бу хакта аерым әйтеп калдырган сүзе юк. Тели икән, хуҗа бер кешене чакыра, тели икән – бишне, тугызны. Хәтта туксан кунакка да чакыру юллый ала ул. Никадәр күп кешене авыз ачтырса, әҗер-савабы шулкадәр зуррак булачак. Берәү көне буе ураза тотучыны авыз ачтырса яки сугышка китүче кешене коралландырса, шуңа йөз шәһиднең дәрәҗәсе бирелә, дигән хәдис бар. Монда саннар бөтенләй күрсәтелмәгән. Димәк, кемгәдер: «Ифтар мәҗлесеңә тугыз кеше чакырмагансың, бу – авыз ачу саналмаячак», – дип дәгъва белдерү урынсыз.

МОНДА ДИВАРЛАР ДА ТАТАРЧА «СӨЙЛӘШӘ»



Лилия
ГӘРӘЕВА

Башка бакчаларда булмаган яңалыклар белән танышырга килдек. Татар балалар бакчасының тормышын күрсәтәсебез килә. Бу язманы укыган әти-әни, менә безгә шушы бакча кирәк икән, дип әйтерлек булсын!











– Әйдәгез әле, алайса, мин сезне группалар һәм педагоглар белән таныштырыйм, – дип елмайды бакча мөдире Тәнзилә Гарәфовна. – Балалар бакчасының төп байлыгы – педагоглар. Ә бездә аларның иң профессионаллары, иң кешелеклеләре эшли...

Бүген без Казан шәһәренең Совет районы – Азино бистәсендәге 261 нче «Сәйлән» балалар бакчасында кунакта. Ни өчен нәкъ менә шушы бакчаны сайлавыбызны язманы укыгач аңларсыз.

Ялан кырда – кирмән

– Бакчабыз 2002 елның ноябрендә ачылды, – дип, таныштыруны дәвам итә Тәнзилә Гарәфовна. – Мине 2000 елда мөдир итеп билгеләгәндә монда әле төзелеш бара иде. Нигезеннән үк үзем күтәрдем, дисәм дә, ялган булмас. Кичтән поездга утырып, Ленинградка китә идем (ул вакытта әле Санкт-Петербург дип сөйләшмибез). Анда бакча өчен кирәк-яракларны сатып алып, КамАЗларга төяп җибәрәм... Менә шуның өчен дә һәр почмагы кадерле миңа бу йортның. Чын татар бакчасы итәсем килде аны. Җиңел генә эш булмады ул. Сәбәпләре төрле иде: шәһәрнең тузган йортларыннан килеп урнашкан гаять төрле халык та, татар теле кирәк түгел, диюче әти-әниләр дә, кадрлар да... Ник кирәк безгә татар теле дип, русча гына сөйләшеп йөрсәк, тел үләчәк. Ләкин ничек яраттырырга ул татар телен?! Гел әйтәм: берничә тел белгән кеше һәрвакыт дәрәҗәле булган. Татар теленең нигезен бакчада өйрәнсә, балага мәктәптә дә җиңелрәк булачак.

Тырышлык, үҗәтлек белән теләгенә ирешә Тәнзилә Сөнгатуллина. Бүген ул җитәкләгән балалар бакчасы Совет районында гына түгел, Казанда иң яхшы ун бакча арасында.

Без монда яз ахырында килдек. Бөтен җирдә ап-ак кар иде. Алай да, капкадан ук соклану хисе бөтереп алды. Күз алдына гына китерегез: ыгы-зыгылы шәһәр урамыннан борылуга, ишегалдында әкияти бер кирмән каршы ала. Сукмакның ике ягындагы штендерларга күз төшә. Болар яныннан узганда сабый әтисеннән яки әнисеннән монда нәрсә язылганын сорамый калмыйдыр. Аларда исә – шәһәребез тормышындагы иң истәлекле вакыйгалар. Бәләкәй чакта белгән нәрсә күңелдән мәңге чыкмый бит ул.

– Территориябез генә дә бер гектарлы, – ди мөдир. – Җәй башында гөл бакчасына әверелә ул. Беренче көннән үк матурлыкка, эстетикага омтылабыз. Балачак матурлыктан һәм шатлыктан гына торырга тиеш. Бакчабызның девизы да: «Сәйлән – матурлык, шатлык иле!» бит. Безгә килгән һәр кунак мондагы шартларга шаккатып китә. Балаларыбызның сәйлән кебек тезелеп, шатланып бакчабызга килүе, көн дә яратып, теләп йөрүе – сүзләремә дәлил.

Бөтен шартлар да тудырылган заманча бакчалар белән генә әти-әнине шаккаттырып булмыйдыр бүген. Моны Тәнзилә Гарәфовна үзе дә кат-кат әйтеп тора: «Хәзер бөтен бакчалар да матур. Хәтта безнекеннән дә матурраклары да бардыр».

Килешәбез, бардыр андый бакчалар да. Ләкин ни өчен нәкъ менә татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш типтагы 261 нче балалар бакчасы шәһәребездә, республикабызда узган конкурсларда, ярышларда гел мәртәбәле урыннар ала соң? Моның сере бардыр бит?

Ачыла әкият тартмасы

Бу бакчада тылсымчылар эшли, ахрысы. Адым саен могҗиза. Узган ел бакчаны карарга килгәч, Казан шәһәр Думасы депутаты Людмила Андреева да: «Анда бит диварлар да «сөйләшә», – дип гаҗәпләнгән. Һәр карышны җанландырырга, балалар өчен файдалы һәм мәгълүматлы итәргә омтылучы мөдир булмаса, бу урында расписание, бәлки берәр картина эленеп торыр иде. Ә биредә коридорның диварлары да әкият «сөйли». «О-о, моннан узганда балаларның күзләре ничек янганны күрсәгез! Сорауны яудыралар гына: «Бу нинди кирмән? Монысы нинди имән? Ә ул кайсы әкияттән? Ә бу, ә ул?» – дип, балачакның күңелле мизгелләрен күңелдә җанландыра Тәнзилә ханым. Рәхәт аны тыңлавы. Ул әле бала булып, аларның бар эмоциясен күрсәтә, әле җитди мөдиргә әверелеп, чишәсе мәсьәләләрне барлый, әле барысын да йөрәгенә сыйдырган нечкә күңелле хатын-кызга, баласын җитәкләп беренче тапкыр бакчага алып килгән әнигә әверелә.

Әнә арырак тагын ниндидер кызык уеннар! Ә менә бу бүлмәдә... «Барысы да авторлык эшләребез», – ди татар теле тәрбиячесе Адилә Шәйдуллина.

Искиткеч матур да, шәп тә фетрбукларны (бу йомшак китапларны да әти-әниләр ярдәме белән тәрбиячеләр фетрдан үзләре теккән. Шулкадәр вак эш ул!), шахмат бүлмәсен (логик фикерләүне үстерә!), коридордагы яшел









Тәнзилә Сөнгатуллина: «Бакчага уңай мөнәсәбәтне мөдир, компетентлы педагоглар, аларның бер-берсе, балалар белән аралашу стиле, ачык йөзе, тышкы кыяфәте тудыра. Мин үзем иҗатка, сәнгатькә тартылган кеше буларак, педагогларымнан да шуны таләп итәм. Иҗади интеллигенция вәкилләре белән очрашулар оештыру безне башка бакчалардан һәрвакыт аерып торды. Мөмкинлеге, теләге булган ата-ана бакчабыздан чыкмыйча, кирәк дип санаган барлык төр программаларны сайлый ала. Балаларыбыз имиджлы мәктәпләргә укырга керә. Алар – безнең йөзебез, безгә рекламаны да нәкъ шул балалар ясый».





Адилә Шәйдуллина: «Бу уеннарны без үзебез уйлап таптык. «Тылсымлы уен» дигәне балаларның сүзлек запасын баетырга, уң белән сулны, ас белән өсне аерырга һәм тагын башка бик күп нәрсәләргә өйрәтә. Балаларга бик кызык. Аларның гел китап кына да карыйсылары килми. Ә бу уен мультфильм шикелле. Фонарь белән яктырткач, ак җәймә аша төрле предметлар күренүне алар бер тылсым итеп кабул итә. Уенның исеме дә шуннан».





Наталья Терещенко: «Әле беренче елымны гына эшлим. Балалар белән эшләве шундый күңелле. Алар тереләр, ихласлар. Чит тел өйрәнү җиңел эш түгел. Ләкин балаларның хәтере бик әйбәт. «Ярты елдан ук балагыз инглизчә сөйләшә башлар дип көтмәгез. Әмма без аның потенциалын ачабыз», – дим әти-әниләргә. Балалар гына түгел, олылар да хаталанудан курка, дөрес әйтмимдер дип уйлый. Ә бездә – киресенчә: бала хәтта дөрес җавап бирмәсә дә, юк, дөрес түгел, димибез. Үз-үзенә ышаныч, таныш түгелне өйрәнәсе килү теләге сүнмәсен».

пианиноны узып (Тәнзилә Гарәфовна үзе дә искиткеч музыкант икән ләбаса. «Лирик кәеф чагында чыгып уйныйбыз шулай», – ди ул), икенче катка күтәреләбез. Юк, башта әле медицина бүлмәсендә бер төркем балаларның кислород коктейле белән сыйланганын күреп чыкканбыз икән.

Уйный-уйный өйрәнәбез

Өлкән тәрбияче Алисә Госманова белән сөйләшәбез:

– Бакчабыз 375 балага исәпләнгән. 14 төркем эшли. Җидесе – татар төркеме, өч төркем – логопед белән шөгыльләнүчеләр. 27 тәрбияче-педагог белем һәм тәрбия бирә, – ди ул. – Worldskills чемпионатының сулышы безнең бакчага үтеп керде. Балалар милли ризыклар пешерергә өйрәнә, кирпечләрдән йорт төзи, мич чыгара, кызларыбыз парикмахерлар...



Алисә Госманова: «Балалар бакчасы – башлангыч белемнең беренче баскычы. Төп белем бирү программасыннан тыш, өстәмә белемгә дә зур игътибар бирелә бездә. Болар – инглиз теле, каратэ, хореография дәресләре дә, арт-студиядә төрле техниканы өйрәнү дә, акыл һәм сөйләм үсеше өчен логика, логоритмика, АБВГДейка, вокал да, «Президент мәктәбе», «Ломоносов мәктәбе» программалары буенча балаларны тулысынча мәктәпкә әзерләү дә...»

– Түгәрәкләр белән берәүне дә шаккаттыра алмыйсың хәзер, алар һәр бакчада бар, – дип сүзгә кушыла Тәнзилә Гарәфовна. – Без бакчаны иң яхшы җиһазлар, уенчыклар белән тутыра алабыз, әллә нинди түгәрәкләр булдыра алабыз. Ләкин тәрбияче, балалар алдына басып, тимер тавыш белән: «Тә-ә-әк! Утырдык шыпырт кына! Тиз! Мин кемгә әйтәм!» – дип боерык бирә икән, әллә нинди кызыклы түгәрәкләрең булсын, йөрми анда бала. «Не хочу, не пойду», – диячәк, киреләнәчәк... Без андый педагоглар белән еллар буена көрәштек. Бала алдына чүгәләп, ярат син аны: «Хәлең ничек? Ник кичә булмадың, без сине көттек», – диген, кочаклап ал. Тәрбияченең күзләре янып торырга тиеш! Ул бала белән бер дәрәҗәдә сөйләшә белергә, аның кечкенә генә уңышын да күреп, үсендерергә, мактарга тиеш! Балалар бакчасында очраклы кешеләр була алмый.

– Безнең бурычыбыз – балага бөтен мөмкинлекне бирү, – ди 40 ел стажы булган педагог-психолог Светлана Терещенко. – Баланы бер гөл дип күзалласак, нинди генә матур чәчәк атарга тиешле булса да, күләгәдә, коры туфракта үстерсәң, бөтен матурлыгы белән ачыла алмый. Баланың потенциалын ачу өчен, аңа бөтенесен эшләп карарга мөмкинлек бирергә кирәк. Бу дөньяда әле аңа барысы да яңа. Ул үзенең нәрсә теләгәнен дә белми, әмма аңа бар да кызык. Шуның өчен безнең балалар башта түгәрәккә түләүсез йөри. Тәнзилә Гарәфовна да әйтә: «Башта йөреп карасын. Күрми торып, үзенең ни теләгәнен кайдан белсен?!» Әле печенье пешергәннәр иде. Никадәр эмоция! Камырын ясадылар, кистеләр. Аннары кухняга кереп, поварлардан пешереп бирүләрен сорадылар. Алар аны уен итеп кабул итте, өйрәнгәннәрен сизмәделәр дә. Наратлар утырттылар. Башта орлыкларын, аннары җирен әзерләделәр. Хәзер менә түземсезлек белән аларның үскәнен көтәләр. Укыту процессы уенга корылган булырга тиеш. Безнең педагоглар – фанатлар. Ә Тәнзилә Гарәфовна ул – рентген кебек. Кешенең күңелендә ни барын шунда ук күрә. Һәрвакыт булышыр, яшь тәрбиячеләргә юлын күрсәтер, ярдәмгә килер, хәленә керер. Ул дус һәм киңәшче. Кечкенә төркемнәр һавага чыкканда без аларны коллективыбыз белән киендерәбез. Тәнзилә Гарәфовна беренче көннән шулай куйды. Бер тәрбияче белән бер ярдәмче ничек утыз баланы тиз генә киендереп өлгерсен?! Һавадан кергәч, шулай ук барыбыз да чишендерешәбез. Тиз генә юеш киемнәрен салдырып корысын кидермәсәң, бу яшьтә әле алар авырырга мөмкиннәр.



Юллы-юллы күлмәктән

Спортзалда физкультура дәресе бара. Барысы да юллы-юллы тельняшкалардан, бар да яланаяк. Бик кызык, ахрысы, дәресләре: көләләр, чыркылдыйлар. Спорт дәресләре «Сәйлән»дә Николай Ефименко программасы буенча уза. Нәрсәсе белән үзенчәлеклеме? Барысы белән дә! Баланың сәламәтлеген ныгытуга бөтенләй башкача караш белән, мәсәлән. Барлык күнегүләр дә баланың умыртка баганасын ныгытуга, яссытабанлылыкны кисәтүгә, мускулларын үстерүгә корылган. Дәресләрне Мария Белоусова уздыра. Моны сөйләргә түгел, күрергә кирәк. Әнә алар башта бүрәнәдән шуыша, аннары келәм җәелгән идәннән үрмәли, аннары шарлар тутырылган бассейнга чума... Һай, күңелле дә соң!

Җыр, бию, хәрәкәт аша сәламәт яшәү рәвешен өйрәтүче «Здравствуйте!» программасы да – яңалык. Театр вәкилләре, язучылар, шагыйрьләр белән очрашу туган телне яратырга өйрәтә, балаларда мотивация тудыра. Шул рәвешле сәнгатькә, әдәбиятка тартыла алар. Бакчада костюмнар арсеналының зурлыгы да шаккатарлык. Үз костюмерлары бар. «Барысын да үзебез тегәбез», – ди мөдир, эчке бер горурлык белән.

2005 елда Казанның меңьеллыгын бәйрәм иткәндә бакчада «Милли хәзинә» музее ачыла. Бер экспозиция еллар буена күрсәтелми монда, тематика гел үзгәрә, экспонатлар гел алмашынып тора.

Бу бакча турында шәһәрдә, республикада, Россиядә генә түгел, чит илдә дә беләләр хәзер. Татар теле укытучыларының V, VI съезды делегатларын кабул итәләр биредә, «Ак калфак» Бөтендөнья хатын-кызлары оешмасы вәкилләре (бу оешмада Америка, Германия, Австралиядә яшәүче ханымнар да бар) дә булып китә. «Сәйлән» дип аталган милли балалар бакчасының даны шулай еракларга тарала.

Мөдирнең эш бүлмәсе беренче катта – ишектән кергәч үк. Махсус шушы бүлмәне сайлаган. Бакчага килгән һәр баланы үзе чыгып каршы алырга, башыннан сыйпарга, күңелен күтәрергә ярата ул. «Әти-әни тыныч күңел белән эшкә китәргә тиеш. Баласына уңайлы, рәхәт булганын белгәндә генә әнинең күңеле тыныч», – ди Татарстан Республикасының атказанган укытучысы, 47 еллык педагогик стажы булган, гади тәрбиячедән Казанның иң атаклы балалар бакчасы мөдире вазыйфасына ирешкән Тәнзилә Гарәф кызы Сөнгатуллина.

Йә, ничек, балаларыгызны шушы бакчага бирәсе килү теләге тудымы сездә дә? Ә безнең моннан хәтта китәсе дә килмәде.

Фото: Анна Арахамия

Рәдиф Гаташ... Аның шигырьләре романтик сер белән өртелгән. Һәм анда һәрчак матуррак, затлырак, нәфисрәк, яктырак башка дөнья. Билгесез утраулар, ерак йолдызлар, мәхәббәт, хыял, шагыйрь күрергә теләгән ераклыклар... Шәрыкка хас нюанслар, гарәп мотивлары, газәлләр, робагыйлар, халык җырлары ритмнары исә аның шигъриятен тагын да нечкә зәвыклы итә. Ул – мәңге яшь, ул – гомере буе гашыйк җан, ул – Шагыйрь. Ул – һәр тарафтан матурлык эзли... Ихтыярсыз, Роберт Миңнуллинның аның турында әйткән сүзләре искә төшә: «Укучыга, бигрәк тә яшьләргә, Рәдифнең мәхәббәт шигырьләре ошый төшә. Оптимист җанлы, беркадәр сентименталь шагыйрь мәхәббәткә олылап карый. Иң мөһиме: мәхәббәт турында яза белә...»

Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рәдиф Гаташ бу көннәрдә үзенең зур юбилеен бәйрәм итә. Котлауларыбыз, алкышларыбыз, соклануларыбыз Сезгә, Рәдиф абый!

Рәдиф ГАТАШ

АПРЕЛЬ БУЛЫП КАЛ СИН!..

* * *

Аның белән көлеп сүз башладым,
Көлеп җавап бирде.
Уйнап кына: «Чыгасыңмы?» – дидем.
Уйнап: «Ярар!» – диде.

Көлеп кенә кичен кочакладым.
Көлеп үптем үзен.
Уйнап кына үпкәләгән булды,
Яшерде дә йөзен...

Көлеп кенә суга төштек икәү,
Утка кердек уйнап.

Аерылышкач кына белдем аны
Сөюемне чынлап!

* * *

«Мне было шестнадцать лет».

Ә миңа унҗиде иде!
Уналты иде – сиңа.
Уналты гына әйтмәдең:
– Юк, сөймә мине, сөймә!
Мин... әзер түгел моңа!

Унҗиде тапкыр кабатлап
Мин әйттем сүзләремне.
Хәтерлим горур карашын
Сихерле күзләреңнең.

Әй күңел! Сиңа, көтмәстән,
Болытлар килгән иде.
Ул кичне гомер буена
Каргармын, дигән идем.

Шул күзләр – хыял күгемдә
Якты йолдызлар булды.
Салкын карашыңнан җанда
Ялкынлы җырлар туды.
Җырлар оныттырды – куды
Шул кичнең болытларын...
...Ә ник күзләреңнең горур
Көлүен онытмадым?!

Төш

Төш күрәм: тагын Казаным
озата Сөембикәне...
Кабул итә, имеш, «базар»:
мондый сылу – бәһале!
Шаһгали тиңе Камайлар –
морзалар бәйрәм итә:
Тагын тотык итеп бирә
татарлар ханбикәне!
...Ничә гасыр алыш-биреш!
Әҗере шулай мулмы?
Канда инде сәүдәгәрлек:
җанны сатмасак әле!
Җанбикәбезне оныттык.
Һәйкәлгә урыны да юк...
Сыктау-елавын ишетмик...
Васыяте истәме әле?
Дан-шанын каралтыйк, җуйсын
милли хәтерен Казан!
Каумебез, газиз телебез
бездән яклау көтәме? –
Әйдә соң, фахишә итеп
фашлыйк пакь нугай кызын,
Нәрсә ул курку Ходайдан?
Мәскәү хуплый бит әле.
Дөнья тагын хәйран булсын:
кайда, нинди халык бар
Үз теләге белән биргән
дошманга мәликәне?!
...Бүгенге афәтләр, ахры,
шул гамәл өчен җәза:
Үзебезне җуйганбыз бит,
түгел Сөембикәне:
Үз кулыбыз белән буган
без бәхтебез Кояшын!
...Милләт әнкәләре! Сезне
шундый язмыш көтәме?!
...Бу – төш, Гаташ! Уянырга
соңмы? Әллә «иртәме»?

* * *

Тиле йөрәк! Аңа ялкын
Сугылганда салкын калды;
Киресенчә, салкыннарда
Яна язып ялкынланды.
Ерактагы йолдыз якын!
Йөрәк шулай харап булды.
Яратмавы белән бер кыз
Гомерлеккә яраттырды.

Алма-Атага хат

Сәламемне җиткергәйсең...
Г. Кандалый

Сәламемне илт, таң җиле,
Алма-Атага,
Барып җит Идел-Уралдан Алатауга.
Җиткер сүзен
Марс авылы «хәзрәте»нең
Корыч авылы тумасына –
моңдаш җанга.

Корычны тик галим-хуҗаң
эретә алган,
Ибне Синадай,
атомны меңгә ярган.
Матдә чиксез ләкин,
гүзәл зат җаныдай:
«Ачтым!» – дисәң дә,
күп гәүһәр яшерен һаман.

Төшенергә ахыргача Яшәү серенә
Гаувас булып кем чummаган
Яр күңеленә?!
Татар кызы – Гөлсем,
Фатыймалар күчкән
Казакъ хәтере –
бөек акыннар теленә.

Сәламемне илт, таң җиле,
Алма-Атага,
Җиткер хисем төрки гөлләр
үскән «җай»га.
Туган ягы җилен танып,
тәрәз ачар,
«Айналайн, сәүләм!» –
диген сердәш җанга!

* * *

Бер күрүдән җанда калган
сурәтеңне
Утыз ел саклаганны беләсеңме? –
Серле башкорт мөһере
бар көләч йөзне,
Асылташ нурлар сипкән ике күзне
(Уралда күпме гәүһәрләр,
беләм үзе!)
Тиңсез санап,
һаман сагынып йөргәнемне?!

Уйламадым ләкин бу
гомеремдә Сине –
Утыз елдан соң! –
тагын да күрәсемне:
Кагылмаган һич вакытлар,
диясеме,
Үзең шундый бер мәңгелек
иясеме?!

Дөрес язганмын, дим,
валлаһ! сурәтеңне!

Тукай таҗы

Шигърият!
Тагын җаныңны
Барлый яз – чираттагы...
Нурланып яна биектә
Тукайның мирас таҗы...

Уй җитә алмас шигъри таҗ! –
Бармы, әйт, сиңа лаек?!
Мин! Дигәннәрне варис дип
Танырмы зирәк халык?!
Хакның тик исемен әйткәнгә
Әҗер без көтмибезме?!
Изге кәгъбәгә пакьсезләр,
Исерекләр үтмибезме?!
Көч, дәрәҗәбез дә бардыр
Йолдызга үрелергә?!
Ходай... аһ, Тукай каршында
Курку да булса бездә!

Ә бармы моңсыз – шигърият?!
Әдәпсез – әдәбият?!
Үзең әйт, шигырь алласы,
Вөҗданны безнең уят!
Мәңгелек җыр – «Туган тел»не
Котлый яз – чираттагы...
Биектә һаман кул җитмәс,
Сатылмый, вакланмый торган
Шигърият –
Тукай таҗы!

* * *

Кал җырымда,
апрель булып кал син!
Якты таңдай син бер балкыдың,
Мартта туган җаным шунда белде
Апрельгәчә дөнья салкынын.

Апрель булып килдең,
юк, май түгел,
Мәңге миңа апрель булып кал;
Мәңге шулай якты булсын кичләр,
Сабый яшьле булсын болытлар –
Апрель булып кал син!

Бөреләрнең
Тик ачылган чагын, саф чагын,
Каеннарның суты ташыган мәлен
Күзләреңнең язы сакласын.
Апрель булып кал тик!

Ташкын сулар
Күңелеңдә калсын шул килеш.
Төенләнгән килеш торсын сорау,
Юк, кирәкми җавап, чишелеш...
Апрель килеш...

Беләм: табигатьнең
Үзгәрмәгән юк бер мизгеле;
Тукталу юк сиңа, алда көтә
Яшьлек яшел урман шикелле.
Кемнәргәдер әзерләнгән бәхетең
Елап ашыктыра майларга...
Юк, туктатып булмас бугай аны,
Күңелең синең әллә кайларда.

Ләкин миңа апрель булып кал син,
Минем өчен апрель булып кал!
...Җырларымда синең Кояш яна,
Елау катыш көлә болытлар.

Кал җырымда,
апрель булып кал син...

Гаташ: Сүзем

Хатыйп дустай хуш күңелләр
Һәм «башка уйлы» бәгъзеләр:
– Сирәк күренәсең басмада,
Утың сүрелмиме? – диләр.

Әйтсә шулай «нәзкәй бил»ләр,
Авыздан чәчеп энҗеләр,
Илһам бирүче ут күзләр!

Үзе тере шигырь – кызлар
(Ходай язган шедеврлар!)
Безне инде күрми узар...

Кайда китте шат заманнар,
Иртән чәчеп, кич урганнар?
Юлыбызга чыгып, гөлләр
Шигырь булып көлгән көннәр?!

Хуш күңел дус һәм бәгъзеләр!
Картлыгым алда күп сөйләр:
Гаташ! Дип танырмы яшьләр,
Киләчәктән дәшәр кемнәр?!





Нәзифә КӘРИМОВА

МИЛӘҮШӘЛӘР ҺӘМ КАРГА КАРГЫШЫ

(Хикәя)

– Әни! Карале, мин сиңа нәрсә алып кайттым!

Мәүҗидә апаның улы Сәлим урман каравылчысы, ягъни егерь булып эшли. Эше күп. Өстәвенә, кыргый хайваннарны да кайгырта: пошиларга тоз куя, кабан дуңгызларына кыш буе ашарга ризык ташый. Егерь булсаң, егәрле булырга кирәк шул, ди аңа әнисе. Аркасына мылтык асып, көненә әллә ничә чакрым җирләрне әйләнеп кайта. Ярый, язлар җитте инде. Урманда браконьерлар харап иткән хайваннарның балаларын да алып кайтып тәрбияләп җибәргәне бар әле. Кайсы булса да яши аларда: кыр куяны, кабан баласы, кыр үрдәге дисеңме! Үстереп кире урманга җибәрә шуларны. Ә алып кайткан көнне өйдә балаларга никадәр сөенеч! Сәлим үзе дә кечкенәдән үк шундый иде. Менә бүген дә нәрсәдер алып кайткан.

Ләкин бүген җәнлек-мазар түгел, әнисенең ел саен көтеп ала торган чәчәкләре иде кулында. Шәмәхә вак чәчәкләр бәйләмен Мәүҗидә апага тоттырды.

– Миләүшәләр! Ай улым, рәхмәт!

Әнисе миләүшә чәчәк атканын күрми калам дип бик борчылган иде. Менә ничә язлар инде һич онытмый торган бер гадәте бар: миләүшәләр җыеп кайта. Гади авыл хатынына хас булмаган шул гадәте каян киләдер? Бәлки, күңел нечкәлегеннәндер, бәлки, хисләренең бай булуыннандыр... Ул аны үзе дә аңламый. Улының кулында чәчәкләр күргәч, балкып китте:

– Миләүшәләр! Рәхмәт, балакаем, – диде ул сөенеп. Сизелер-сизелмәс хуш ис тараткан чәчәкләрне сак кына борынына китерде. – Исләре лә исләре!

– Әби, нәрсә ул, миңа да күрсәт әле, – дип, оныгы Әминә дә йөгереп килде. – Миңа, миңа да бир әле, әти! – дип тыпырдады кечкенә кыз.

– Кызым, әс-сабыр иман, бис-сабыр шайтан! Хәзер күрерсең, ашыкма! – диде әбисе. – Кай тирәдән таптың? Шул, мин әйткән төштә идеме? – дип кызыксынды.

– Матур чәчәкләр, миңа да! – дип сабырсызланды Әминә.

– Әминә, бу әбиеңә генә! Мондый чәчәкләрне күп итеп өзәргә ярамый. Менә сиңа да бар! Беләсеңме нәрсә бу? Тал бәбиләре! – Сәлим яңа чыккан чебешләр кебек сапсары тал бөреләре тезелгән берничә чыбыкны кызына тоттырды.

– Ай-яй, нинди йомшаклар! Тал бәбиләре! Әби! Карале, әти миңа тал бәбиләре алып кайткан! Әни! Тал бәбиләрен күргәнең бармы?! Әти алып кайткан! – Әминә тал бәбиләрен күрсәтергә дип әнисе янына йөгерде.

– Улым, миләүшәләрне кайдан таптың дип сораган идем...

Әнисенең сораулы карашыннан, «мин әйткән җирдәнме?» дигәнне аңлады улы.

– Юк, әни, ул урыннан түгел. Гел башка җирдә очрады. Минем умарталык артында да үсә икән алар.

– Элек бер җирдә генә үсә иде алар. Ә инде мин әйткән урынга – Дәүли печәнлегенә миләүшәләрне әтиең белән бергә күчереп утырткан идек. Үрчегәннәрме, юкмы икәнен бик беләсем килгән иде... Барып карарга әтиең юк бит инде... Мин дә йөри алмам...

– Әни! Киләсе елга шуннан карармын, яме... Хәзер гөлҗимеш чәчәкләрен генә көтәсе калды инде. Әнә, суыткычта ләйсән суың да көтеп тора.

Улы аның белән шулай баласытып сөйләшсә дә, Мәүҗидә апа үпкәләми. «Менә бит әле, онытмаган, миләүшәләрне тапкан, димәк, эшендә дә мине исендә тотып йөргән, балакаем», – дип уйлады ул. Әминә тал бәбиләре белән генә тынычланмады. Үрсәләнә-үрсәләнә, чәчәкләрне тотып карарга дип әбисенең әле бер ягында, әле икенче ягында тыпырдарга тотынды. Әбисе, әлбәттә, кулыннан гына иснәргә бирде чәчәкләрне. Аннан соң оныгының башыннан сыйпады да, миләүшәләр салган төргәкне бик кадерле әйберсе кебек күкрәгенә кысып, кая куярга белми торды. Ул бит суга утыртып, тәрәзә төбенә куя торган чәчәк түгел. Мәүҗидә апаның чәчәкләрдән һич аерыласы килми иде. Нигә шулай хуш исле икән бу миләүшәләр? Ул аларны суыткычтагы ләйсән суы салынган савыт артына кыстырды. Хәзер инде гөлҗимеш чәчәк атканны гына көтәсе калды. Иң мөһиме – ләйсән суы бар. Ләйсән яңгыры яуды быел. Ел да яумый ул. Менә узган ел, Мәүҗидә апа күпме генә көтмәсен, яз ләйсәнсез генә килде. Һәм ләйсәнсез язлар белән бергә авылда сәер хәлләр дә булып алды. Сабан туена кунакка бер генә баласы да кайтмады Мәүҗидә апаның. Барысының да ниндидер эше килеп чыкты. Күңелгә хәвеф керде. Күңелгә килгән алга килә, диләр. Булды инде хәлләр! Бер-берсе белән бәйлелек күренмәсә дә, кешеләрдә дә, табигатьтә дә ниндидер үзгәрешләр сизде Мәүҗидә апа.

Әллә нинди шомлы тоелды узган елгы яз. Авылда булган бер ярамаган хәл байтак кына вакыт телдән төшмәде, үзе белән фаҗига да алып килде...

* * *

...Шулай карлар эреп бетеп, ташу сулары тынычлангач, инде кара каргалар, сыерчыклар кайтып, язның иң матур көннәре җәйгә тоташып барганда, менә ничә еллар инде Мәүҗидә апа үзе генә белгән шушы бер горефне башкара: апрельдә җыелган ләйсән суын, майда чәчәк аткан миләүшә, июнь башларында дөньяга ачылган гөлҗимеш чәчәге белән кавыштыру туе ясый. Бу аның өчен кавыша алмый гомер иткәннәргә, өметләрен югалтмыйча көткәннәргә бер мәдхия буларак башкарыла торган йола иде.

Әминә кебек бәләкәй чагында аңа әбисе бер вакыйга сөйләгән иде. Гади генә итеп, әкияткә охшатып сөйләсә дә, Мәүҗидә аны ул вакытта ук чын итеп кабул итте. Һәм гомергә онытмый инде менә – яз билгеләре күренә башлауга һичшиксез үтәлергә тиешле бер кагыйдә булып калды. «Кызым, мин бит кавыштырам, савабы күп аның!» – дигән иде әбисе. Һәм ул сүзләр Мәүҗидә апа күңелендә гомер буе саклана. Савап!

Әбисе болай дип сөйләде: кайчандыр, бик борынгы заманнарда яшәгән ди, булган ди бер ана. Аның булган ди өч игезәк кызы. Берсен – Ләйсән, икенчесен – Миләүшә, өченчесен Гөлҗимеш дип атаганнар. Кызлар буй үсеп җиткәч, яучылар да килә башлаган. Һәм өчесен өч тарафка кияүгә дә алып киткәннәр. Әниләре белән үзара сирәк кенә очрашкаласалар да, өч туган бер-берсе белән күрешергә җай тапмыйча, дөнья мәшәкатьләренә чумып, сагынышып яшәгәннәр. Якты дөньяда бер генә тапкыр да очраша алмаган алар. Менә шулар истәлеге ул, кызым, дип әйткән булган Мәүҗидәгә әбисе. «Мин аларны кавыштырам, кызым. Чөнки бу ике чәчәк һәм ләйсән суы теге өч игезәк кебек табигатьтә беркайчан да очраша алмыйлар. Язмышлары шундый. Башта ләйсән ява, аннары миләүшә чәчәк ата. Аннан соң инде бик көттереп кенә чәнечкеле гөлҗимеш чәчәге үзенең матурлыгы, хуш исләре белән тирә-юньне ямьли...»

Ул чәчәкләрнең һәм ләйсәннең тәнгә караганда җанга дәвасы бардыр, күрәсең... Мәүҗидә апага да аларны кавыштыру үзе бер бәхет! «Җаннарым рәхәтләнеп китә, әйтерсең лә шундый зур эш башкарам!» – дигән иде аңа әбисе. Мәүҗидә апа да менә ничә еллар инде аларның барысын җыя да кавыштыра. Бу кавыштыру гына түгел, сагыш, мәхәббәт, ярату хисләрен бергә тоташтыра торган бер йола да иде. Чөнки Мәүҗидә апаның күңелендә әле әбисе сөйләп бетермәгән, һәр кеше үзе генә тоя алган хисләр кабына иде бу чәчәкләрне бергә туплаганда. Аннан соң җиде чишмә кушылган урында суга агызып җибәрә. Әлбәттә, ул әкият. Ләкин матур әкият, әбисенең әкияте. Мәүҗидә апа аларны болай гына агызып җибәрми. Бу матур гореф-гадәтнең үз догасы да бар.

Миләүшәләрне тотып карарга тырышкан оныгы Әминәгә Мәүҗидә апа да әбисе кебек бу тарихны сөйләргә тотынды. Бөтерчек кебек кыз төбенә төшми туктамас, шуңа күрә әбисенең итәгенә ябышкан кулын тәки ычкындырмады.

– Әби! Мин сиңа үпкәләсәм, син миңа үпкәләмисеңме?

– Ни өчен үпкәләргә уйладың соң әле, балам?

– Әти алып кайткан чәчәкне миңа күрсәтмәдең бит! Менә мин тал бәбиләрен күрсәтәм бит сиңа, кара! Мин аларны санадым да инде!

– Күрсәтмәдеммени, кызым, әйдә әле, тагын бер карыйк. Үзем дә туйганчы карамадым бит! – диде әбисе.

Алар суыткычтан теге төргәкне алдылар да әбисенең бүлмәсенә кереп киттеләр. Мәүҗидә апа әбисеннән кал-



ган әкиятне Әминәгә дә сөйләде. Менә хәзер инде гөлҗимеш чәчәген көтәбез дә, барысы да бергә җыелгач, җиде чишмә кушылган җиргә барып суга агызабыз.

– Җиде чишмә? Безнең авылда ике генә чишмә бит, әби. Каян килгән җиде чишмә ул? – дип гаҗәпләнде Әминә.

– Мин дә әбигә шушы ук сорауны биргән идем, – диде Мәүҗидә апа. – Әйе, без белгәне ике чишмә. Берсе – Олы чишмә, икенчесе – Бәләкәй чишмә. Калганнары кайда соң, дигән идем. Син әле барысын да белмисең шул. Мин дә белми идем синең кебек чакта. Әби күбрәк белә шул. Санаганым бар, безнең авыл аша җиде чишмә ага, диде. Менә син дә белеп кал әле. Аның беренчесе – безнең авылдан ике чакрым югарырак җирдә ага башлый. Бурсык елгасында ул чишмә. Икенчесе – Мунчала күпере чишмәсе. Өченчесе – Түбән очлар эчә торган чишмә, ә менә дүртенче белән бишенчесе – син белгән Олы чишмә белән Бәләкәй чишмә. Бәләкәй чишмәне әле Ибрай чишмәсе дип тә йөртәләр.

– Әбием, мин бит саный беләм! – диде Әминә хәйләле елмаеп. – Әле бишәү генә булды! Безгә бит җиде чишмә кирәк!

– Ашыктырма! Тагын берсе – Болын чишмәсе. Хәзер инде аннан су алучы да, суын эчүче дә юк. Ләкин чишмәсе бар бит аның! Ул бит барысы бергә кушылган җиргә төшеп җитә! Җиденчесе – Олы каен чишмәсе! Бәләкәй чакта без анда суга йөри идек. Безнең урам чишмәсе иде ул. Һәр урамның үз чишмәсе бар безнең авылда. Ә хәзер инде бер генә чишмәгә дә баручы юк. Бер караганда, кеше ышанмаслык. Менә сиңа җиде чишмә! Болай гына агызып җибәрәсе түгел. Без синең белән аның догасын да әйтергә тиеш. Кавыштыру догасы – иң саваплы дога! Чөнки без синең белән кавыштыру бәйрәме ясыйбыз!

– Әбием! Догасын миңа да өйрәтерсең әле, яме! Ә менә кавыштыру нәрсә ул? – дип төпченде Әминә.

– Кызым, ул хакта гөлҗимеш чәчәк аткач сөйләрмен, яме. Дога өйрәтермен, анысын бергә укырбыз! Шуны гына онытма, кызым, бу бәйрәм безнең гаиләнең байлыгы, ул югалырга тиеш түгел. Әбиемнең васыяте. Менә хәзер син дә үсеп җиттең, син моны белергә тиеш. Менә быел ләйсән дә яуды, аның янына миләүшә кайтып җитте. Хәзер гөлҗимеш чәчәкләрен генә көтәсе калды.

Ә узган ел...

Узган елгы ләйсәнсез язның бер көнендә оныгы Әминә белән тагын берничә бала шаулаша-шаулаша яңа гына йомыркадан чыккан кош балаларын күтәреп килеп керделәр. Мәүҗидә апа беркавымга имәнеп китте.

– Балакайлар! Әнекәйгенәм! Нәрсә бу, кайдан алдыгыз?! Хәзер үк урынына илтеп куегыз. Бу бит карга балалары түгелме соң, каргышы төшәр!

– Башка урамнар да алды аларны. Ояларын җимергәннәр бит, – диде Әминә.

– Җимергәннәр? Туздырган дип сөйлә! Ояларны туздыралар. Кайсыгыз менде карга оясына, и Ходаем! Карга каргышлары гына төшә күрмәсен!

Каргалар ташланмадымы соң? Ярый әле чукып күзләрегезне чыгармаганнар!

– Юк, тимәделәр! Шундый каты итеп кычкыралар су буенда!

– Нәрсә булган соң анда? Әйбәтләп сөйлә әле!

– Су буендагы бөтен агачларны кисkәннәр, утын итеп ярганнар!

– Булмас! Безнең Бал әби утырткан таллар бит алар! Кемнәр кискән? Кем кушкан? Су буе талларын шулай кисеп әяләр димени? Алар бит авыл күрке!

– Анда каргалар каравыл кычкыра. Шуларны ишетеп төшкән идек. Сез нигә ишетмисез? Һаман өйдә утырасыз!

– И балакаем, өйдә утырабыз шул. Аякларым авыртмаса... Таякка таянып булса да төшеп менәм әле су буйларына. Каргалар ташланмаса ярый. Аларның ярсыган вакытыдыр. Нигә беркем дә сүз әйтми соң? Каян килеп чыккан ул кансызлык? Карга каргышы тиз төшә ул. Балакайларым, бу кош балаларын кая куярга да белмим инде. Чебешләр янына каргалар сыймас. Шулай да бабаңның иске бүреген алып кил әле, кызым, – диде ул Әминәгә.

Шулай итеп, балалар алып кайткан карга балаларына оя да табылды.

– Җим бетмәгән, язган булса – үсәрләр. Күрә торып җан иясен үтертәсе юк, – диде ул өйдәгеләргә. Мәүҗидә апа гына түгел, бу өйдә барысы да бериш: әле күптән түгел генә кыр куянын терелтеп җибәрделәр.

– Кем эше бу... кайсыгыз белә? – дип сорады ул балалардан.

– Таһир абый, диделәр...

Су буйлары бик матур булса да, чиләк-көянтә асып суга баручы юк авылда. Һәркемнең дә өенә кергән су. Уты, газы кергән, суы да өй эчендә. Әйтерсең чишмә тамагында яшиләр! Ләкин барыбер нидер җитми. Кеше кешегә керми башлады. Капкадан чыгып карасаң, бөтен урамында беркем юк! Суга баручы да, судан кайтучы да юк. Нишләпләр яталардыр өйләрендә? Телевизор карыйлардыр инде... Менә шуңа күрә дә су буендагы йөз еллык талларны утынга кисеп тураганнарын да күрми калганнар. Теләсә кайда өлгерә торган бала-чага әле канатлары да чыкмаган карга балалары белән йөгерешә торгач кына, авыл аңына килде кебек. Ләкин аңына килеп нәрсә эшләделәр соң?

Карга балаларын урнаштырганнан соң, Мәүҗидә апа, бу хәлгә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, су буена төшеп китте. Һәр тал, һәр агач, ул агачларны кем утыртканы, аларның тарихы – бар да таныш аңа. Су буйлары авылның иң матур, иң күркәм урыны. Кунаклар кайтса да, авылдашлар үзләре дә чишмә суын бик сагынган чакларында сыңар чиләк белән булса да су буена төшәләр. Тал-тирәкле, сандугачлы-каргалы, бөтнекле-җиләкле матурлыкны югары очның бәрәңге бакчалары артыннан уза торган ерганак кына аерып тора. Аның аша басма шикелле генә күпер дә салынган, ел саен язгы ташу алып китә үзен. Чишмә юлына ятып диярлек үсеп, кем генә узса да, башларыннан сыйпап кала торган олы яшьтәге ике тал агачы бар анда. Мәхәббәт таллары ул. Алар су буендагы агачларның иң олы яшьтәгеләре. Яңгыр ява башласа да, кояш кыздырса да сыендыра иде ул таллар. Таякка таянып, әкрен генә чишмәгә таба атлаган Мәүҗидә апа иң элек шул талларны күрергә өметләнде.

Инде су буена килеп җитте дип әйтергә була. Чаттан тыкрыкка борыласы гына калды. Борылса...

Таллар гынамы сиңа! Колачлы усак агачларын да егып салганнар! Җил булмаганда да лепердәшеп утыручы усак яфраклары турында Миңсылуэттәй: «Алар бит тәкъбир әйтеп утыра, аларның җаннары бар!» – ди торган иде. Ә хәзер әнә шундый җанлы агачның җансыз кәүсәсе беркемгә дә кирәк булмаган утын агачы булып ята. Су буйлары бушлык! Тегендә-монда – юлда да, бакчада да елга аркылы да йөзьеллык таллар бүрәнә булып аунап ята, әле кайчан гына лепер-лепер килеп, яфраклары белән уйнаган усак агачлары да анда-монда ауган, әйтерсең лә агач мәетләре! Ә нигә соң аварга торган корыган карт талларны кисмәгәннәр бу кансыз кешеләр! Әле йөз еллык булсалар да, язларда яшәреп су юлларын бизәгән, сукмактан узган чакта яфраклары башлардан сыйпап калган талларны кисеп аударганнар! Бар кешене җәлеп иткән, авылның барлык кунакларын чакырып торган су буе ниндидер ят җиргә әверелгән. Мәүҗидә апа нишләргә белмәде. Як-ягына каранды. Оныгын үзе белән ияртмәгәнгә үкенеп тә куйды. Ник, ичмаса, бер тере кеше очрасын су буенда. Таягын куйды да сукмак кырыена чүгәләде. Менә бит ничек! Бу безнең авыл түгелдер! Чишмә тамагына барып җитәрлек хәле калмаган иде аның. Ятлар хуҗа булып алгач, су буйлары да ятсындыра икән. Азрак хәл алганнан соң, ул чишмә янына килеп, бит-кулларын юды, учы белән алып өч йотым су уртлады. Салкын! Аннары коры җиргә утырып дога кылды. Су буе да аңар ятсынып карый кебек тоелды. Мәүҗидә апаның күңеле тулып китте. Әле кибәргә дә өлгермәгән чишмә суы, күз яшьләре белән кушылып, бите буйлап тәгәрәде. Язгы суларга манчылган, яңа гына киселеп аткан агач төпләре күз яшьләренә буылып елыйдыр кебек тоелды. Соңгы тапкыр кайчан килгән иде икән су алырга? Хәтерләми дә инде.

Мәүҗидә апа әле генә борын төртеп килгән үләннәрне сыйпап алды, тирә-юньне күздән кичерде. Яңа гына берән-сәрән ярылып килгән сары-яшькелт яфраклар су буеның бушлыгын капларга тырыша кебек. Андагы хәлләрне күреп, йөрәге урыныннан купты. Каргалар тавышы томырылып аккан чишмә шавын да басып китәрлек иде. Кайгыларын уртаклашулары инде дип уйлады.

Мәүҗидә карчык су буеннан бик ачынып кайтты. Кемгә керергә, кем белән уртаклашырга? Кара инде, эч серен сөйләрлек кеше дә калмаган бит авылда. Болай озак яшәргә кирәк түгел икән. Алай дип әйтү түгел, уйлау да көферлек инде. Күпме сулар сулыш калгандыр, анысы бит бездән тормый. Ә менә карга балаларының язмышын кешеләр генә хәл иткән. Болай калдырып булмый, бу Таһир белән очрашып, авылның тәртибен аңлатырга кирәк дип уйлады ул. Кайткач, хәлсезләнеп урын өстенә ауды. Җаны сызлады аның.

– Балалар, килегез әле монда, сүзем бар! Килен, син дә тыңла әле, – диде Мәүҗидә апа. – Бу хәл минем башыма сыймый. Торып-торып уйлыйм. Бу карга оясын тузгытучылар тынычлап йоклый микән? Мондый хәлнең әле авылда булганы юк иде. Беләсезме, кем эше булган соң бу?


Рәсем: Наталья Васильева



– Әни, син аны беләсең инде. Таш кибеттә эшләгән Гафур булган бит заманында, шуның төпчек малае, Таһир.

– Авылга кайтып үз пуҗымнарына өй салган Таһирмы?

– Шул инде, шул, – диде килене.

– Бик игелекле кеше дигәннәр иде, ничек бу хәлгә төшкән соң ул? Әйтүче булмаганмыни?

– Әнә шул игелек эшлим дип башлаган инде ул аны.

Хәзер бит авылга теләсә кем кайтып төпләнә дә үз кануннары белән яши башлый. Иң беренче авылга кайтып төпләнүче дип, Мәүҗидә апа телевизорны атый иде. Авылга оятсызлыкны шул гына алып керде, ди ул. Ләкин кешеләрдән уйламаганы да килеп чыга икән. Ә инде Таһир читтә үссә дә, əти-әнисе – авыл кешеләре. Шуңа күрә дә әтиләреннән калган иске йортка кайтып егылды инде ул. Күрәсең, читтә эшләре бик хөрти булгандыр. Булганлыгы да бардыр. Өйне яңадан салып керде. Авылда ялгыз апалар да күп. Таһирны ияләндерергә тырышучылар да аз түгелдер. Шулай да берсе үзенеке итте шул. Күптән түгел генә тол калган Фасилә, авыл кешеләре әйтмешли, ипи иснәтеп ияләндерде үзенә. Гел бергә тормасалар да, Таһир Фасиләнең бар эшләрен дә башкара торган булды. Таллар кисү дә шул Фасилә әйтүе белән башкарылган икән. Мунчага ягарга утын кирәк. Урманына керерлек түгел. Ә су буе үзебезнеке, янәсе.

Күршесендәге булса да, әллә кайчан дөнья куйган карчык бакчасы, кемнең кемдә эше бар! Менә бит үз авылының гореф-гадәтләрен белмәү нәрсәгә китерә. Фасиләсе дә читтән, күрше авылдан килен булып төшкән кеше. Таһиры да, читтә зимагур булып күп еллар килмешәклектә йөргәннән соң, авылга кайтып сыенган бер мескен. Каян белсен инде алар каргаларга тияргә ярамаганны! Нәфес көчле! Битарафлык! Уйлап карасаң, яз көне беренче сыерчыкларны көтеп алалар! Сыерчыклар кайткан, сыерчыклар кайткан! Парлысын күрдеңме, парлысы булса, быел кияүгә чыгасың, дип сынамышлар да әйтә торган иделәр. Ә инде язгы бәйрәм итеп барыбер «Карга боткасы» пешә бит, сыерчык боткасы түгел! Карга боткасы бит! Кая китте ул вакытлар! Әкрен-әкрен югалтабыз бит!

– Үз таллары булса бер хәл. Ул бит безнең Бал әби таллары иде. Берсе дә юк хәзер. Нигез корыды. Аңа да яклаучы кирәк шул. Алар карга ояларын гына туздырып калмаган, алар туганыбызның нигезен дә туздырганнар! Авылда мондый хәлнең булганы юк иде бит әле. Оя туздыру ул бит тормышны туздыру. Әйтүче булмады микәнни? – диде бу хәлләрне берничек тә аңлата алмаган Мәүҗидә апа.

Хәер, хәзер кеше әйткәнне барысы да тыңлап бармый шул. Яхшы сүз булса да, колакка элмиләр. Ярамый дип әйтсәң керми калмас иде әле. Күрәсең, теге авылга кайткан егеткә әйтүче булмаган. Кешесенә очрамаган инде, дип уйлады Мәүҗидә апа. Яхшы белән яманны аера белмәү – ул инде уң белән сулны бутау белән бер.

– Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың. Фасилә чанасына утырган ул, – диде килене. – Анысына ни җитми тагын. Тиз генә утынлы буласы килгән. Әй, бу шәһәр кешесе! Әллә акылсыз инде алар. Әллә үзләрен бик акыллы дип саныйлар. Малайлар әйтеп торган аңар. Карга оясы булган агачларга тимә! – дигәннәр...

– Карга оясы да булдымы саклый торган нәрсә! – дип әйткән ди.

Әлбәттә, аның бит ул каргаларны каршылаганы да, карга боткалары ашаганы да юк. Мескен! Үз башына. Карга каргышы төшми калмый. Яз кошларын хөрмәт итәргә кирәк. Алар язны алып килә, гаилә кора, бала чыгара. Шул турыда уйлап караганнары бармы икән?

– Чакыр әле шул Таһирны безгә, сөйләшәсем килә. Бәлки, башына бирәр акыл салып булыр.

– Әни. Килә алмас ул безгә. Башта бүрәнәләр өстерәп билен авырттырган, ди. Кичә әнә үзенең ишегалдында егылып, берьюлы ике аягын да сындырган!

– Ике аягын берьюлымы?! Карга каргышы! Ул озак көттерми!

– Үзе дә әйтә ди. Тигез җирдә егылып киттем, карга каргышы гына төште башыма, дип әйтә ди. Әле кичә генә гел йөри алмаслык хәлгә килгән дигәннәр иде. Бәхетсезлегенә каршы, каядыр бармакчы булган, күрәсең. Хәзер аяксыз ята әнә.

– Шуның белән генә бетсә, бик әйбәт булыр иде дә. Ай-һай! Карга каргышы каты була ул!

Таһирның аягы төзәлсә дә, башына зыян килгән, дип сөйләделәр. Урманда телефоннар өчен куелган маш янына килеп, иң түбәсенә менеп карга балалары кебек очып төшсәм, бәлки, каргышлары бетәр иде, дип әйтә, ди.

...Менә быел да кайтты каргалар. Авыл кешеләре сәер күренешне күреп, быелгы язда да шаккаттылар. Гомердә дә чыршыга оя кормаган каргалар быел чыршыларга да оя корган. Таллар беткәч, кая барсыннар? Ул агачлар киселгәне туралып, туралмаганы бүрәнә булып быел да ята. Беркем дә кагылмый аңа. Ә инде Таһир сүз биргән ди. Нигә генә кистем икән, ел саен Карга боткасы оештырыр идем, дип әйтә ди. Каргалар бит алар боткасын ашарлар, каргышларын гына ташламаслар. Менә Таһир хәзер бу карга каргышы кайсы яктан бәрер икән дип көтеп йөри, ди. Көткән нәрсә килә инде ул!

«Карга боткасы пешер, оештыр шуны! Су буйларына алып төшеп, карга балаларына ашат, бәлки, гафу итәрләр!» – дип шаяртып әйткән сүзләргә ышанган Таһир, быел бала-чаганы басуга алып чыгып, карга боткасы пешергән, кошларга да калдырган, диделәр.

...Ә менә Мәүҗидә апа белән оныгы Әминә бүген ләйсән суын, миләүшә белән гөлҗимеш чәчәген чүлмәккә салып, җиде чишмә суы белән тулып аккан елгага агызып җибәрделәр. Әле Әминә алар артыннан елга буйлап байтак кына йөгерә-йөгерә озата да барды.

– Әбием! Киләсе елга тагы шулай бергәләп кавыштырырбыз, яме! – диде Әминә.

– Исән-имин булыйк та, ләйсән яңгырлар яусын дип телик, кызым. Әйдә, хәзер бер дога.

Әбисе догасын укыды һәм ахырда болай диде: «Йә Раббым! Сагынып көткәннәр, яратканнар, көтеп гомерләре узганнар да кавышсын, еллар бәхет алып килсен, өметләр якты булсын, күңелләр миһербанлы булсын! Амин, амин, амин!»

Шундый зур саваплы эштән ләззәт табып, әби белән онык, җитәкләшеп, өйләренә атлады.

СЕЗДӘН МИҢА БЕР ДОГА...



Лена ШАГЫЙРЬҖАН, шагыйрә, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

Шигырь язучылар бик күп, ә шагыйрь булу бөтенләй икенче нәрсә, диләр. Бик дөрес әйтәләр. Шагыйрьлек – ул авыр хезмәт. Менә шул авыр эш язмышыңны үз кулына ала. Бер шигырең яхшы чыккан саен, икенчесенә үреләсең, өченчесенә... Өлкән яшьтәге Анна Ахматова, кулын әкрен генә селкеп: «Ладно, вас много, вас много... Вы не кончаетесь...» – дип, башына килгән шигырьләрне куа торган булган, дип сөйлиләр... Шигырь язу өчен көч тә, дәрт тә кирәк шул. Ә болай барысы да – шагыйрьлек, җырлау, музыкага сәләт, биюгә осталык табигатьтән килә. Нәселдән дә күчә. Гомумән, табигатьтә нинди күренешләр бар – бөтенесе дә адәм баласына күчә. Космостан дигәнебез дә, ихтимал, шул табигать тавышларыдыр. Табигатьнең дәртләнүе – бию, моңсу көннәре – моңлылык, чишмә агышлары җыр булып керәдер кеше күңеленә...

Иҗат белән гаилә бергә яши аламы икән? Иҗатка башаягың белән кереп чуммасаң, алар бербөтенгә әйләнмәсәләр дә, янәшә яши алалардыр. Мин иҗатка башымны артыграк салдым шул... Мөгаен, шуның өчен дә йөрәгемә якын булырдай тормыш итәрлек кешене тапмадым. 36 яшемдә бер уйлап карадым анысы. Тик: «Булмас, моны бит карарга, тәрбияләргә дә кирәк. Аннан күренеп тора – язучылыктан биздерергә исәпли», – дип баш тарттым. Дөресен әйткәндә, үземә тиң яр таба алмадым. Төнлә эшли идем. Андый хатын кемгә кирәк? Төнлә эшләмәсәм – язып булмый. Ә язмыйча торып булмый...

Шигырьләр ничек языламы? Алар үзеннән-үзе башка килә. Шул мизгелдә үк аны язып куясың. Язып куйганы синеке була инде, ә язарга вакытың булмаса, иренсәң яки язганыңны югалтсаң – шигырь тумыйча кала. Чөнки соңыннан искә төшереп, тырышып-тырышып ясап карасаң да, шигырь инде чыкмый. Ул ясалма була. Ә ясалма шигырьнең ниндилеген үзең аңлыйсың: шагыйрь кеше шигыренә үзе бәя бирә белергә дә тиеш.

Рус әдәбиятын су урынына эчтем. Татар әдәбиятын инде әйткән дә юк. Өебездә китаплар бик күп иде. Китаплардан кала, тагын ялгызлык сөя идем мин. Менә аның мәгънәсе булгандыр инде... Уйчан кешегә уй килә. Уй килгән кешегә фәлсәфә килә. Аннан китаплар укыганда: «Карале, мин дә болай иттереп уйлый беләм бит», – дисең. Кайсыбер фикерләргә шаккатасың, ә иң ошаганнарын үзеңә сеңдерәсең. Китапта язылганнарны күңелеңә сеңдерү урлауга керми, ә аны баетуга керә. Илһам абый Шакиров белән якын дуслар идек без. Ул фәлсәфи, юморлы, кызык кеше. Рухи дөньяма аннан да бик күпне алганмындыр.

Рухи байлыгыбыз арткан, зурайган саен, шуңа тәңгәл рәвештә рухи батырлыгыбыз да артсын иде. Болар бер-берсеннән шактый аерыла. Кешедә рухи байлык булып та, рухи батырлык булмаска мөмкин. Рухи батырлык миндә яшь чагында бик көчле булды. Аннан, ничектер, нәрсәдер бераз мине сындырды. Рухи батырлыгым да кимеде... Яшерен-батырын түгел, үзгәрешләр булды бит инде тормышта. Ул минем шигырьләрдә дә бар. Әйе, бар... Бик кызык шигырьләр яздым күчеш чорлары турында.

Адәм баласына җыр кирәк, шигырь кирәк, бию кирәк. Менә шушыларның бөтенесе дә булмаса, дөнья бөтен булмый инде.

Халык нәрсә әйтә, халык нәрсә уйлый, без, шагыйрьләр, шуны уйлыйбыз, шуны сизәбез. Сез әйтеп бетермәгәнне шигырь итеп әйтәбез. Менә шуңа да, без үлсәк тә, дога кылыгыз. Бер шигыремне укуыгыз да дога кебек булыр...

Һавалардан йолдыз яуган чакта,
Тамчыларын җыйдым учыма.
Күңелкәем әллә шуннан бирле
Чиксезлеккә, күккә очына...

Һавалардан йолдыз яуган чакта,
Теләкләрем теләп өлгермим...
Ашкынукайларым шулай көчле,
Чүттән генә чыгып йөгермим...

Һавалардан йолдыз яуган чакта,
Инде куралмый да каламын.
Хыялымда җиргә төшкән берен
Учларыма җыеп барамын...

Тәртип радиосы



«Тәртип» радиосында баручы «Чакырылган кунак» тапшыруының шагыйрә Лена Шагыйрьҗан катнашкан бу чыгарылышын (2014 ел) тулысынча тыңлау өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



Фотолар, хатлар, көндәлекләр Флёра Хәмитованың шәхси архивыннан алынды.

ҖАНЫМ МОНДА КАЛА...



Гөлзадә БӘЙРӘМОВА

Менә инде ничәнче көн тәрәз каршындагы өянкеләрнең искән җилдән акрын гына тирбәлүеннән өстәлгә ачып салган көндәлек дәфтәренең битләре ачыла да ябыла... Вакыт җилләреннән инде саргая башлаган дәфтәр битләренә язылган истәлекләргә күңел хатирәләре дә өстәлә, моңсулык иңә...

Гомернең шундый бер чорына җитәсең, хатирәләр белән яши башлыйсың. Иҗат кичесенең алкышлар һәм табышлардан, югалту һәм сагышлардан торган тормышында бәгырьләрне телеп-телеп ала торган хатирәләр, һай, күп тә соң! Әнә алар, әле мәктәптә укыганда, хорда җырлап торган чагында, Салих Сәйдәшевнең чәченнән сыйпап: «Җырла, бәгырь, син әле Мәйсәрәләрне уйнарсың», – дигән ягымлы тавышы, Мәскәүгә Щепкин исемендәге Югары театр училищесына укырга җибәрергә теләүләренә ни дип җавап бирергә дә белмичә торганда, кабул итү комиссиясе әгъзасы, Татарстанның халык артисты Һидаят Солтановның: «Хәмитова, мондый мөмкинлек ике тапкыр булмаячак!» – дигән кисәтүле дә, үгетләүле дә авазы булып та яңгырап китә.

Их син, яшьлек! Их син, тиле яшьлек! Яшьлеккә генә хас сыйфатлар булмаса, син бит яшьлек дип тә аталмас идең! Сөя, ярата да белмәс идең! Ут кебек янып торган, юктан да кызык табып көләргә, шаярырга яраткан, яшьлек яме белән балкып янган Флёрага Мәскәүдә укыганда Ашхабадтан килеп укучы, төрки халыкларга гына хас булган кара-кучкыл йөзле, күз карашы белән үк яндырып алучы чибәр төрекмән егете Ашир гашыйк була. Мәскәүдә гаилә корып яши башлаган булачак артистларның берсенең, укуын тәгәлләп, Казанга кайтыр вакыты житсә, икенчесенең исә әле укуы тәмамланмаган. Ашир, елдан артык Казан белән Мәскәү арасында йөргәннән соң, бу юлы инде гаиләсен Ашхабадка алып китәр өчен кайта. Башбирмәс төрекмән егете чит җирдә төпләнеп калырмы?! Щепкинчыларның Казанга тәмамлап кайтуын, Камал театрында яңа талантлар, яңа исемнәр күренә башлавын театр үзе генә түгел, тамашачылар да көткән бит. Талантлы, җырлы-моңлы артистка кайткан дип, Флёра Хәмитованың исеме халык арасында тарала да башлаган була. Хыялы бит эссе якның коры һавасын сулап, чит-ят гореф-гадәтләргә баш иеп түгел, сәхнә тузанын иснәп, үзен зурлаган тамашачысына баш иеп яшәү иде. Әтисенең муенына сарылган кызы Айгөл, томырылып җавап көтеп карап торган

Флёра Хәмитова режиссёрлар өчен чын мәгънәсендә табыш була.

ире Ашир, Камал театры режиссёры Александр Михайловның: «Пропискадан төшеп китмә, яши алмаячаксың син ул якта, кайчан кайтсаң да кабул итәм», – дигән сүзләре хәтер түрендә яңара... Язмыш поезды бу юлы инде аны Мәскәүдән дә ераккарак – Ашхабадка алып китә... Тормышта үз урыныңны табар өчен, кайчакларда, бәлки, ераккарак та китеп карарга кирәктер... Күңелен бушатырга, әле ярый сердәше дәфтәр бар. Көндәлек дәфтәренең Ашхабадта яшәгәндә алып барылган битләрен ачабыз...

«Төн уртасында килеп төштек. Юл ерак, арылган. Төнлә кисәк кенә уянып киттем дә бүлмә буйлап карап йөрим. Тәрәзәдән кап-караңгы төн генә шәйләнә. Күк шундый түбән, кулыңны сузсаң, йолдызларга тиярсең кебек. Каядыр еракта, тауларда, бала елаган сыман шакал елавы ишетелә. Айгөл изрәп йоклый, Ашир исә тезләренә таянып, елмаеп мине күзәтә. Сүзләр артык. Бер-беребезне елмаюлы карашлар аша да аңлыйбыз.»

Ул якларда рус телен яхшы белгән белгечләргә кытлык заман. Тамырдаш халыклар телен өйрәнү дә аңа әллә ни кыенлык тудырмый, Мәхдүм Колый исемендәге театрда төрекмән теленнән русчага тәрҗемәче булып эшли башлый. Педагогик белеме булган Флёра Хәмитова мәхәббәте, гаиләсе хакына төрекмән балаларына рус теленнән дәресләр биреп хөрмәтле мөгаллимә дә була алыр иде, Аллаһы Тәгалә аңарга укытучыларда булырга тиешле сыйфатларны – сабырлыкны, гыйлемне, матур сөйләм, буйсынны камил итеп биргән. Тик көндәлек дәфтәренең битләре көннән-көн ешрак ачыла, күңелгә җыелган хискичерешләр түгелә бара...

«Мин чит җирдә. Кешеләр үзләре әйбәт, ләкин бик кырыслар. Шул ук вакытта юмартлар да. Хатын-кызларга карата мөгамәлә коры. Катнаш никахлар хупланмый. Туганнары мине сагаеп кабул иттеләр. Тора-бара мөнәсәбәтләре үзгәрде, елмаеп сөйләшә, Флораҗан дип дәшә башладылар. Ирем назлы, нечкә күңелле. Тик мин үземнең Ватанымны, театрымны сагына башладым. Үземне читлектәге кош сыман тойдым. Ирем нинди генә әйбәт булса да, ни илемне, ни театрымны алыштыра алмый иде шул. Әлбәттә, ул минем халәтемне аңлый иде һәм без бер-беребезнең күзенә туры карый алмый башладык. Ул – чарасызлыктан, мин ачык итеп дөресен әйтә алмаудан».

Баланың авырый башлавы, артык коры, эссе һаваны күтәрә алмавы, врачларның климатны алыштырырга кушулары инде болай да бәргәләнеп, җанын кая куярга белми яшәгән Флёрага Казанга кайтырга бер этәргеч була.

«Аширга дөресен әйтми чарам калмады. Ул Казанга күчеп килергә риза булды. Тик бер шарт белән: анда кайткач театрда уйнамаска.» Флёра исә ни дип тә җавап бирми, башында бары тик тизрәк өйгә кайту уе гына. Азга гына дип аерылышуның гомерлеккә буласын ул вакытта сизенделәр микән? Хәтер түрендә Аширның очкыч аланында басып калган сурәте, «Флораҗа-а-ан...» дип өзгәләнүе генә сагыну-сагышларга уралып, Мәйсәрә-Сәрвәрләрнең моңына кушылыр...

Театр дөньясы шундый дөнья – бер-береңне өнәп бетермәсәң дә, үпкә-ачуың булса да сиздермәскә, сөймәгән партнёрыңа да сәхнәдә «сөям» дияргә, кочаклашырга мәҗбүрсең. Киткән вакытта сәхнәдәшләреннән: «Китмә!» дигән сүзне ишетмәгән кебек, кайткач «Кайттыңмы?» дигән сөенечле карашны күрмәсә дә, Флёра яраткан, туган йорты кебек күргән театрына кайтуы белән бәхетле була. Бернигә карамый, беркем сүзен ишетми уйный, иҗат итә. «Бу роль минеке!» дип сәхнәдәшләренең башына басып йөрми, рольләр аны үзләре эзләп таба, бигрәк тә ул елларга хас булган әсәрләрдәге нечкә күңелле хатын-кыз героинялар – аныкы. Иң беренче роле – К. Тинчуринның «Казан сөлгесе»ндә – Мөршидә,

Йә, әйтеп кара, сугыш кичкән ир-егетнең йөрәгендә сөю уты янмый дип?!







А. Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләр»ендә – Дибәҗә, Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ендә – Сәрби... 1970 елда Марсель Сәлимҗанов куелышындагы «Зәңгәр шәл»дәге – күпләр хыялланган Мәйсәрә! Ул аны өч йөз тапкыр уйный! Көнчел күңелләр исә аның уңышларын җырлый белүе белән генә дә бәйләргә тырышалар, янәсе ул тамашачы күңеленә уйнавы белән түгел, җырлавы белән генә үтеп керә. 1971 елны сәхнәгә Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы менә. Анда исә тамашачылар бүгенге көнгә кадәр хәтерли торган онытылмас Сәрвәр! Кайсы гына режиссёр нинди генә чорда куймасын, гади тамашачы арасында гына түгел, сәнгать кешеләре арасында да: «Флёра Хәмитованың Сәрвәре түгел шул инде...» дигән сүзләренә әле бүгенге көндә дә күп тапкырлар шаһит булганым бар. Ул да сәхнәдә 500 тапкыр уйнала! Флёра Хәмитова Сәрвәренең шулай озак тамашачы күңелендә саклана алуының сере, әлбәттә, аның күп тапкырлар уйналуында түгел, актрисаның талантында, онытылмаслык образ тудыра алуында, героиня белән тәңгәллегендә, бербөтенлегендә. 1971 елда режиссёр Ришат Хаҗиәхмәтов М. Фәйзинең «Ак калфак» әсәрен сәхнәләштерә. Биредә ул иркәлектә үскән, үзсүзле, ләкин шул ук вакытта нечкә күңелле, нәзакәтле, җырлы-моңлы морза кызы Хәмдияне сурәтли. Билгеле, талант иясенең иҗат амплуасы киңкырлы булырга тиеш, уңай героиняларны гына уйнау ышандыру көчен киметә, актриса буларак үсеш юлын томаларга да мөмкинлеген күздә тотып, Марсель Сәлимҗанов аңа характерлы рольләр дә бирә. Н. Сторожеваның «Әгәр ташлап китсәң»ендә – Анна, Н. Погодинның «Баһадирлар»ында – Ирина, К. Тинчуринның «Американ»ында – үз-үзен генә яратучы, беркемгә баш имәс Дилбәр, Х. Вахитның «Ике килен-килендәш»ендә – Разия, М. Әмирнең «Тормыш җыры»нда – Халидә, Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү»ендә – чая Саҗидә, «Дуслар җыелган җирдә» әсәрендә – Галия. Хәтта королеваның үзен дә уйный әле ул! Шекспирның «Гамлет»ында – Гамлетның әнисе, королева Гертруда. Көнләшүчеләр тагын табыла, королева бик гади, янәсе. Бөеклекнең асылы – гадилек юкса... Ә менә «Хушыгыз»да аңа уйнарга туры килми, гәрчә автор сиздерүе һәм үзенең сиземләве буенча әлеге әсәр аның турында булса да... Нинди зур хыяллар, өметышанычлар белән сәнгатькә, халкыма хезмәт итәм дип актриса язмышын сайлаган, ләкин идеаллары җимерелгән, күп әйбердән күңеле кайткан, өмете өзелгән, театрның ишегеннән чыгып киткәндә: «Хушыгыз!» – дип кенә әйтә алган Миләүшә – ул бит! Ах, ничек тәэсир итәр иде тамашачыга аның сәхнә биеклегендә роль аша, образ аша саубуллашуы...

Театр сәхнәсе генә түгел, тормыш сәхнәсе дә синең белән бергә әйләнә. Берәү тормышыңнан төшеп калса, икенче берәү исә күңелең түрендә үк урын алырга, яклаучың һәм саклаучың булып кулын сузарга мөмкин. Аның уйнаганын яратып караган меңәрләгән тамашачының күз карашына, сәхнә кырыннан гына томырылып карап торган, театрның чибәр, талантлы артисты Дилүс Ильясовның да карашы өстәлә. «Нигә болай карап торасыз миңа, Дилүс абый?» – дип сорарга батырчылык итә Флёра. «Яратып...» – ди фронтовик артист. Өлкән артистларның яшьләр уйнаганын күзәтергә яратканын белсә дә, тик моның инде артист буларак кына күзәтү түгеллеге аның уена да кереп чыкмый. Яратуы көчле буламы, бала сөясе килүеме, йөри торгач Дилүс Ильясов: «Балаңа ата булырмын», – дип тә өстәп куя. Баласын ялгыз үстерүче, таяныр терәге булмаган хатын-кызга мондый очракта, бәлки, соңгысы ныграк та тәэсир иткәндер. Сугыш михнәтләрен кичкән фронтовик артист: «Минем балам булмый», – дип

әйткән булса да, бер елдан кызлары туа. Инде 40 яшьтән узган булуына карамастан, әле бер тапкыр да ата булу бәхетен тоеп карамаган ир: «Чулпаным туды!» – дип сөенә. «Балам булмый» дип әйтүе, бәлки, күпләрне тавышы белән генә дә дер селкетеп торган Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы, беренче хатыны Гәүһәр Камалованың үзеннән җибәрмәс өчен, хатын-кыз хәйләсе генә дә булгандыр? Бәлки, бәлки... Гаилә тормышы четерекле. Барың да бергә, бер коллективта эшләү, бер сәхнәдә уйнау кайсына да җиңел булмагандыр. Ә менә кайнанасы – Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы, бу дөньяның ачысынтөчесен күп татыган, сөрген михнәтләрен күргән Гөлсем Камская Флёра Хәмитованы яратып кабул итә.

Гастрольләр – артист гаиләсе өчен зур сынау да, сагынышып күрешү өчен җай, форсат та. Ярый да икең бергә китсәң?! Труппа икегә бүленеп, берсе төньякка, икенчесе көньякка китеп барган вакытлар да аз булмый. Андый чакларда очрашу көнен якынайтып, арада сагыну тулы хатлар йөри. Сак кына, акрын гына, Дилүс Ильясовның Флёра Хәмитовага язган, вакыт үзенең сары төсен сеңдергән, һәр юлы, һәр сүзе сагыну-сагыш белән сугарылган, хатларын ачабыз...

«Кадерлем минем!

Син бу хатны мин киткәч алырсың. Бел (белмим, алай әйтәләрме, юкмы) һәм онытма, мин китәм, әмма йөрәгем һәм җаным монда кала. Синең янында, шатлыгым һәм кайгым минем! Нәрсә генә булса да, без бер-беребезгә дөресен әйтергә тиеш. Бу бик-бик авыр булса да, ихлас булыр. Бу – бигрәк тә сиңа карый, чөнки мин инде сиңа үземнең соңгы сүземне әйттем! Син – минем соңгы аккош җырым!» 2.8.64.

Гаҗәп, икенче көнне үк ерак Фрунзе каласына килеп төшүгә язылган хат. Йә, әйтеп кара, сугыш кичкән ир-егетнең йөрәгендә сөю уты янмый дип!

«Исәнме, кадерлем!

Менә без Фрунзега килеп җиттек. Юл ерак һәм алҗыта торган.

Барсы да спектакльгә киттеләр, минем исә уйларымда булса да синең белән каласым килде. Мин сиңа әйткән идем, син минем өчен бик якын, кадерле, тик беркайчан да синең юлыңда киртә булмам дип. Әйттем бит: телемне тешләп булса да түзәрмен, әмма сер бирмәм. Син бу юлларны укырсың да елмаерсың, үзем язам – үзем синең күзләрне, елмаюыңны, чәчләреңне күрәм. Бары шуны гына әйтә алам: яратам! Сине күрәсем килә, сине кочасым, үбәсем килә...» 3.08.64.

«Сәлам Наманганнан!

Бу хатны ашыгып язам. Теләсә кайсы вакытта кемдер кайтып килергә мөмкин. Кадерлем минем! Күземне йомуга, күз алдыма син килеп басасың, тузгыган чәчләреңне, шат күзләреңне күрәм. Әллә сихерләдең инде? Кызык бит бу, кичә килеп төштек Наманганга, белеп торам, миңа почтада бернәрсә дә юк, ә үзем чаба-чаба киттем главпочтага. Менә дивана, әйеме?» 19.9.64.

Юк, чит җирдә җирсү, эч пошудан гына язылмый әлеге сагынычлы хатлар, үз илендә, үз җирендә дә азга гына аерылышып торсалар да, күңелен сагыш баса ирнең.

«*Кадерлем минем!*

Бүген мин 5.20 дә Буинский вокзалында син сулый торган һава, син тора торган җирдә 20 минут чамасы тордым. Әгәр вакыт уңаерак булса, бәлки, мин Куйбышевтан телеграмма да җибәргән булыр идем, ләкин вакыт бик иртә, һәм вокзалга килү сиңа уңай түгел...

Сагындым сине, чертовкам, сагындым. Хатларыңны бөтен көчем белән сакларга тырышам. Минем өчен алар бик кадерле.

Яратам! Юк, алай дип әйтмим! Көтәм, түземсезлек белән сине көтәм!!! Үземнең Флёрамны нык-нык итеп үбәм!» 14.10.64.

Хатлар... хатлар... Еракта чакта да бер-берсенең исәнлеген, барлыгын, яратуын тойдырып, ерак араларны, очрашу көннәрен якынайтып, бәйләп торучы бердәнбер дип әйтерлек чараларның берсе бит ул заман өчен.

Гел шулай гына барса икән дә бит дөнья! Гел шулай гына – өйдә кызларының шат авазларына күмелеп, икең бергә сәхнәдә уйнап, тамашачы мәхәббәтенә коенып яшисе генә дә бит! Чаллыда гастрольдә вакытында, Татарстанның халык артисты Дилүс Ильясов, 1981 елда, 59 яшендә көтмәгәндә йөрәк өянәгеннән вафат була. 17 ел бергә яшәгән гомер кинәт өзелә...

Театрга багышланган 24 ел гомер, 40 ка якын роль... һәм бушлык... Озакка сузылган бушлык. Хәтер җилләре кабаттан көндәлек битләрен актара:

«1984 ел. 1 октябрь. Әллә китәргә инде? Күз яшьләре аша көләсе килә. Ничек шулай килеп чыкты? Мин тагын китәргә тиеш.»

Ә нигә тиеш? Кайда язылган ул? Бернинди боерык яки каядыр чакыру да юк лабаса! Эчке сиземләүме бу яисә тирә-якны әйләндереп алган бушлыкның салкынлыгын тоя башлаумы? Һәм ул китә. Рольсез яшәгән, әрәмгә узган еллары өчен беркемгә үпкә белдерми, бары тик «Хушыгыз!» гына ди... Татарстанның атказанган артисткасы Флёра Хәмитова моңарчы да дәресләр алып барган Казан дәүләт мәдәният институтында рәсми рәвештә укыта башлый һәм булачак сәхнә осталарына сәхнә теленнән 32 ел – 81 яшенәчә белем бирә.

Шәфәкъ алсулыгы аша искән җил көндәлекнең соңгы битләрен ача:

«Щепкинчыларның юбилеена чакырдылар. 29 октябрьдә Камалда. Мин анда 24 ел эшләдем. Тагын үземнең курсташлар арасындамын. Төрле өзекләр уйныйлар. Миңа да «Сүнгән йолдызлар»дан өзек уйнарга кушалар. Бик дулкынландым. 16 ел сәхнәгә чыкмаган. Тавыш бар, уйнап чыктым. Бер генә мизгелгә үземне яңадан сәхнәдә итеп хис иттем. Бәхетле мизгел. Тик минем исем генә беркая да яңгырамады. Әйтерсең лә миннән театрдан киткәнгә үч алдылар. Кадерлеләрем минем! Ә мин бит зур рольләр уйнап киттем...»

Ә җил исә дә исә... Хәтер төпкелендә утлы күмер кузлары кабынып китеп янә көндәлек дәфтәре битләренә иңәләр:

«Бәргәләнә адәм, өзгәләнә,
Рәхмәтлемен Аллаһыма
Безгә түзгәненә...»

Фото: К. Тинчурин, «Сүнгән йолдызлар». (Сәрвәр – Ф. Хәмитова, Мәхдүм – Р. Таҗетдинов.) Д. Ильясов Ш. Бикчуринның «Бергә – гомергә» спектаклендә. К. Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар». (Сәрвәр – Ф. Хәмитова, Исмәгыйль – Н. Әюпов.)

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Әбием – Хәйруллина Софья Нәби кызына быелның март аенда 95 яшь тулды. Хезмәт һәм тыл ветераны, Герой-ана ул. 95 яшенә житсә дә, күзләре жете, хәтере уяу.



Бурятия Республикасының Кабанский районы, Кабанск авылында яшәүче әбием Татарстанның Кукмара районы Чишмәбаш авылында туа. Гомере буе Софья булып йөрсә дә, документларда шулай теркәлсә дә, мулла кушкан чын исеме Сәйдәбану аның. Сугыш башланган елны авылдагы жидееллык мәктәпне тәмамлап, солдатларга гимнастеркалар, юл биштәрләре тегүчеләр артеленә эшкә керә. Бик тиздән яшь кыз тәжрибәле тегүчеләр белән беррәттән эшли башлый.

Ул елларда да Татарстаннан күп гаиләләрне Себергә сөргенгә жибәрәләр. 1943 елны әбиләр гаиләсенә дә приказ килә. Айлар буе мал вагоннарында ачлы-туклы интегеп бара торгач, бер өлеш халыкны Бурятиянең Мысовая станциясендә төшереп калдыралар. Алар Поворот авылында урнашып, шунда эшләргә тиеш була. Байкал күле буендагы бу авыл халкы балык тотып, фронтка балык озата. Әбием дә балыкчылар бригадасында эшли. 15 яшьлек кыз бала өчен авыр ятьмәләрне судан сөйрәп чыгару жиңел эш булмаса да, ул зарланмый. Зарланып, кая барасың... Эшләгәннәренә акча түләмәсәләр дә, балыкчыларның үзләренә көненә – 650 г, гаиләсенә 400 г ипи бирәләр. Тотылган балыкны исә яр буендагы чаннарда тозлап, фронтка озатырга әзерлиләр.

1944 елны әбиемнәр Посольск авылына күченә. Шушы елны әтиләрен жирлиләр. Әбием монда да колхозның балыкчылар бригадасына кушыла. Жәен дә, көзен дә Байкалның салкын суында бил тиңентен торып, ике йөзәр центнер балык тоткан көннәре була. Кышын исә тагын да кыенрак, калын-калын бозларны тишеп, бәке ясыйсы, бозланып каткан авыр ятьмәләрне боз астыннан тартып чыгарасы... Элек бу эшне бары тик ирләр башкарса, хәзер бригадада хатыннар да яшь кызлар гына...

Бу авылда әбием Анна исемле кыз белән якынаеп китә. Дуслыклары гомерлек була аларның. Анна Марченконың шаяртып кына: «Әйдә әле, Соня, ашарга әзерлә!» – дигән сүзеннән әбием ашчы булып китә. Яр буенда учак ягып, бригададагы егермедән артык кешегә тәмле ашлар пешерә. Токкан омульнең берсенә дә тияргә ярамый, ул фронт өчен! Үзләренә вак-төяк балыклар гына. Ач булмаганнарына сөенеп, анысына да шөкер итәләр.

Жиңү көнен дә хәтерли әбием. Шатлыклы хәбәрне Посольск станциясеннән ишетеп кайта. Күз яшьләренә коенган көн була ул. Кемдер шатлыктан, ә кемдер якын кешесенең инде мәңге кайтмаячагын уйлап елый.

Сугыштан соң да тормышлар тиз генә үзгәрми әле. Һаман да шул ук эш, һаман да шул балык...

1948 елны әбием үзләре шикелле Татарстаннан килгән татар егете Хәйруллин Мансур белән гаилә кора. Бабам ул вакытта фронттан кайтып, Колесово колхозында шофер булып эшли. Унөч балага гомер биреп, жиде малай һәм алты кыз үстерәләр. Әбием Софья Хәйруллина I һәм II дәрәжәдәге «Ана даны» ордены белән бүләкләнә. «Бөек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәте өчен» медаль иясе дә ул.

Әбием пенсиягә чыкканчы – 25 ел «Кабанский» совхозында эшли. Балаларын да эш сөя торган, тәртипле кешеләр итеп үстерә. Бу якларда төпләнеп, үз язмышлары белән килешсәләр дә, алар гел туган якларын – Татарстанны сагынып яшәде. Өйгә «Сөембикә» журналы килгән көн –

Фото: Анна Арахамия

көтеп алынган бәйрәм кебек иде. Әбием бу журналны әле бүген дә алдыра, хәрефен дә калдырмыйча, кабат-кабат укый.

Авыр сынаулар аша узарга туры килсә дә, әбием үзен бәхетле саный. 27 оныгы, алардан туган 33 туруны «әбием», дип, уратып алса, йөзләре балкып китә.

Виктория ХӘЙРУЛЛИНА.
Бурятия Республикасы.

Аны авылдашларыбыз, ихлас күңелдән яратып, безнең «ашыгыч ярдәм» дип йөртә. Юкка әйтелмәгән аңа бу исем. *Вәсилә Мәннанова Минзәлә медицина училищесын тәмамлаганнан соң гомере буе шәфкать туташы булып эшләде. Лаеклы ялга чыккач, туган нигезенә – Кузкәй авылына кайтып өйләрен яңартты.*

Ачык йөзле, җор телле Вәсиләбез бүген авылдашларга ярдәм итеп, авыл тормышында кайнап яши. Кемгә укол ясый, кемгәдер Минзәләдән яисә Чаллыдан дару алып кайтып бирә, кемдер район больницасына барырга аптырап йөри – Вәсиләнең машинасы «җигелгән», гадәтенчә, ярдәмгә ашыга.

Китапханәнең актив укучысы да ул. Китаплар дөньясында аның белән сөйләшеп утырабыз:

– Мин әбием белән әниемә бердәнбер кыз бала булдым. Әбием Фәрхенур сабыр холыклы, акыллы, бик ярдәмчел иде. Миңа ике ай чагында әни әтидән аерылып кайткан, яңадан кияүгә чыкмаган. Яшәү өчен авыр еллар булган. Ирсез килеш газап чигеп алып барылган тормыш та сәламәтлеген какшаткандыр, больницада еш ята иде. Янына баргач, аңа укол кадаганнарын кызыгып карап торам. Табиб булу теләге шул чакларда барлыкка килде. Кечкенә чагында уйнаганда да, инде мәктәптә укыганда да түшемә «врач» дип язып әлә идем. Уйный башласак, үземнең «медпункт»ым булыр иде.

Урта белем турында аттестат алуга, Минзәлә медицина училищесына юл тоттым. Башта шәфкать туташы һөнәрен алыйм әле, кайтып йөрергә авылга да якын. Тора-бара күз күрер, дидем...

Училищеда уку аңа бик җиңел бирелә, инде диплом алыр чак та җитә. Элек уку йортын тәмамлаган яшь белгечләргә эш урынына юллама бирәләр иде бит. Вәсилә дә хезмәт юлын Түбән Камада башлый. Бераздан күрше Боерган авылы егете Флүргә кияүгә чыга.

Туган авылы Кузкәй больницасында эшләгәндә аның таланты тулысынча ачыла. Дөрес сайлаган ул һөнәрен, кешеләргә аның ярдәме бик кирәк икән бит. Ару-талуны белмичә, вакыт белән исәпләшмичә, үз кичерешләрен, борчуларын сиздермичә, кар-буран, яңгыр булмасын, җәяүләп тә, трактор, ат белән дә ярдәмгә ашыга. Төнлә авыруны Минзәлә больницасына илтеп тапшыргач, иртүк тагын постына чаба. Авыл җире шундый инде, Вәсиләгә фельдшер гына түгел, көне-көне белән врач та, акушер да булырга туры килә. Берсендә бала табар вакыты җиткән хатынны алып киләләр. Минзәләгә җибәрергә соң була, тулгагы көчәя. Муенына кендеге уралып, зәп-зәңгәр булып туа сабый, тавышы чыкмый. Каушап, югалып калмый шәфкать туташы Вәсилә Хамматовна. Бөтен осталыгын җигеп, куркуын җиңеп, муенга ике кат уралган кендекне тиз-тиз чишеп, баланы коткара.

Ләкин югары белемле табибә булу хыялы гына чынга ашмый кала: язмыш Вәсиләгә сынау арты сынау җибәрә. Башта ике айлык улын югалта, аннары фаҗигале төстә ире үлеп китә. Инде югалту ачысын бераз җиңеп, кызы Гөлнара белән матур гына яшәп ятканда, 22 яшьлек йөрәк парәсе дә якты дөнья белән хушлаша. Җир күтәрә алмаслык бу ачы хәсрәткә ничек түзгән ул үзе генә белгәндер. Бу вакытта Вәсилә КАМАЗ заводларының берсендә медпункт мөдире булып эшли. Бирегә дә тырышлыгы, һөнәри осталыгы белән танылa. Лаеклы ялга чыккач, картаеп барган әнкәсе Гыйльменурны карарга туган йортына кайта. Инде 90 яшькә җиткән әнкәсе дә дөнья куйгач, Вәсилә апа бөтенләй ялгыз кала. Ә яшәргә кирәк, ул кул кушырып утыра торган заттан түгел. Җиңел машина алып җибәрә. Шуның белән авылдашларына булыша башлый. Әйткәнемчә, даруын алып кайтып бирә, кирәк кешегә укол ясый.



Амбулатория көндез генә эшли, ә чирнең төнлә кузгала торган начар гадәте бар. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәмгә әзер ул. Яралы йөрәкле шәфкать туташы Вәсилә Хамматовна кешеләргә яхшылык эшләп күңеленә рәхәтлек ала.

Шулай өч ел элек республика программасы нигезендә авылда су торбаларын яңартып чыктылар. Авылда ялгыз, өлкән кешеләр күп. Урамда траншея казып, торба алыштырганда көннәр буе килгән эшчеләр арасында кайнашты. Торба-кран кирәкме, башка кирәк-яракмы – Вәсилә апа Чаллыга, Минзәләгә барып бөтенесен алып кайтып кына торды. Су кертүчеләрне күршеләре белән алмашлап ашатуны да оештырды. Берәүләргә коммуналь хезмәтләргә түләү икеләтә-өчләтә артып килгән. Бу очракта да Вәсилә апага мөрәҗәгать итәләр, ә ул кайнар линиягә шалтыратып, дөреслекне юллый...

Менә шундый олы йөрәкле, ни генә булмасын, тормышта нинди генә сынаулар килмәсен, яшим дип яши белүче, күңеле изгелекләрдән тукылган Вәсилә Мәннанова барыбыз өчен матур өлге.

Тәнзилә ШӘЙХНУРОВА.
Тукай районы, Кузкәй авылы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

«ЯШӘРГӘ КӨЧЕМ КАЛМАДЫ...»

Мин бу хакта язмыйча булдыра алмыйм. Беренчедән, күңелем әрнүе азрак булса да басылмасмы, дим. Икенчедән, бәлки, бу язмам кемнедер вакытында олы фаҗигадән коткарырга ярдәм итәр...

Фото: www.pixabay.com

Ания (исемен үзгәрттем) белән мин яңа мәктәпкә күчкәч, өченче класста укыганда таныштым. Өйләребез дә янәшә генә торгач, укудан да бергә кайтабыз – дуслашып киттек. Аларда кунакта булганда гел пластинкалардан матур җырлар тыңлый идек... Аниянең туган көнендә әнисе мин моңарчы күргәнем дә булмаган искиткеч тәмле пирожныйлар пешереп ашатканы истә калган.... Өлкән классларда безнең юллар аерылды: бу вакытта инде артык якын дуслар түгел идек. Ания 9 нчы класстан соң туган ягына – Мәскәүгә күчеп китте...

Яңадан без югары уку йортларын тәмамлап, икебез дә бер шәһәргә кайтып урнашкач аралаша башладык. Бергә Испаниягә барып ял иттек, бер-беребез белән серләшә, киңәшләшә идек. Кайвакыт эштән төшке ашка да аңа кунакка кереп чыгам: аш-суга бик оста иде ул. Юмарт, ярдәмчел, нинди генә хәл булса да, сине юатыр, тынычландырыр, яхшы сүзен җәлләмәс... Ул да, мин дә бер-бер артлы Мәскәүгә күчеп килдек, шул чакта да бик күп ярдәм итте ул миңа. Яхшы күңелле, ихлас, беркайчан беркем турында начар сүз әйтмәс: «Не суди, ты же не знаешь», – дип кенә куяр. Олы кайгы кичерсә дә, һәрвакыт ачык, позитив (Аниягә 17 яшь чакта, бик интегеп, яман шештән әнисе үлеп китте)... Холыкларыбыз төрле булса да, чын дустым, терәгем иде ул минем.

Гаилә кору, кыз бала табу хакындагы хыялы тормышка ашмады аның. Үзеннән яшьрәк егетне сөеп, авырга узуы ачыклангач, тегесе Анияне калдырып китте. Баласын дустым ялгызы гына үстерде, аның шәхси тормышында башка җитди мөнәсәбәтләр булмады. Тормыш йөген үзе тартты. Берничә ел элек әтисе дә вафат булгач, бөтенләй берүзе калды. Бертуган абыйсы, башка туганнары белән дә, нигәдер, бик якын түгел иде алар. «Беләсеңме, мин бит бер ялгызым, бу дөньяда бер таяныр кешем дә юк», – дип ачылып китеп сөйләгәне хәтеремдә.

Шатлыгы, мәшәкате белән тормыш шулай алга бара торды. Әмма берничә ел элек Ания эшен югалтты: белгеч буларак, вазыйфасын яхшы белә, ләкин характеры үзенчәлекле иде аның. Шомарта-нитә белми, турысын бәрә дә әйтә. Шул сәбәпле, хуҗасы белән килешә алмады. «Офис кешесе түгелмен, үземә үзем хуҗа булып кына эшләргә кирәк миңа», – дип аңлатты ул безгә...

Бухгалтер булуына карамастан, акча тота белми иде Ания. Бар шундый кешеләр: алар артык юмарт, акчаны санап тормый – бөтен кеше әйбернең арзанлысын алганда да, бу иң кыйммәтлесен сайлый. Әтисе зур кеше булганлыктан, барлыкта үскән, шуңа ашамлыкның да иң яхшысын, сыйфатлысын гына ала иде. Хезмәт хакы начар булмаса да, ул аны беркайчан җиткерә алмады. Кыйммәтле кухня алды, машинасын алыштырды – миллионнан артык кредиты җыелды. Һәм шул вакыт аны эштән кыскарттылар... Кредитын түләргә акча табалмыйча көяләнеп, Ания чиргә сабышты. Аның ике ай караваттан тора алмыйча, атналар буе йокламый интегүләре, умырткасы төзәлмәслек авыртудан кычкырып ятулары! Остеопатларның, авыртуны баса торган даруларның – берсенең дә файдасы тимәде. Нишләргә белми аптырап, азрак аракы йота башлады Ания – әйтүенчә, аның хәлен

шул гына җиңеләйтә иде. Аннары көч-хәл белән, бармыйм, дип озак баш тартса да, без аны больницага урнаштырдык. Ярый, нервыларын ныгытып, терелеп чыкты.

Бәланең башы шул чакта башланды, ахрысы.

Мәрхүм әтисе Аниягә һәм аның улына аерым фатирлар калдырган иде. Әмма чирләгәннән соң Ания: «Бу өйдә гел начар хатирәләр... Аннары банкка бурыч түләргә дә кирәк», – дип, үзенекен алыштырырга уйлады. «Яхшыракны алам, ә калган акчаны, төзелүче йорттан улыма яңаны алырга дип салып куям», – дип, баласының да фатирын сатты. Беребезне дә тыңламыйча, кабат кыйммәтле җиһазлар алды, ремонт ясатты, әллә никадәр акча түгеп, ялга барып кайтты. Әллә фатирларны арзанга сатты, әллә акчасын юкка-барга туздырып бетерде – нәтиҗәдә, Аниянең улына фатир алырга акчасы җитмәгәне, ә банкка һаман шул 1 миллион бурычы калганы беленде. Без, дуслары, аптырап калдык, әмма кеше кесәсенә кереп булмый бит... Яңадан эшкә урнаша алмады ул. Үз эшен башлап карар өчен тагын 1 миллион чамасы акча кирәк иде. Беркем белән киңәшләшмичә, нindидер шикле кешеләр аша ялган белешмәләр ясатып, бердәнбер фатирын банкка залогка куеп, тагын кредит алганын соңыннан гына ишеттек. Бөтен ышанычы шул бизнес иде, әмма анысы да барып чыкмады... Кабат кан басымы күтәрелде, куллары калтырый башлады Аниянең. Очрашкан саен: «Даруларның файдасы тими», – дип зарланды ул. Ләкин табибларга күренергә, больницаларга йөрергә вакыты юк иде: ялгыз хатынның проблемаларын үзеннән башка кем хәл итсен?

Соңрак аның бурычы инде 5–6 миллионга җитүе ачыкланды. Фатиры хакыннан да күбрәк... Әмма без Аниянең сәер адымнарына инде күнегә башлаган идек: әйткәнне тыңламагач, кешене нишләтәсең? Бала-чага түгел бит...

Узган ел без аның белән бер-беребездән ераклаштык. Нигәдер, минем Ания белән сөйләшәсем килми башлады. Еллар буе башы авырлыктан чыкмаган кеше белән аралашу кыен бит: аның зары сиңа да күчкән кебек була. Ә бит үз тормышымда да проблемалар җитәрлек! Шулай да аны бөтенләй ташладым дия алмыйм: хәлен белеп, кирәк чакта акчалата да, киңәш белән дә, күңелен күтәреп тә – кулдан килгәнчә ярдәм иттем. Үзем эчтән аның өчен борчылам, янам. Үземне тиргим: нигә каты бәгырьләндең, ешрак шалтырат дустыңа, дим. Ә ул кайвакыт язганыма өчәр көн җавап та бирми...

Соңгы вакытта ул бөтенләй әллә нишләде. Нидер майтара да, без моны азактан гына беләбез. Кайвакыт бер үк нәрсәне миңа – бер, икенче дустына икенче төрле итеп сөйли. Берни аңламыйбыз!

Ярты ел элек бу бетмәс кредит хәлләреннән тәмам башы буталып: «Түзәр хәлем калмады, тәрәзәдән сикерсәм, улымны карарсыңмы?» – дип шалтыратып шомга салды мине. «Юк, бу турыда уйлама да!» – дидем. Тиз генә бер сумка ашарга алып, сеңлем белән янына киттек. Юаттык, тиргәдек, аннары әйбәтләп сөйләшеп, кәефен күтәрдек... Ул яңа планнар корып калды. Карантин башлангач та хәлләрен белеп тордым.

Шуны да аңлагыз: эчкече кеше – авыру, аның аңы белән аракы идарә итә, шуңа күрә киңәш белән генә ярдәм итүдән файда юк.

Кәефе юк, сәламәтлеге начар иде – нык ябыкты Ания, әмма фатирын сатып, бурычын түләр, азрак дәвалангач, эшкә керер, әкренләп тормышы җайланыр дип өметләнә идек...

Шул вакыт дуслар арасында: «Ания эчә икән», – дигән сүз чыкты. Имеш, кемдер янына барганда, аңардан аракы исе аңкып торган. Әмма Ания элегрәк тә: «Мине туганнарым яратмый, йә тәртипсез, йә транжира, йә эчә дип нахакка кыерсыталар», – дия иде. Аннары: «Файдасы булсын өчен, күп дозада «пустырник» эчәргә туры килә. Югыйсә булышмый», – дигәнен дә ишеткәнем булганга, бу сүзләргә минем үземнең әллә ни исем китмәде. Гайбәттер...

Аңа соңгы тапкыр барганда өс-башы бер дә каралмаган булуга да зур әһәмият бирмәдем шул. «Урамда түгел бит, ә без үз кешеләр – гаеп итмибез», – дип уйладым. Өч-дүрт ай элек кафеда күрешкәндә, чәченең таралмаган, киеменең таушалган (ә ул элегрәк гел бизәнеп, прическалар ясап – үз-үзен бик карап йөри иде), йөзенең карасу-соры төстә булуын да һаман шул чиренә сылтадым. Инде кайчаннан юньләп ашый алмыйм, төнлә йокламыйм дип зарланды, хәлем юк, диде. Берничә тапкыр һушын да югалтканын әйтте. Көпә-көндез йоклап калып, бик кирәкле белешмәне алырга бармаганын әйткәч тә, мин шалтыратканда әзрәк теле көрмәкләнеп торуын сизгәч тә, барыбер шикләнмәдем шул: арыган булгандыр, кан басымы да бик югары бит дип уйладым. Үземнең беркатлылыгыма шаклар катам хәзер! Тирә-юнемдә бүтән эчкән кеше булмагач, эшнең нидә икәне кайдан башыма килсен соң?!

Соңгы көннәрендә табибка да барган, анализлар да биреп йөргән ул. Ләкин, «кич уңмаган, һич уңмас» дигәндәй, вакыт үткән булган шул инде. Хәле тәмам начарлангач, «ашыгыч ярдәм» чакырткан. Реанимациядән кире үз аяклары белән инде чыга алмады – вафат булды Ания. Бавыр циррозы...

Җеназада башка дуслары белән очрашып сөйләшкәч, аралашкач, чәчләрем үрә торды! Бөтенләй белмәгәнмен икән Аниянең хәлләрен... Узган көз аңа нарколог чакырткан булганнар. Файдасы тимәгән... Чынында, дусларының һәркайсы аңа гел ярдәм итеп торган. Бер ерак шәһәрдәгесе күптән түгел: «Кил, яшәргә урын бар, эш белән дә булышырмын», – дигән булган. Димәк, хәлләре бөтенләй өметсез булмаган! Әмма күптән яшел елан көенә йөргән икән шул инде Анияебез.... Менә нигә үзгәргән, менә нигә барыбыздан да хәлләрен яшергән, алдашкан, кеше аңламаслык адымнар ясаган! Иң аяныч, түтәсе дә: «Кызганыч, бик иртә китте, әмма алдагысы, бәлки, моннан күпкә начаррак булыр иде», –

PRESSA

диде... Дусларының берсе: «Ярый әле үз-үзенә кул салмады, кешечә китте Ходай каршына. Бу хакта да күп сөйли иде бит», – дип авыр сулады. Соңгы вакытта аңарда кунакта булган Ания: инде бер көн аракысыз тора алмаган, өйдәге запасларын кунагыннан хәтта яшерергә мәҗбүр булган хуҗабикә...

Аниянең вафатыннан соң үземне бик битәрләдем. Нишләп күбрәк игътибар бирмәдем, нигә янына ешрак йөрмәдем? Бәлки, баштан ук аның белән кырысрак булырга, сәламәтлеге какшагач ук кулыннан җитәкләп алып больницага илтергә кирәк булгандыр?.. Өен залогка салгач та: «Нишлисең син?! Эшең барып чыкмаса, урамда каласың бит. Үзең дә, балаң да!» – дип кычкырып җилтерәтәсем килде. Ләкин кыенсындым. Җайлап кына шул хакта әйткәч, ул миңа: «Тынычлан, мин барысын да исәпләдем, беләм», – дип җавап бирде... Әйе, башта үземне гаепләдем, аннан, элеккеге без яраткан яхшы күңелле, көр кәефле яшь хатын урынын алган ямьсез, кызганыч, депрессив Аниягә кинәт ачуым чыкты! Алай ук ялгыз да, мескен дә булмаган бит ул. Әнә күпме кеше аңа ярдәм кулы сузган! Мин дә аның өчен ничек өзгәләндем, ә ул тормышын җайлауны да, улын да уйламаган, эчеп тик яткан... Аннары кабат элеккеге Анияне искә алып еладым. Күңел һаман әрни: аңа нибары 42 яшь иде бит. Яшисе дә яшисе иде әле! Улы белән нәрсә булыр, белмим: Аниянең туганнары белән мөнәсәбәте, әйткәнемчә, яхшы түгел иде соңгы елларда, кредит-фатир авантюрасының да беркем очына чыкмаслык...

Бу ачы тәҗрибәмнән чыгып, шуны әйтәсем килә. Беренчедән, әллә нинди хыялларга бирелеп, түләп бетерә алмаслык кредитлар алырга кирәкми. Берәүгә дә! Заманы да ышанычлы түгел, аннары бурычлар нервыларны да бик ашый. Икенчедән, якыныгыз турында «эчә» дигән сүз чыга икән, моңа колак салырга кирәк: гадәттә, утсыз төтен булмый – мондый сүз берничә яктан ишетелсә, бигрәк тә. Әгәр дә мондый яман хәлгә тарыган кешенең башка дуслары, туганнары белән якын элемтәдә түгел икәнсез, шалтыратышып, очрашыгыз – уртага салып, хәлне ачыклагыз. Безнең хата нидә булды? Һәркем үзенчә булышырга тырышкан, әмма хәлләрнең без уйлаганга караганда күпкә куркынычрак икәнен тулысынча белмәгән. Шикләнүләр дөрес булса, ай-ваена карамыйча, аны ничек тә табибка күрсәтергә кирәк: салган кеше үзен беркайчан да «эчкече» димәячәк, төрлечә акланачак, алдашачак... Өченчедән, якын кешегезнең кара полосасы бик озакка сузылса, кайвакыт каты торырга да кирәк: стресстан араларга, вакытында дәваларга, табибларга, психологларга мөрәҗәгать итәргә... Кеше күп вакыт үз хәлен сөйләмәскә дә мөмкин: ул йә ояла, йә кыенсына, йә яшермәкче була һәм шул ук вакытта үз-үзен коткарырга көче дә җитми... Нәтиҗәдә – фаҗига.

Мондый афәтләрдән Ходай барыбызны да сакласын иде.

Камилә ӘЮПОВА.
Мәскәү.

ТАБИГЫЙ КОСМЕТИКА

Себер үсемлекләре экстрактлары нигезендә ясалган Natura Siberica Россия бренды ICE Professional by Natura Siberica чәчләр өчен беренче профессиональ косметика коллекциясе чыгара. Билгеле булганча, бу бренд органик косметика булуы белән дан тота. Әлеге линия матурлык салоннарында стилистлар куллану, өй шартларында чәчләрне тәрбияләү өчен дә каралган.



Продуктны ясаганда компания стилист-парикмахерларны, профессиональ трихологларны җәлеп иткән. Куллануч ылар ихтыяҗын канәгатьләндерерлек косметика булдыру өчен, тикшеренүләр берничә ел алып барылган. Марка сыйфатка, актив ингредиентларның югары концентрациясенә һәм профессиональ инновацион компонентларның Себер үсемлекләре концентрациясе кушылмасына өстенлек биргән. Бу чәчнең табигый көчен һәм сәламәтлеген кайтаруга ярдәм итәчәк.

ICE Professional by Natura Siberica – көндәлек эшләрендә стилистлар очрашкан иң катлаулы эстетик проблемаларны хәл иткәндә кулланыла торган 6 линия һәм 61 продукт ул. Зарарланган чәчләрне дәвалау, дымландыру һәм тукландыру, детокс, чистарту һәм баш тиресен тынычландыру, буялган чәчләрнең төсен, шул исәптән, блонд төсмерләрен саклау, бөдрә чәчләрне карау һәм башка төрле тәрбия өчен косметика бар. Коллекция ассортиментында: ике төрле күләмле (250 һәм 750 мл) шампунь һәм кондиционерлар, чәчләр өчен маска, сыворотка һәм спрейлар, продуктларны баетыр өчен концентратлар, чәч тиресе өчен пилинглар, кремнар.

ICE Professional by Natura Siberica коллекциясе Россия һәм БДБ илләрендә бизәнү әйберләре сатыла торган люкс челтәрләрнең профессиональ косметика бүлекләрендә, профессиональ косметика кибетләрендә, эре маркет- плейсларда һәм шулай ук Natura Sibericaның фирма кибетләрендә сатыла.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

ДУЛКЫНЛАНДЫРГЫЧ КОНЦЕРТ

Башкача мөмкин дә түгел! VI «TMTV» музыкаль телевизион премиясен тапшыру тантанасы «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә узды. Өч мең тамашачы сыйдырышлы Илһам Шакиров исемендәге концерт залында бу беренче колачлы тантана иде.

Татарстан эстрадасындагы иң көтелгән музыкаль вакыйгаларның берсе ул. Пандемия аркасында яраткан җырчыларының тере тавышына сусаган тамашачы югары дәрәҗәдәге концертны карарга, залны күрергә дип килде. «Барс Медиа» компанияләр төркеме шундый мөмкинлек тудырды.

Затлы сәхнә, заманча акустика, ут, матур декорация, республиканың моңарчы күрелмәгән мәйдандагы зур концертлар залы... Тамашачы да, җырчылар да, оештыручылар да дулкынланды. «Илһам Шакиров исемендәге концертлар залында чыгыш ясау аеруча күңелле һәм бик тә җаваплы. Монда беренчеләрдән булып концерт оештыруыбыз да горурлык тудыра. Һәр тамашачыда бәйрәм рухы тудыра алу минем өчен дә, команда өчен дә мөһим», – диде компаниянең Директорлар советы рәисе Камил Гәрәев.

«Казан Экспо» шәһәрдән 20 чакрымнан артык ераклыкта. Монда килеп җиту өчен компания махсус трансферлар оештырды. «Ә миңа бирегә килеп җиту өчен берничә минут кына кирәк булды. Самолеттан төштем дә туп-туры концертлар залына элэктем. Тамашачыларымны бик сагынган идем, зур залдан зур энергетика алдым», – диде Татарстанның халык артисты Айдар Галимов.

Кызыл келәмнән узганнан соң, татар эстрадасы Олимпында торган җырчылар да, яңа гына калкып килүче йолдызлар да чыгыш ясады. Алар арасында Элвин Грей, Айдар Галимов, Ришат Төхвәтуллин, Әнвәр Нургалиев, Зәйнәб Фәрхетдинова, Филүс Каһиров, Иркә, Данир Сабиров, Рифат Зарипов, Зинира һәм Ризат Рамазановлар, Гүзәлем һәм Салават Миңнехановлар, Гөлназ Асаева һәм башкалар бар иде. Концертта шулай ук рус җырчысы Роман Плеханов, башкорт җырчысы Азалия Вәлиева, Казакъстанда туып-үскән Шаһзат Разметов татарча җырлады. Халык сайлавы буенча иң яхшы дип табылган 40 җырчыга статуэткалар тапшырылды.

Музыкаль премия бирү тантанасында «Яңа йолдыз» вокал бәйгесенең җиңүчесе Эльвира Мифтахованың дебюты булды. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева Әнвәр Нургалиевка Татарстанның атказанган артисты исемен тапшырды.


Биш сәгать барган концерт тамашачыны һич арытмады. Залның Элвин Грейга кушылып җырлавы халыкның мондый тамашаларга сусавын сиздерде. «Барс Медиа» компаниясе инде алтынчы ел тамашачыларына зур шоу ясый. Пандемия аркасындагы тәнәфестән соң, ул быел аеруча кадерле бүләк иде.

16+

Фото: Анна Арахамия

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА




Фотолар: гаилә архивыннан

ТУРГАЕМ, САГЫНДЫМ!..


Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Фаил Шәфигуллинның иң популяр җырларыннан берсе булды «Яшьлегем тугае». Композиторы – моңа кадәр халык яратып кабул иткән бик күп матур көйләр авторы Зиннур Гыйбадуллин.

1980 нче елларда алар: Фаил Шәфигуллин, Зөлфәт, Зиннур Гыйбадуллин, кайвакытта тагын берничә әдәбият-сәнгать әһелен алып, байтак кына районнарга, өлкәләргә очрашуларга йөрделәр. Үзләре белән бергә, бер-берсе турында шактый күп мәзәкләр дә ияртеп кайталар иде. Күп вакыт ул мәзәкләр Зиннур Гыйбадуллинның гаҗәп дәрәҗәдә беркатлы, һәрнәрсәгә бик тиз ышанучан, ифрат та нечкә күңелен чагылдырып, шуның аркасында үзеннән-үзе кызык хәлләргә дучар булган композитор турында була торган иде. Мәсәлән, Зөлфәт, төн уртасында чыгып китеп, шыгыр-шыгыр өй кыегында йөри икән дә, Зиннур Гыйбадуллин, башына килгән көен баяны телләрендә «биетергә» куркып, шагыйрьнең түшәгенән күтәреп ята ди. Иртәнгә инде гениальный көйнең пары күпкә кимегән була, имеш... Фаилнең Зиннур абый белән дуслыгы шул вакытта башланды. «Яшьлегем тугае»ннан соң «Язгы су гөрләде», «Кырда чәчәкләр күп диләр» җырлары туды. «Кайнана» моноопереттасына да көй язылды. Әмма арада иң бәхетлесе, иң озын гомерлесе барыбер «Яшьлегем тугае» булып калды. (Тарих өчен әйтим, ул вакытта Зиннур Гыйбадуллин Зөлфәт сүзләренә дә берничә җыр язды. «Талисман», «Атлар чаба», «Каеннар күтә» шундыйлардан иде.)

Яшьлегем тугае

Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды.
– Күзләрең сагышлы, –
Дип әйтте бер тургай,
Нишлим соң, тургаем, сагындым!

Ничәнче мәртәбә
Тургайлар килделәр,
Тугайлар яшәрде, ямьләнде.
Өздереп сайрады,
Сайрады бер тургай,
Читендер сагыну хәлләре.

Өздереп сайрама,
Хәлемне сорама –
Ул үзе аңлар бер, тургаем.
Минем күк сагынып,
Кайтыр ул, тургаем:
Онытмас яшьлеге тугаен.



Сулдан-уңга: Фаил Шәфигуллин каләмдәшләре Әхсән Баян, Гәрәй Рәхим белән. 1980 нче еллар.

Бервакыт күршебез Зирәк Йосыпов, тагын берничә кеше Бауман урамыннан барабыз шулай. Кинәт кенә колакка таныш моң килеп керде.

– Бәй, бу бит «Яшьлегем тугае»! – ди Зирәк.

– Әйе шул, Фаилнең җыры, – дим.

– Әйдә барыйк әле, кемнәр җырлый икән?

Киттек. Чернышевский чатындагы күпер асты кебек урында – бер төркем студентлар. Арадан берсе, кулларын дирижер кебек төрле якка тибрәлдереп, төркемгә дәрт биреп тора...

Менә шулай итеп, «Яшьлегем тугае» сәхнәдә дә, табын ашларында да, күңелле компанияләрдә дә – өлкәннәрнең дә, яшьләрнең дә яраткан җырына әверелде. Җырны беренче булып башкаручы Нәфисә Василова аңа мәңгелек гомер, үлмәс фатиха биргән диярсең. Нәфисәдән соң кемнәр генә күтәреп алмады да, нинди генә талантлы җырчылар башкармады аны. «Яшьлегем тугае» хәзер дә бик күпләрнең репертуарында.

Мәрхүм Зиннур Гыйбадуллин үзенең 1988 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан җырлар китабын, шушы җыр исеме белән «Яшьлегем тугае» дип атаган. Фаил Шәфигуллинның 2014 елда нәшер ителгән яңа шигырьләр китабын без дә «Яшьлегем тугае» дип исемләдек. Менә шулай итеп җыр шагыйрьнең дә, композиторның да визит карточкасына әйләнде. «Яшьлегем тугае» дип әйтүгә үк, аның бер канаты булып Фаил Шәфигуллин, икенче канаты булып Зиннур Гыйбадуллин күз алдына килә. Колакта Нәфисә Василова, Хәйдәр Бигичев, Мирсәет Сөнгатуллин, Миңгол Галиев, Зөһрә Сәхәбиева, Хәмдүнә Тимергалиева, Газинур Фарукшиннарның көчле дә, моңлы да тавышлары яңгырый башлый:

Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды.
– Күзләрең сагышлы, –
Дип әйтте бер тургай...

Чү! Кем турында сүз бара? Кемнең күзләре сагышлы? Автор ни өчен боеккан, борлыккан күзләргә, сагынуның читенлегенә басым ясый? Безнең, ягъни гаиләсенең, мөлдерәмә тулы хәсрәт газабы белән каласын алдан сизгәнме? Әллә сабый вакытыннан ук ачы югалтуны, үксезлекне татыган тормыш тәҗрибәсе чагылышымы бу? Бик иртә тол калган әнисенең күңел халәтен күреп үскәнгә шундый юллар язылганмы? Сугыш афәте калдырган бихисап күп ялгызларның, ятимнәрнең моңсу да, ямансу да язмышы балачактан ук таныш булганга күзләре сагышлымы? Ничек кенә фаразласак та, шагыйрьнең талант тоемы күпләр өчен уртак булган сагыну сагышын – кешенең иң нечкә кылларын тибрәтеп, күңеленә тиясен белеп-аңлап тотып алган.

– Нишлим соң, тургаем, сагындым!..

1982 ел. Фаил Шәфигуллин инде зур, талантлы язучы булып өлгергән билгеле шәхес. 5 октябрь төнендә билгесез кешеләр тарафыннан кыйналып, алган җәрәхәтләреннән аңына килә алмыйча, 7 октябрь төнендә мәңгегә күзләрен йома. Фаилнең үзенең дә фаҗигале язмышын белгәнгә күрә, әлеге җыр яңгыраганда, якыннарының гына түгел, башка бик күпләрнең дә күзләренә яшь тула.

Өздереп сайрады,
Сайрады бер тургай,
Читендер сагыну хәлләре...

«Сагыну хәлләре» – читен генә түгел, бик авыр да халәт шул. Кайтыр җирдә булса, сагына-сагына түзәргә бик риза булыр идең дә, әмма кайтмасын белеп сагыну – бу инде гомерлек газап, гомерлек чир!

Әлеге җырның халык күңеленә уелып, сеңеп калуын күр син! Фаил Шәфигуллин турындагы истәлек-мәкаләләрнең бик күбесе шушы җырның сүзләре белән башланып китә, аерым юллары эпиграф итеп алына. Әйе, сүзләре дә, көе дә искиткеч халыкчан шул бу җырның. Кырык ел элек халык ничек яратып кабул иткән булса, хәзер дә популярлыгын югалтмый ул.



Бәләкәй вакытында авыз эче бозылмый калган бала юктыр, мөгаен. Балалар арасындагы иң киң таралган стоматологик чирләрнең берсе ул. Еш кына хәтта яңа туган сабыйларда да очрый. Яшь әниләрне хафага сала, баланың исә тынычлыгын ала торган стоматит хакында Республика балалар клиник хастаханәсенең стоматологы Венера ИШТАЕВА белән сөйләшәбез.

СТОМАТИТ

Стоматит – авыз куышлыгының лайлалы тышчасы ялкынсыну. Бәләкәй балалар арасында еш очравының сәбәбе әлеге чирнең шулай киң таралышында гына түгел, ә балаларның әле иммунитетлары ныклап җитлегеп бетмәүдә дә. Организмның саклык чаралары камил булмаганлыктан, нәкъ менә сабыйлар ешрак авырый да инде.

Стоматитны вируслар, гөмбәләр, бактерияләр китереп чыгара. Күп очракта балалардагы стоматитның төп сәбәбе – вирус, аның да 80 проценты герпеслы стоматит була.

Төрле травмалар, җәрәхәтләр дә авыз эченең ялкынсынуына юл ачарга мөмкин.

Балаларда стоматитның афтозлы төре дә очрый. Ул аллергия һәм инфекцияләр аркасында барлыкка килә. Гадәттә, бу төр белән дүрт яшьтән өлкәнрәк балалар авырый. Афтозлы стоматит дәвамлы характерда уза, елга бер яки ике тапкыр кабатланырга мөмкин. Моның сәбәпләрен тирәннәнрәк эзләргә кирәк, гадәттә аны ашкайнату системасындагы чирләр, аллергия, баланың тән төзелешендәге тайпылышлар, паразитлар китереп чыгара.

Билгеләре:

- бала тынычсызлана, ашаудан баш тарта;
- авыз куышлыгында сулы куыкчыклар барлыкка килә;
- баланың уртында, яңак эчендә түгәрәк җәрәхәтләр, ялкынсынулы төрткеләр була;
- баланың тамак төбе, теле, яңак эчләре кызарып ялкынсына;
- авыз эчендә аксыл-соргылт төстәге кунык (налет) барлыкка килә;
- баланың сулышыннан авыр ис килә;
- баланың селәгәе ага;
- ирен читләрендә эрен барлыкка килә;
- температура күтәрелә.



Табиб киңәше





- баланың авыз эче гигиенасын төгәл саклау;
- соскаларны, (имезлекләр) яхшылап дезинфекцияләү;
- баланы имезгәндә гигиена таләпләрен үтәү;
- баланың беренче тешләре чыга башлауга даими рәвештә стоматологка күренү;
- сөт тешләрен чистарту өчен махсус пасталар һәм йомшак щеткалар куллану;
- баланың иммунитетын ныгыту.

Фото: www.pixabay.com

Сәбәпләре

- иммунитетның зәгыйфьлеге;
- вируслар;
- гөмбәләр (аеруча кандида гөмбәсе). Әлеге төр стоматит, нигездә, күкрәк балаларында очрый;
- озак вакыт антибиотиклар кабул итү;
- бактерияләр (ешрак стафилококк, стрептококк);
- авыз куышлыгындагы төрле вак җәрәхәтләр.

БУ МӨҺИМ

стоматитны дәвалый башлаганчы, аның этиологиясе ачыкланырга тиеш. Дәва чараларына авыртуны басучы һәм авыруны китереп чыгарган төп сәбәпләрне юк итүгә юнәлдерелгән препаратлар керә. Стоматитның нинди төре булса да, ризык җылымса гына булырга тиеш. Бу вакытта ачы, тозлы, борычлы, кайнар, салкын ризыклар тыела. Вакытында дәваланмаган гөмбәле стоматит аркасында кыз балаларда – вульвит, ир балаларда баланопостит, эзофагит, энтероколит, пневмония, цистит, артрит кебек катлаулырак чирләр да башланырга мөмкин.



ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.



Хатын-кызның сәламәтлеге – кешелекнең киләчәге ул. Җир йөзенә сәламәт бала тудыру, аны тәрбияләп үстерү өчен иң беренче чиратта әни кеше үзе дә сау булырга тиеш. Организмдагы беренче карашка кечкенә генә булып тоелган проблемалар да киләчәктә катлаулырак хәлләргә китерергә мөмкин. Республика клиник хастаханәсенең гинекология бүлеге табибы Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА белән хатын-кыз сәламәтлеге турында сөйләшәбез.

ПОЛИКИСТОЗ

Поликистоз синдромы – бик киң таралган һәм социаль мөһим саналган чирләрнең берсе. Бала табу яшендәге һәр унынчы хатын-кызда очрый ул. Әлеге чир, нигездә, эндокрин системасындагы көйсезлекләр аркасында барлыкка килә. Нәселдәнлекне, әйләнә-тирәлек тәэсирен дә инкарь итә алмыйбыз.

Гормональ системадагы кечкенә генә җитешсезлек тә дисбалансқа китерә – организмда ир-ат гормоннары арта, хатын-кызларныкы, киресенчә, кими. Шуның аркасында күкәйлек тирәли каты тышча барлыкка килеп, ул өлгергән күкәй күзәнәкнең чыгуына – овуляциягә комачаулый. Фолликул өлгерми башлау аркасында күкәйлектә күпләгән кисталар барлыкка килә. Чирнең атамасы да шуннан килеп чыккан, поли – күп дигәнне аңлата. Күкәйлекнең тышчасы калыная, әлеге үзгәрешләр аркасында җенси җитлегү чорында инсулин активлыгы күзәтелә. Бер караганда, инсулинның күкәйлектәге кисталарга ни катнашы бар кебек? Ул гормоннарның җитештерелүенә турыдан-туры җавап бирә.

Поликистоз синдромы моннан 80 ел элек билгеле булса да, аның килеп чыгу механизмнары бүгенгәчә тулысынча ачыкланып бетмәгән әле.

Поликистоз билгеләре кыз балада инде яшүсмер чакта ук күренә башларга мөмкин. Әниләр кызларындагы күрем циклының үзгәрүенә игътибарлы булсыннар. Әмма беренче ике елда ул әле тотрыклы булмаска, берничә айга тоткарланырга да мөмкин. Ләкин ике елдан менструаль цикл инде рәткә салынырга тиеш. Проблемалар булса, табибка күренергә һәм дәвалауны үз вакытында башларга кирәк.

Поликистоз синдромы гинеколог тарафыннан дәвалана. Кайчагында эндокринолог киңәше дә кирәк була. Чирне ачыклау өчен комплекслы чаралар билгеләнә. Моңа гормоннарны ачыклау өчен кан анализы да, УЗИ да кирә.

Сәбәпләре:
- эндокрин системасының төгәл эшләмәве;
- калкансыман, бөер өсте бизләрендәге чирләр;
- шикәр диабеты;
- гипоталамус, гипофиздагы көйсезлекләр;
- гормональ дисбаланс;
- нәселдәнлек;
- әйләнә-тирәлекнең тәэсире;
- дөрес тукланмау, гәүдәнең артык авырлыгы;
- абортлар;
- стресслар.

БУ МӨҺИМ

Күкәйлекләрдәге поликистоз синдромы балага уза алмауга, аналык тышчасы гиперплазиясенә, аналык яман шешенә китерергә мөмкин. Менә шуның өчен дә әлеге диагноз куелган хатын-кызлар үз сәламәтлекләренә тагын да җитдирәк карарга, табиб кушканнарны төгәл үтәргә тиеш. Дәвалауның максаты – гормоннар җитештерелүен җайга салу, организмда ир-ат гормоннарын киметү, күрем циклын җайлап, овуляциягә ирешү.

✓


Билгеләре
- күрем циклы бозылу;
- биттә, муенда, ботның эчке якларында каты төкләр барлыкка килү – гирсутизм. Моны гипертрихоз белән бутарга ярамый. Беләктә, аякларда йомшак төкләр булу – табигый күренеш;
- тәнгә бетчәләр чыгу (акне);
- май катламының ир-ат тибына хас булганча тупланую – корсакның аскы ягында, корсак куышлыгындагы әгъзаларда;
- пеләшләнү;
- инсулин активлыгы аркасында култык, касык, муен, беләк бөгелешләрендәге тиренең каралҗымланып торуы;
- корсак тиресендә тартылган эзләр – стриилар барлыкка килү;
- дөрес тукланып та, гәүдәнең авырлыгын нормада тотуның кыенлыгы;
- балага уза алмау.



Республика клиник хастаханәсенең җәмәгатьчелек белән элемтәләр буенча әйдәп баручы белгече Валерия Белова ярдәмендә әзерләнде.

ҖИҺАНДА — ЯЗ!

Апрель ае – табигатьнең керфекләрен яңа ачкан мәле. Тереклек дөньясы яңа көч, яңа сулыш белән яңа тормыш башлый. Бик тиздән бөреләр уяныр, беренче чәчәкләр кояшка елмаер... Әлегә исә тәрәзә төбебездәге «бакчаны» тәрбиялибез. Чәчәбез, күчереп утыртабыз, ашлыйбыз...



Яшелчәчегә

Апрель башыннан да калмый, помидорның иртә өлгерешле сортларын чәчәләр. Март ахырында чәчелгәннәрен исә пикировкалыйлар. Пикировкалауның кирәклеге күпләрдә бәхәс тудыра. Кемдер аны зуррак савытка күчереп утырту белән бутый. Пикировкалаганда үсемлекнең чук тамыр очы чеметеп өзеп алына. Шул рәвешле янтамырлар активлаша. Томат, кәбестә, петуния, лобелия, канәфер чәчәге, бакча җиләге пикировкалаганны ярата. Кыяр, кабак, ташкабак, кавын, аквилегия, мәк, мальва моны авыр кичерә. Борыч һәм баклажанны да пикировкасыз үстерү кулайрак.

Җәйнең беренче аенда ук түтәлдән яңа өзелгән хуш исле кыяр белән сыйлану өчен, апрельдә аны рассадага чәчеп үстерә торалар. Сортына карап, түтәлгә утыртканчы 20–30 көн кирәк, шуннан орлыкларны чәчү вакытын исәплиләр. Кыяр орлыгын турыдан-туры аерым савытларга чәчәләр. Кыяр үсентесе җилсез һәм җылы урынны ярата.

Теплицасы булганнар апрель аенда кәбестә орлыкларын теплицага чәчә ала. Монда салкынча температураны саклавы уңайрак.

Кышка саклау өчен ак башлы кәбестәнең Агрессор, Амагер, Белоснежка, Валентина, Женева, Колобок сортлары әйбәт. Иртә өлгерешле сортларны апрельнең беренче көннәреннән дә калмыйча, уртача өлгерешлене – апрель уртасына кадәр, соң өлгерешле сортларны 20 апрель тирәләрендә чәчәләр. Орлыкларны 10–15 см ара калдырып, сызылган буразналарга, бер-берсеннән 3–5 см ераклыкта чәчәргә кирәк.



Триходерма үрчетәбез

Бәлки, бу гөмбә турында инде ишеткәнегез булгандыр. Бакчачының экологик яктан зарарсыз ярдәмчесе ул. Фитофторадан, фузариоздан, тамыр муентыгы черегеннән саклаучы бу гөмбә бакчачылык кибетләрендә сатыла. Бар бакчаны эшкәртү өчен җитәрлек күләмдә сатып алу шактый бәягә төшәчәк. Аны өйдә дә үрчетеп була. Моның өчен 1 кг арпа, 1 кап әзер триходерма гөмбәсе, су, чиста банка кирәк. Арпа ярмасын чиста суга чыкканчы кат-кат юып, салкын суда 8–12 сәгать чылатабыз. Аннары сөзеп, саркытабыз. Стерильләштерелгән чиста банкага бүрткән ярманы салып, 4–7 минутка микродулкынлы мичкә куеп алабыз. Ярма кайнарланырга, ләкин пешмәскә тиеш. Кибеттән алган триходерма гөмбәсен, инструкциядә күрсәтелгәнчә сыеклап, суынган ярма өстенә агызабыз. Банка авызын тастымал белән каплап, җылы урынга куябыз. Бер-ике көннән ярма ак төсле кунык – мицелийлар белән каплана. Ә тагын өч-дүрт көннән саргылт-яшел төсле споралар күренә башлый, алар мицелийларны тулысынча каплап алгач, триходерманы үсемлекләр өчен кулланып була. Ярты литрлы банкадагы гөмбәне 30 литр суда сыеклыйлар. Кулланып бетмәгән ярманы туңдырып яки киптереп сакларга мөмкин.

Бакчачыга

Агачларда бөреләр уяна, ә алар белән бергә корткычлар да... Апрель ае – чир тудыручы гөмбәләр, корткычлар белән көрәшү вакыты. Бөреләр ачылганчы җимеш агачларына һәм куакларга чирләргә каршы препаратлар бөркеп өлгерергә кирәк. Иң гади чаралардан – 3 процентлы бакыр купоросы. Аны һава температурасы 5 градус җылылыктагы, җилсез көнне сибәрләр. 10 литр суга 300 г бакыр купоросы алына (3 процентлысы өчен). Әлеге чара парша, кутыр, антракноз, монилиоз, коккомикоз, ончылчык авыруларыннан да профилактика булып тора.

Карлыган куакларын корткычлардан зарарсызландыру өчен кайнар су бөркергә киңәш ителә. Әмма моны белеп эшләсәң генә файдасы бар. Кайнар суны бөреләр ачылганчы, ягъни кар эреп бетәр-бетмәс вакытта ук башкаралар. Су 80 градустан да кайнар булмасын. Куакны тигез эшкәртү өчен, ботакларын җыеп бәйлиләр. Суны бер урынга 3 секундтан да артыграк сибәргә ярамый, югыйсә ботаклар пешәргә мөмкин.

Кар эреп, җир кипкәнче, агач-куакларны беренче тапкыр ашлыйлар. Бу чорда азотлы ашламалар кулланыла. 1 квадрат метрга 50–100 ашлама кертеп, туфрак белән җиңелчә генә күмдерелә.

Фото: www.pixabay.com

ҖИҢСЕЗ КҮЛМӘК КИЯРГӘ ӘЗЕРЛӘНӘБЕЗ



Көннәр җылыну белән без, хатын-кызлар, матур күлмәкләр, җилфердәп торган итәкләр киябез. Җиңсез киемнәр кигәндә күз иң элек беләкләргә төшә. Ә ул сыек булып, мускуллар тонуста булмаса, кигән күлмәкләрнең бер матурлыгы калмый. Беләк тулышып, мускул линияләре күренеп торсын өчен, махсус күнегүләр эшләргә кирәк. «Физик эш башкарып кына кулларны матурлап була дигән фикер дөрес түгел, чөнки бертөрле генә мускуллар хәрәкәткә килә, шуңа күрә махсус күнегүләр эшләргә кирәк», – ди тренер Резеда МУСИНА. Спортзалга бармыйча, аларны өйдә генә эшләргә дә мөмкин. Бары тик 2,5 килограммлы ике гантель һәм теләк кенә кирәк. Һәр күнегүне өчәр тапкыр 12–15 кат эшләү җитә. Киттек!











1 Туры итеп басабыз. Кул чугын алга таба борып, гантель тоткан кулларны бераз алга чыгарабыз. Сулыш чыгарганда кулларны якяктан өскә күтәрәбез, ә сулыш алганда әкрен генә төшерәбез.

2 Бу күнегүне мәктәп эскәмиясеннән үк беләбез. Кулларны шулай ук бераз алга сузабыз һәм сулыш чыгарганда, терсәкләрдән бөкләп, салмак кына гантельләрне күкрәккә таба китерәбез.

3 Гантельне ике кул белән тотып, кулларны өскә күтәрәбез дә, гантельне баш артына җибәрәбез; сулышны чыгарганда аны өскә таба күтәрәбез. Күнегүне ясаганда – сынның туры, калак сөякләренең бер-берсенә тиеп торуы мөһим.

4 Тездән бераз гына чүгәбез, арканы төз тоткан хәлдә алга таба иеләбез. Куллар терсәктән бөгелгән, сулышны чыгарганда кулларны артка җибәрәбез.

5 Туры итеп басабыз, куллар якякка күтәрелгән. Бу вакытта күкрәк киерелгән булырга тиеш. Сулыш чыгарганда кулларны өскә күтәрәбез. Сулыш алганда – төшерәбез.



Күнегүләрне QR-код аша кереп, видеодан да карый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Челтәр-челтәр ак пәрдә

Яз җиткәч үзебезне генә түгел, яшәгән өебезне дә матурлыйсыбыз килә. Өйне, тәрәзәләрне юа башлыйбыз. Ел фасылына карап пәрдәләр алыштырып элү – элек-электән килгән гадәт. Өйне яңача бизәп куйгач, дөнья үзгәреп, яктырып киткән кебек. Мода өй бизәүне дә урап узмый. Бүгенге көннең тренды нинди? Белгечләр нинди тукыма, фурнитура, стиль тәкъдим итә? Пәрдәләр дизайнеры Азалия ГАЛИМОВА шушылар хакында сөйли.





Фото: А. Галимова

2021–2022 еллар тренды

Пәрдә – текстиль декор элементы. Дөрес итеп сайласаң, теләсә нинди өйнең йөзек кашына, хәтта визит карточкасына әйләнә.

Берничә ел модада булган табигый нейтраль төсле тукымаларга ачык һәм текстуралылары алмашка килде. Тәрәзәләрне бизәүдә киң кулланылган ламбрекеннар да пьедесталдан төште. Алар болай да өй биеклеге өч метрдан арткан очракта гына килешле күренә. Тәбәнәк йортларда ламбрекен эләргә киңәш итмим, чөнки өй биеклеген бик нык «ашый».



Кәрниз охшамаган очракта бердәнбер вариант: бандо кулланырга була. Катырылып тегелгән махсус формадагы тукыма шул рәвешле кәрнизне каплый. Гомумән, тәрәзә бизәүдә ламбреkennарга, чукларга өстенлек бирүчеләр азаеп бара. Классик стильне хәзер бик аз сайлыйлар. Дөрес, узган ел яңа декор – магнитлы чуклар барлыкка килде. Әмма аңа сорау зур түгел, күрәсең, белеп бетермиләр. Алар кыз кулындагы йөзек кебек, пәрдәгә шарм өсти. Хәзер модада бер тондагы, гади генә эленеп торган пәрдәләр. Велюр, ясалма замш белән кызыксыналар. Бик сирәк очракта гына портьерны җыя торган элемент кулланыла.

Кәрнизләр буенча билгеле бер тренд юк. Нигездә, түшәмгә беркетелгән кәрнизгә сорау зур, чөнки алар очсыз, һәм аның нинди материалдан эшләнүе мөһим түгел. Җитмәсә, күпләр хәзер тарттырылган түшәмнәр ясата. Стенага беркетү өчен дюралюминийдан ясалган таяклар киңәш итәм. Алар күптөрле төсләрдә. Кәрнизнең баш-башларына өйнең стиленә туры килерлек элементлар куярга мөмкин.

Пәрдә сайлау

Пәрдәләр сайлаганда җиһазларның нинди материалдан ясалуына игътибар итсәгез иде. Мәсәлән, рогожка, ягъни капчык сыман тупас тукымадан ясалган мебельле өйгә шундый ук тукымадан тегелгән пәрдәләр сайлау дөресрәк булыр. Диван-креслолар велюр белән тышланса, пәрдәләрне шома текстуралы тукымадан тектерегез. Акцент ясыйсыгыз килсә, портьерны җыеп торган декорны башка төрле тукыма сайлагыз. Аерым бер төсмер бирер өчен махсус кант кулланырга киңәш итәм клиентларыма. Ягъни пәрдәләрне контрастлы төстәге тукыма белән читлибез йә өстән полоса җибәрәбез. Ул бик матур акцент булып тора.



Бүлмәләргә нинди челтәр-пәрдәләр эләргә?

Бүлмәдә тәрәзәләр аз һәм кечкенә икән, авыр портьерлар эләргә кирәкми. Ул яктылык керергә дә комачаулый, бүлмәне дә кечкенә итеп күрсәтә.

Челтәр сайлаганда саранланырга ярамый. Ул тәрәзә иңеннән кимендә ике тапкырга киңрәк булырга тиеш. Җиңел, таралып торган шома тукымаларга өстенлек бирегез. Челтәр сайлаганда өйдәге яктылык мөһим роль уйный. Мәсәлән, тәрәзәләр төньякка чыга икән, бизәксез, ап-ак челтәр сайларга кирәк. Ул яктылыкны яхшы кертә. Әгәр дә кояш төшкән як икән, калынрак, бизәклерәк тә ярый. Мәсәлән, креп тукыма.

Кухняга пәрдәләр теккәндә гарнитурның ничек корылуына карап эш итеlә. Кайбер мебель ясаучылар шкаф белән стена арасында бөтенләй урын калдырмый, нәтиҗәдә, челтәр 10 сантиметр чамасы мебельгә тиеп тора. Моннан котылу өчен, челтәрне бер якка җыйдырып куябыз. Тәрәзә төбенә терәтеп ясалган мебель булса, кыска челтәр, рим пәрдәләре уңышлы булыр.



Балалар бүлмәсенә, гадәттә, якты төсләр сайлана. Алсу, зәңгәр, сары, яшел, төсле тукымадан тегелгән пәрдәләргә өстенлек бирелә. Алар аксыл көрән (бежевый) төстәге челтәр белән килешә. Гомумән, төсләр балага, аның холкына карап сайлана. Кайберәүләр балалар бүлмәсенә яктылык кертми торган блэкаут пәрдәләр элә. Имеш, балага төнлә йокларга уңайлы. Әмма бу идея белән килешмим. Балаларның үз биоритмнары формалаша. Блэкаут пәрдә кояш яктысында да бүлмәне томалый. Ә караңгыда уянырга авыр. Бу өлкәннәргә дә кагыла. Бигрәк тә иртән авыр торучыларга мондый төр пәрдәләрне кулланмаска киңәш итәм. Бүлмәне караңгылатасыгыз килә икән, 50–70 процентка караңгырак портьерлар сайлагыз. Стандарт яктылык сезне уята алачак. Бу – организмга да азмы-күпме стресс дигән сүз.







Челтәр-пәрдәләрне ничек юарга?

Составында полиэстер булган тукымаларны 20 градуслы җылымса суда юарга киңәш итәм. Юу өчен махсус капчыкларга салсагыз, машина барабаны челтәр-пәрдәләргә зыян китермәс. Табигый тукымаларны коры химчисткага бирү киңәш ителә. Кер юу машинасында юганнан соң алар формасын югалтырга мөмкин. Бәрхет тукымадан тегелгән пәрдәләрне дә юарга ярамый.

Челтәрләрне «Белизна» белән юарга киңәш итмим. Бер-ике тамчы көнкүреш агарту химиясен генә тамызыгыз. Ак төстәге челтәр иртәме-соңмы кояш нурларыннан саргая ул. Аларны куллану вакыты ун елдан артмый. Дөрес итеп юылган очракта, портьерлар бик озак хезмәт итәргә мөмкин. Хәзер челтәр-пәрдәләрне үтүкләргә яратмыйлар. Аларны дымлы килеш эләләр, кипкәч, сырлар калса, пар утюгы белән йөртеп алалар. Әйткәнемчә, зәвык белән сайланган челтәр-пәрдәләр күзне иркәли. Өегез һәрвакыт ямьле булсын!

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
әзерләде.

Төрек пәхләвәсе

Рамилә ЗАКИРОВА – Әлки кызы. Алар гаиләдә өч кыз. Бәләкәйдән дәү әниләре янында, аның уң кулы булып үскәнгәдер, өчесе дә аш-суга бик уңганнар. «Куллары ятып тора, пешекчегә бар», – дип әйтә торган була Рамиләгә дәү әнисе. «Пешеренергә бик яратам, – ди ул үзе дә. – Ризык әзерләгәндә җаным ял итә. Күңелем боекса, аш бүлмәсенә кереп бикләнәм дә, берәр яңа рецептны сынап карыйм. Шуннан үземә бер рәхәтлек алам, борчу-мәшәкатьләрем онытыла». Пешергән ризыкларын матур итеп фотога төшереп, рецептларын дуслары белән дә бүлешә ул. Ире Фәнил дә: «Безнең Рамиләдә рәссамлык сәләте дә бар. Аның ризыклары тәмле дә, матур да була», – дип, хәләленең күңелен үстереп тора. Бөтендөнья татар конгрессы уздырган «Татар табыны-2019» конкурсының финалисты булуы да юкка гына түгел. Дәү әнисенең киңәшен тотса – яхшы кулинар, хыялы артыннан барса моңлы тавышлы артистка булыр иде Рамилә. Ә ул менә педагогик белем алган, физика укытучысы булырга әзерләнгән. Тик... язмыш исә тормыш сукмакларын бөтенләй башка юлга кертеп җибәргән: Рамилә Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең сайлау комиссиясендә инженер булып эшли. Алган белеме менә кайда кирәк булган аңа! Әмма кайда гына эшләсә дә, яраткан хоббиена тугрылыклы ул. Аның өчен иң рәхәт, иң җылы урын – аш бүлмәсе!
Бүген укучыларыбызга ул пәхләвә пешерү серләрен ачар. Пәхләвәнең әллә ничә төрлесен әзерли Рамилә. Бу юлы исә төрек пәхләвәсен пешереп карарга булдык. Ягез, кемнәр безгә кушыла!





Кирәк

- 2 йомырка;
- 130–150 мл сөт;
- 100 мл үсемлек мае;
- 1/4 бал кашыгы тоз;
- 1 бал кашыгы камыр көпшәкләндергеч;
- 500–600 г он;
- камырны җәйгәндә куллану өчен кукуруз крахмалы;
- эчлегенә салырга 400 г вакланган әстерхан чикләвеге;
- өстенә сибәргә 300 г эретелгән атланмай;
- бизәр өчен вакланган пестә (фисташка) чикләвеге.

Эш барышы

■ 2 йомырка, сөт, үсемлек мае, тоз, камыр көпшәкләндергечне бергә кушып, артык каты булмаган камыр басабыз. Үзләнгәнче баскач, 30–50 минут тирәсе ял иттерәбез.

■ Камырны куна тактасына төшереп, 13–15 тигез өлешкә бүләбез.

■ Һәр өлештән бик юка җәймәләр җәябез. Камырны җәйгән вакытта он урынына крахмал кулланабыз.

■ Майламаган коры табага өч җәемне бер-бер артлы түшәп, камыр өстенә мул итеп төелгән әстерхан чикләвеге сибәбез. Чикләвек күбрәк булган саен тәмлерәк.

■ Чикләвек өстенә кабат өч-дүрт кат итеп камыр җәелә. Аның өстенә дә мулдан чикләвек сибәбез.

■ Калган кисәкләрне дә шулай юка итеп җәеп, бер-бер артлы табага түшибез. Әзер пәхләвәдә өч кат камыр, ике кат чикләвек булырга тиеш.

■ Үткен пычак белән пәхләвәне тигез итеп кыек шакмакларга (ромбикларга) бүлеп чыгабыз. Ромбикларның зурлыгы 4 см тирәсе.

■ Эретелгән атланмайны камыр өстеннән сибеп, пәхләвәне 180 градус кайнарлыктагы мичкә 50–60 минутка куябыз. Ул алсуланып пешәргә тиеш.

■ Пәхләвә пешеп чыгарга 10 минут кала, ширбәт кайнатабыз. Моның өчен 300 г шикәр комы, 300 мл су, берничә лимон телеме кирәк. 10 минут кайнагач, ширбәтне сөзәбез.

■ Пәхләвәне мичтән алып, өстенә чүмеч белән кайнап торган ширбәт агызабыз.

■ Бизәр өчен исә вакланган пестә чикләвеге әзерлибез.

Пәхләвә кайнар килеш тә, суынгач та бик тәмле була.

Күрәсез, аны әзерләүнең бер катлаулылыгы да юк.

Чәйләрегез тәмле булсын!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Детокс-аш

Озакка сузылган авыр кыштан соң организмыбыз туклыклы матдәләргә, витаминнарга мохтаҗ. Яңа гына сыгылган соклар һәм смузилар бу кытлыкны тулыландыра, билгеле. Ләкин рационыбызны детокс-ашлар белән дә баетырга булдык. «Дөрес туклану» рубрикасының даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА бүген нәкъ менә аларның файдасы турында сөйләр.



Детокс-аш – яшелчәдән әзерләнгән җиңел ризык. Ул организмны шлаклардан һәм токсиннардан арындыра, файдалы микроэлементлар белән баета, туклык хисе бирә. Ә яшелчәләрдәге клетчатка эчәклекне чистартырга булыша, кирәкле микрофлораны торгыза, иммунитетны ныгыта. Рационыгызга детокс-ашлар өстәп, матдәләр алмашын яхшыртасыз.

Детокс-ашның нигезен яшелчә шулпасы тәшкил итә. Аны төрлечә әзерләргә мөмкин, без исә база вариантын тәкъдим итәбез. Берьюлы кулланып бетерә алмасагыз, калганын туңдырып та куя аласыз.

Шулпа әзерләү:

3 литрлы салкын суга 4 кишер, 2 баш суган, 3 сельдерей сабагы, 5–7 тармак укроп, петрушка, 3–4 тармак тимьян, 3–4 тырнак сарымсак, 6–7 борчак кара борыч, дәфнә (лавр) яфрагы һәм тәменчә тоз кирәк.

Яшелчәләрне суга салып, кайнап чыккач, 25–30 минут талгын утта пешерәбез. Соңыннан шулпаны сөзәбез. Шулпа әзер! Әлеге шулпа белән төрле детокс-ашлар пешерергә мөмкин. Без исә брокколи ашы тәкъдим итәбез.

Брокколидан детокс-аш

■ Әлеге аш өчен төп ингредиентлар – брокколи, сельдерей һәм яшел борчак. Брокколи организмны менә дигән итеп чистартучы продукт. Ул ялкынсынуларны баса, йөрәк-кан тамырлары, ашкайнату системалары эшчәнлеген җайга сала.

■ Сельдерейда исә калорияләр бик аз, ә менә С витамины күп. Антиоксидантларга, ялкынсынуны басучы матдәләргә дә бай ул. Брокколи кебек үк, сельдерей да йөрәк-кан тамырлары, ашкайнату системалары эшчәнлеген көйләргә булыша.

■ Яшел борчак – аксым чыганагы.

Кирәк:

- якынча 350 г брокколи;
- 3 сельдерей сабагы;
- 150 г туңдырылган яшел борчак;
- бер кечкенә имбир кисәге;
- 5 кыяк яшел суган;
- 400 мл яшелчә шулпасы;
- тәменчә тоз белән борыч.

Эш барышы:

■ Сельдерей, суган һәм брокколины ваклап турагыз, ә имбирны угычтан уабыз.

■ Табага аз гына май салып, сүрән утта суган белән имбирны кыздырып алабыз. Аннары шунда ук сельдерейны һәм шулпаны өстибез.

■ Шулпа кайнап чыкканнан соң, утны киметеп, 25 минут пешерәбез. Шулпага брокколи белән яшел борчакны салып, 5 минут кайнатабыз да уттан алабыз.

■ Аш бераз суына төшкәч, блендер белән издерәбез.

■ Табынга биргәндә кабак яисә көнбагыш төше, чикләвек, бер чеметем генә кызыл борыч яисә көнҗет орлыгы белән бизәргә була.

Ашларыгыз тәмле, сихәтле булсын!

Фото: www.pixabay.com

Кучкар хатын-кыз

Кучкар йолдызлыгында туган хатын-кызлар – көчле шәхесләр. Күп кенә «тимер леди»лар нәкъ менә Кучкарлар. Әлеге йолдызлык Марс планетасы йогынтысында, ә ул егетләр планетасы санала. Менә шуның өчен аларның холкында ир-егетләргә хас сыйфатлар чагылып китә дә инде. Хатын-кыз Кучкар теләсә нинди катлаулы хәлдән дә чыгу юлын табачак, үз проблемаларын үзе чишәчәк.

Кучкар хатын-кыз – чып-чын перфекционист. Аның бөтен нәрсәсе идеаль булырга тиеш. Үзенең көчсез якларын бирәүгә дә күрсәтмәс, зарланмас. Мөстәкыйльлеккә бик яшьли өйрәнә, үз язмышын үзе кора. Кучкарны буйсындырам димә.

Мөнәсәбәтләр

Кучкар хатын-кызлар ирләрне үзләренә җәлеп иттерә белә. Никадәр генә көчле булсалар да, яраткан кешесе янында алар нәфис, нечкә күңелле, ягымлы хатын-кызга әверелә. Тугрылык – төп принциплары. Аның өчен ир-егетнең акчасы түгел, шәхси сыйфатлары мөһимрәк. Кайчак ул үзеннән көчсезрәк ир-егетне дә сайларга мөмкин, ләкин аның алга таба үсәрлек мөмкинлеген күрсә генә.

Гаилә

Кучкарлар идеаль гаилә кору турында хыяллана һәм бу адымга бик уйлап кына бара. Ирен тагын да үстерер өчен кулыннан килгәннең барысын да эшли. Аның янәшәсендә тыныч кына яши алмыйсың.

Карьера

Бу йолдызлык астында туган хатын-кызлар гел югарыга омтыла. Үзенә максат куя икән, ул аңа, һичшиксез, ирешәчәк һәм моның белән генә дә тукталып калмаячак. Кучкарларны аерып тора торган тагын бер сыйфат – акыл. Бизнестамы, фәндәме, шәхси өлкәдәме – акылы аңа һәрвакыт ярдәм итеп, ялгыш адымнардан саклап килә.

Йолдызнамә май

Кучкар. Кыйммәтле әйберләр сатып алу, зур чыгымнар өчен яхшы вакыт түгел. Бу – рухи үсеш, әхлакый кыйммәтләрне ныграк бәяләү ае. Яңа эшләр башласагыз, яңа белемгә тотынсагыз, уңышка ирешерсез.

Үгезбозау. Уңышлы ай булыр. Рухи күтәренкелек ай ахырына кадәр дәвам итәр. Нәрсәгә тотынсагыз, шул эшегез гөрләп барыр. Моңа кадәр уйларга да куркып торган идеяләрегезгә керешә аласыз.

Игезәкләр. Энергиягез ташып торса да, ялгызыгыз гына калып, җаныгызны тыңлыйсы килер. Үз-үзегезне аңлар, хаталарыгызны танып, аларны төзәтер өчен менә дигән чор. Иҗади талантыгыз ачылыр.

Кысла. Сабырлык, башкаларны аңларга тырышу, үз-үзеңне кулда тоту – бу айның төп таләбе менә шулар. Уңышны куркытмас өчен, телегезне тыебрак, күңелдәгесен яшеребрәк торыгыз.

Арыслан. Эш азлыктан зарлана алмыйсыз. Аның каравы, нәтиҗәсе сөенерлек булыр: һөнәри яктан үсеш көтелә. Шуның белән бергә акча ягы да күпкә җайлана төшәр. Әлегә үзегезне күрсәтергә тырышыгыз.

Сөмбелә. Документлар белән эшләүдә, хокукый мәсьәләләрне чишүдә уңышка ирешерсез. Яңа белемнәр җиңел үзләштерелә, бу мөмкинлектән файдаланып кала аласыз. Рухи кыйммәтләргә омтылыш көчле.

Бизмән. Тыныч һәм имин ай. Ләкин сезнең кебек эш дип яшәүчеләр өчен күңелсез тоелырга мөмкин. Хәер, озак күңелсезләнергә туры килмәс, бу айда күңелле сюрпризлар күп булырга тиеш.

Чаян. Табигатьтә генә түгел, күңелегездә дә яз. Һәм ул хис әле озакка барачак. Бу күтәренкелек әллә нинди катлаулы эшләрне дә бер тында башкарырга мөмкинлек бирер. Тормышның вактөягеннән дә ләззәт алып яшәрсез.

Укчы. Айның энергиясе тынычлыкка, дуслыкка этәрә. Ләкин ай ахырына таба мәшәкатьләр күбәеп китеп, тынычланырга җай калмавы да ихтимал. Эшне генә түгел, сәламәтлекне дә кайгыртырга вакыт.

Кәҗәмөгез. Нәрсәгә сәләтле икәнегезне күрсәтергә җай чыгар. Тырышлыгыгызның нәтиҗәсе куанычлы. Моңа кадәр чишелми килгән мәсьәләләр җиңел генә хәл ителер.

Сукояр. Эш алымнарын үзгәртергә туры килер. Яңалык уйлап тапканчы, элеккегеләрнең тәҗрибәсенә күз салыгыз, чишелешне шунда күрерсез. Якыннарыгызга бәйле хәл итәсе мәсьәләләр килеп чыгуы ихтимал.

Балык. Сез актив, көчле, эш дәрте белән янасыз. Мондый куәтле энергия ташкынын файдалы итеп кулланып калыгыз. Ләкин бу айда акчалар белән сак эш итегез, уйланмаган чыгымнар килеп чыкмагае.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА әзерләде.







ТЫН ЧӘЧӘКЛӘР ҖЫРЫ

Чаллы рәссамы Марсель Сингатуллин киндерләрендәге чәчәкләренең һәммәсе: бәйләмнәрдәгеләре дә, зур итеп, макросурәт рәвешендә язылганнары да камиллек чигендә! Аның иҗаты каршында күпләр эреп китә! «Сез тудырган матурлыктан күз дә аласы килми!» – дигән ихлас соклануларны еш ишетә, еш укый талант иясе.

Ә бит балачакта күп рәсемнәр ясаса да, рәссамлыкка омтылышы булмаган аның. «Үсеп җиткәч йә язучы, йә умартачы булырмын дип уйлый идем, – ди Марсель. – Сәнгатькә тартылу, нәкъ менә майлы буяулар белән картиналар язу теләге... бик кинәт кенә, 19 яшемдә күңелемне биләп алды. Шунда киләчәгемне сынлы сәнгать белән бәйләргә теләвемне аңладым, тик моның өчен һөнәри белем алырга да кирәк иде: Чаллы педагогика институтының сынлы сәнгать-графика факультетына өч тапкыр имтихан тоттым. Уку еллары тәмамлангач, ирекле рәссам булып киттем, осталыгымны арттыру өчен гел практикада булдым... Тәүлекнең яртысы диярлек нидер ясап үтә иде. Хәзерге уңышлы иҗат итүемнең бер сәбәбе – тырышлык та».

Марсель Зөфәр улының иҗатында төп юнәлеш һәм максат – чәчәкләр матурлыгын күрсәтеп бирү булса да, ул башка жанрдагы картиналарны, марина һәм анималистика юнәлешендәге әсәрләрне дә яратып, зәвык белән яза. Диңгез пейзажларын иҗат итәр өчен И. Айвазовский әсәрләрен тирәннән өйрәнеп тәҗрибә туплаган. Анималистикага килгәндә, башта төрле кошларны һәм җанварларны ясаса да, соңгы вакытта ул бары тик атларны сурәтләү белән генә мәшгуль. «Аларны кечкенәдән яратам, чөнки дәү әтием Марс гомер буе атлар тотты, һәм мин дә аның янында шул атлар белән мәш килә идем. Шуңа күрә аларны теләсә кайсы ракурста, килешле һәм бик тә төгәл итеп сурәтләп бирә алам», – ди оста.

Марсель Сингатуллин әсәрләре Россия һәм БДБ дәүләтләре, Болгария, Германия, АКШ һәм Австриядәге шәхси тупланмаларда да саклана.

Тамашачыларның кайберләре рәссам картиналарына сокланып кына калмыйча, ул үткәргән осталык дәресләренә дә теләп йөри. Картиналарын игелекле, куәтле энергетикалы арт-терапиягә тиңләүчеләр дә җитәрлек. Бик тә зәвыклы сәнгатьсөярләр дә бу фикербәяләмә белән килешә. Марсель исә уңышларының серен хәләл җефете белән дә бәйли: «Без икебез дә рәссамнар, бергә укыдык. Алсуга бер күрүдә гашыйк булдым. Бүгенге көндә ул минем иң якын киңәшчем дә, илһамчым да! Улыбыз Марат белән кызыбыз Алиса киләчәктә рәссам булып китәрләрме, әлегә билгесез, әмма аларның да рәсем ясауда сәләтләре бар!»

Марсель Зөфәр улы шәхси һәм гомуми күргәзмәләрдә еш катнашмый, ләкин башка рәссамнар аның иҗаты турында күптән югары фикердә инде. Останың журнал укучыларына тәкъдим ителүче шушы үзенчәлекле эшләр галереясы да күпләр күңеленә хуш килер дигән фикердә без.

Һава, яктылык белән сугарылган картиналарындагы тыныч төс-төсмерләр, кылкаләменең «ювелирлык» дәрәҗәсендәге нәфис буяу япмалары талантлы рәссамның үз хезмәтен бик яратуын сөйли. Чиксез диңгез-океаннарның төрле кәефләрен, тырыш атларының мәгърурлыгын, шат чәчәкләр ямен үз эченә алган экспрессив иҗаты киләчәктә дә сөендерер әле безне.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА













МАРСЕЛЬ СИНГАТУЛЛИН

2021 

ГОД РОДНЫХ ЯЗЫКОВ И НАРОДНОГО ЕДИНСТВА В РЕСПУБЛИКЕ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ТУГАН ТЕЛЛӘР ҺӘМ ХАЛЫКЛАР БЕРДӘМЛЕГЕ ЕЛЫ



Елена АЛЕКСЕЕВА,
Кайбыч районы Кече Мәми авылы җирлеге башлыгы

Мин Кече Мәмидә туып, шушы авыл мәктәбендә белем алдым. Күпмилләтле мәктәп – төрле авыллардан килеп укыйлар иде монда. Татары да, чуашы да, рус балалары да... Мәктәпкә укырга кергәнче татарча белдем дип әйтә алмыйм. Өйдә без чуашча сөйләштек, чуаш авылында яшәгәч, урамда да күбрәк чуаш телендә аралаштык. Дусларым, классташларым арасында татарлар күп иде, татар теленә мине алар өйрәтте. Кыен булмады татарча өйрәнү. Әле ярый өйрәнгәнмен, дим. Кече Мәми муниципаль авыл җирлегенә татар авыллары да керә. Җирлек башлыгы булгач, алар белән гел аралашып торырга туры килә. Татар авылларында яшәүче әби-бабайлар русча бик яхшы белеп тә бетермәскә мөмкин бит. Алар белән үз телләрендә сөйләшә алуым һәрвакыт ярдәм итә. «Син бит чуаш кызы, ничек татарча өйрәндең?» – дип аптырыйлар. «Татарча белмәгән чуаш бармыни ул?!» – дип җавап бирәм. Тел белүнең беркемгә дә авырлык китергәне юк әле, ә менә ярдәмен күп тоям.



Фото һәм видео: Анна Арахамия.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

